Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина

# ТУГАН ТЕЛДӘГЕ ӘДӘБИЯТ 5

Методик әсбап



Г. Н. Мөхәрләмова, Д. М. Абдуллина

# ТУГАН ТЕЛДӘГЕ ӘДӘБИЯТ

**5 нче сыйныф**

Методик әсбап

Төп гомуми белем бирү оешмаларында
(туган (татар) телендә сөйләшүче укучылар белән)
эшләүче укытучылар өчен

КАЗАН
2024

УДК 82 (072)
ББК 74.268.3 (=632.3)
М92

Методик әсбап
Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать
институтында эшләнде

**Мухарлямова Г. Н.**
М92 Родная (татарская) литература. Туган телдәге әдәбият. 5 класс. Методическое пособие : для преподавателей образовательных организаций основного общего образования, работающих с обучающимися, владеющими родным (татарским) языком / Г. Н. Мухарлямова, Д. М. Абдуллина. — Казань, 2024. — 126 б.

Методик әсбапта 5 нче сыйныфта «Туган (татар) телдәге әдәбият» предметы буенча дәреслек белән эшләү тәртибе яктыртыла. Биредә предметны өйрәнүгә куелган максат-бурычлар, планлаштырылган нәтиҗәләр, тематик планлаштыру, дәрес эшкәртмәләренең үрнәкләре бирелә.

Әсбап урта сыйныф укытучыларына ярдәмлек буларак тәкъдим ителә.

УДК 82 (072)
ББК 74.268.3 (=632.3)

© Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, 2024
© Г. Ибраһимов исем. әдәбият һәм сәнгать институты, 2024
© Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. 2024

## ХӨРМӘТЛЕ ХЕЗМӘТТӘШЕБЕЗ!

Әлеге методик ярдәмлек дәреслек белән эшләүне беркадәр җиңеләйтү, юнәлеш бирү максатыннан әзерләнде.

Төп гомуми белем бирү этабында алга таба әсәрләрне укырга мөстәкыйль сайлый белә торган, теләгенә һәм куелган уку мәсьәләсенә бәйле рәвештә үзенең уку эшчәнлеген мөстәкыйль белем алуда файдаланучы грамоталы китап укучы тәрбияләү «Туган (татар) телдәге әдәбият» укыту предметының төп максаты булып тора. Моның өчен иң беренче чиратта укучыда әдәби текстны укый, тиешле аңлатмалар бирә, анализлый, шәрехли белү күнекмәләрен булдыру кирәк. Бу укучыларны аерым әдәби-теоретик төшенчәләр, татар әдәби процессы белән таныштыруга, әдәби анализ элементларын кертү аша сәнгать төре булган әдәбиятка якынайтуга, аның тарихи процесска бәйләнешен аңлауга ярдәм итә.

Укучыларда китап укуга кызыксыну уяту, аларның әхлакый һәм эстетик хисләрен тәрбияләү, туган телләрендә иҗади эшчәнлеккә сәләтләрен үстерү дә шул төп максатка хезмәт итә. Моннан тыш, безнең заман өчен укучыларның коммуникатив күнекмәләрен формалаштыру, аларның телдән һәм язма сөйләмнәрен камилләштерү дә зур әһәмияткә ия.

Урта сыйныфларда әкиятләр, мифлар, риваять һәм легендалар, халык авыз иҗатының кече жанрлары булган табышмаклар, мәкаль-әйтемнәр, татар халык җырларын, дастаннар, бәетләр өйрәнүне, укучыларның татар халык авыз иҗаты әсәрләренең жанр үзенчәлекләренә, төп проблемаларына төшенүләре күздә күздә тотыла. Яңа программаларда һәм шул исәптән дәреслекләрдә дә татар фольклорыннан материаллар 5—8 нче сыйныфларда урын алды.

Шулай ук бу сыйныфларда вакыт һәм сәнгатьнең төрләре арасындагы бәйләнешне күзәтү аша әдәбиятның төрләре һәм жанрлары проблемасын карау төп эш булып тора. Аерым алганда, 5 нче сыйныфта игътибар үзәгендә әдәби төрләр

турында мәгълүматлар, аерым әсәрләр мисалында проза, лирика һәм драма төрләренең үзенчәлекләре өйрәнелә.

Татар һәм рус телләрендә белем бирүче мәктәпләрдәге укучыларны күздә тотып иң беренче максат — укучыны халкыбызның бай әдәби мирасы белән таныштыру, аңа якынайту. Сүз сәнгате һәрвакытта да тәрбия бирүнең, кешенең үзаңын тәрбияләүнең алыштыргысыз чарасы, төп формасы саналган. Һәр заман, үз идеологиясен тарату өчен, шул чараны файдаланган һәм аны үз күзәтүе астында тоткан. Әдәбият укучыларыбызның сүзлек байлыгын арттырып, телен баетып кына калмый, ул аларны халкыбызның рухи мирасы, мәдәнияте, тарихы белән бәйли, милли характер формалаштыруның төп чарасы булып хезмәт итә. Димәк, хәзерге шартларда әдәбият дәресләре — укучыларыбызга милли тәрбия бирүнең төп формасы. Укучыларыбыз, һәр халыкның милли үзенчәлекләре булуын аңлаган хәлдә, татар халкының затлы сыйфатлары, олы тарихы белән горурлана, башкалар алдында аны дәлилли алырга тиеш.

Әдәби текстны эмоциональ кабул итү, образлы һәм аналитик фикерләүне үстерү, иҗади күзаллау, әдәби әсәр текстларын эчтәлек һәм форма берлегендә үзләштерү, төп тарихи-әдәби мәгълүматларны һәм әдәби-теоретик төшенчәләрне өйрәнү, әдәби әсәрләрне уку һәм анализлау күнекмәләрен булдыру шулай ук әдәби белем бирүнең аерылгысыз максатлары булып тора.

Туган (татар) телдәге әдәбият буенча УМКны эшләүнең бурычы — аны укытуны тормышка ашыруны тәэмин итү. Билгеле, әлеге яңа дәреслекләр яңартылган Федераль дәүләт белем бирү стандартларына нигезләнеп төзелгән федераль эш программалары буенча эшләнде.

Яңа УМКларның төп үзенчәлекләренең берсе — ул ике дәрәҗәдә белем бирү, ягъни рус телендә белем бирү оешмалары укучылары өчен дә, татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен дә уку материалының бер дәреслектә кушылуы. Беренче карашка, кабул итү өчен, куллану өчен дә авыр кебек тоелган юнәлеш, шул ук вакытта үзен аклый да. Хәзерге көндә татар җирлегендә файдаланылган (көндәлек тормышта татарча аралашучы) дәреслектә

нигез өлештә тәкъдим ителә торган материал үзләштерү өчен җиңел һәм мәгълүмати яктан чагыштырмача ярлы булып тоелырга мөмкин, телне яхшы белгән балаларның предметны үзләштерүләрен чикләп калдырмас өчен, татар мәктәпләре укучылары өчен тәкъдим ителгән материалга мөрәҗәгать итә алабыз.

Моннан тыш, бер программада уку материалын үзләштерүнең ике дәрәҗәгә бүленеп бирелүе татар һәм рус телләрендә белем бирү оешмаларында туган әдәбият укытуның үзенчәлеген аңларга гына түгел, ә белем бирүнең аерым бер дәрәҗәсендә үзләштерергә тиешле предмет нәтиҗәләренең күләмен ачык итеп күз алдына китерергә мөмкинлек бирә. Нигез өлештә татар әдәбиятының, халык авыз иҗатының тарихы һәм теориясе буенча төп күзаллауларын һәм төшенчәләрен формалаштыруга, әдәби текстны, шагыйрьләр һәм язучыларның иҗатын кабул итүгә, анализлауга һәм бәяләүгә өйрәтүгә, әдәби процессның төрле чорларында чагылыш тапкан матур әдәбиятка мәхәббәт уята. Тирәнтен өйрәнү дәрәҗәсе дөнья әдәбияты барышы фонында татар әдәбияты, татар халык авыз иҗаты буенча күзаллау һәм төшенчәләр формалаштыруны тәэмин итә, әдәби текстны кабул итүгә, анализлауга, интерпретацияләүгә һәм бәяләүгә, гомумән, татар әдәбиятының әдәби, структур, эстетик үзенчәлекләрен башка әдәбиятлар фонында билгеләүгә, әдәби текстларны, шагыйрьләр һәм язучыларның иҗатын, әдәби процессның аерым чорларында чагылыш тапкан төп тенденцияләрне чагыштырып бәяләүгә юнәлтелә.

Әдәбият предметыннан яңа УМКларның тагын бер үзенчәлеге — укучыларның коммуникатив компетенцияләрен формалаштыруга йөз тоту. Укучыларны матур, төзек, төгәл, дөрес итеп сөйләргә өйрәтү әдәбият дәресенең төп бурычларының берсе булып тора. Бу үз чиратында әдәбиятны яхшырак, тирәнрәк аңлау-төшенүгә ачкыч ролен үти.

Уку предметы буларак туган (татар) телдәге әдәбият дәресләренең потенциалы, тел дәресләренеке кебек үк, иң элек, аралашуга, сөйләмгә әзерлекле шәхес тәрбияләү. Аралашуга әзерлекле шәхес дигәндә без, телнең мөмкинлекләреннән иркен файдаланырлык, соралган темага әңгәмә алып

барырлык белеме булган шәхесне күздә тотабыз. Димәк, әдәбият дәресләре туган телнең асылына төшендерү, аның мөмкинлекләрен ачу, бу телдә иркен аралашу һәм иҗат итү мөмкинлегенә ия шәхес тәрбияләүгә юнәлтергә тиеш. Бу һәр дәрес бөртекләп уйланылган, белем бирү системасында эзлекле, өзлексез чылбырның бер буыны булганда гына тормышка ашырыла ала. Әгәр дәреснең максатлары бер дәрес белән генә чикләнсә, нәтиҗәлелеккә ирешү дә мөмкин түгел.

Дәреслектә урын алган әдәби әсәрләр дә аралашу эшчәнлегенә тарту өчен файдаланыла. Әдәби әсәр теле укучыларны әдәби телдә сөйләргә өйрәтү, аның матурлыгын, байлыгын аңлау, үзләштерү өчен бик файдалы чыганак булуын онытмаска кирәк. Шуңа бәйле рәвештә, дәреслеккә татар әдәбияты һәм фольклорының иң яхшы үрнәкләре кертелде.

Тел һәм әдәбият дәресләре бер-берсен тулыландырып килүе, бер максатка хезмәт итүен истә тотып, дәреслекләрдә ике предметның материалы тыгыз бәйләнештә эшләнде.

## «ТУГАН (ТАТАР) ТЕЛДӘГЕ ӘДӘБИЯТ» УКУ ПРЕДМЕТЫННАН ФЕДЕРАЛЬ ЭШ ПРОГРАММАСЫ

1. «Туган (татар) телдәге әдәбият» уку предметыннан федераль эш программасы (предмет өлкәсе — «Туган тел һәм туган телдәге әдәбият») (алга таба — туган (татар) телдәге әдәбияттан программа, туган (татар) телдәге әдәбият, татар әдәбияты) туган (татар) телдә һәм рус телендә белем бирүче оешмалар өчен туган (татар) телдә сөйләшүче укучылар өчен эшләнде, һәм аңлатма язуын, уку-укыту эчтәлеген, туган (татар) телдәге әдәбияттан программа үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләрен үз эченә ала.

2. Аңлатма язуы туган (татар) телдәге әдәбиятны өйрәнүнең төп максатларын, уку планы структурасындагы урынын, шулай ук эчтәлекне сайлап алуга, планлаштырылган нәтиҗәләрне билгеләүгә юнәлешләрне чагылдыра.

3. Уку-укыту эчтәлеге төп гомуми белем дәрәҗәсендә һәр сыйныфта мәҗбүри өйрәнү өчен тәкъдим ителгән эчтәлек юнәлешләрен ача.

4. Туган (татар) телдәге әдәбияттан программаны үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре төп гомуми белем бирү дәрәҗәсендә барлык уку чоры өчен шәхескә бәйле, метапредмет нәтиҗәләрне, шулай ук һәр уку елы өчен предмет нәтиҗәләрне үз эченә ала.

5. Аңлатма язуы.

5.1. Туган (татар) телдәге әдәбияттан программа укытучыга белем бирүдә заманча тенденцияләргә һәм актив укыту методикаларына юнәлдерелгән эш программасын булдыруда методик ярдәм күрсәтү максатыннан эшләнде.

5.2. «Туган (татар) телдәге әдәбият» шәхеснең интеллектуаль һәм әхлакый-эстетик үсеш дәрәҗәсен билгели торган гуманитар белем бирү юнәлешендәге төп предметларның берсе булып тора. Туган телдәге әдәбиятны өйрәнү тормышны танып белүгә һәм чынбарлыкны модельләштерүгә булыша, сүз-сурәт чаралары ярдәмендә дөньяның художестволы картинасын булдыра һәм аңа билгеле бер мөнәсәбәт тудыра, югары дәрәҗәдәге эмоциональ тәэсиргә ия.

Әдәби белем укуның һәм әдәбиятны өйрәнүнең үзенең шәхси үсеше өчен әһәмиятен аңлаган, үз фикерен дәлилли һәм аны телдән яки язма формада тәгъбир итә алган, шулай ук кеше һәм җәмгыять мөнәсәбәтләрен гармонияләштерү, дөньяны тану һәм үзен бу яшәештә күрә белү чарасы буларак системалы рәвештә укуга ихтыяҗы формалашкан укучы тәрбияләү белән бәйле.

5.3. 5—9 сыйныфларда туган (татар) телдәге әдәбиятны өйрәнү укучыларның татар әдәбияты әсәрләрен үзләштерүен, художестволы форма һәм эчтәлек бердәмлеге принципларына таянып шәрехләү һәм анализ күнекмәләрен үстерүне; милли үзаңны үстерү, этник чыгышны аңлау, системалы белемнәр алу өчен шартлар тудыру үз халкының тарихы, теле, мәдәнияте, дөньяга карашы, менталитеты, фәлсәфәсе турында белемне тәэмин итә.

5.4. Уку предметы гуманитар циклга караган башка уку предметлары белән, аеруча «Туган тел (татар теле)» һәм «Әдәбият» уку предметлары белән предметара бәйләнешләрне тәэмин итә.

5.5. Туган (татар) телдәге әдәбияттан программаның эчтәлегендә түбәндәге эчтәлек юнәлешләре аерылып чыга:

халык авыз иҗаты (әкиятләр (тылсымлы, көнкүреш, хайваннар турында әкиятләр), мифлар, риваятьләр, легендалар, халык авыз иҗатының кече жанрлары (табышмаклар, мәкальләр һәм әйтемнәр), татар халык җырлары, дастаннар, бәетләр; татар фольклоры 5—8 нче сыйныфларда тәкъдим ителә);

чорлар буенча татар әдәбияты (әдәби әсәрне мөстәкыйль сәнгать әсәре һәм катлаулы әдәби процессның бер чылбыры буларак карау; татар әдәбиятын аның үсеш этапларына туры китереп өйрәнү, урта гасыр әдәбиятыннан, XVIII гасыр, XIX—XX гасыр әдәбиятыннан башлап, хәзерге татар әдәбиятына кадәр; туган телдәге әдәбиятта тарихи вакыйгаларның чагылышын күзәтү, тарихи барышта татар әдәбиятының роле турында күзаллауларны киңәйтү);

әдәбият теориясе (конкрет әдәби әсәрләрне өйрәнү процессында теоретик-әдәби төшенчәләрне үзләштерү: вакыт һәм сәнгать формалары арасындагы өзелмәс бәйләнешне күзәтү процессында әдәбият төрләре һәм жанрлары проблемасын карау, 5 нче сыйныфта аерым әсәрләр мисалында проза, лирика һәм драма үзенчәлекләре өйрәнелә, 6 нчы сыйныфта лирик әсәрләрдә, хикәядә һәм повестьта, лиро-эпик әсәрләрдә, драма әсәрләрендә, шулай ук фантастик, автобиографик характердагы әсәрләрдә образлылык тудыру алымнары карала, 7 нче сыйныфта укучылар хикәя, повесть, роман, драма, лирик һәм лиро-эпик әсәрләрнең жанр хасиятләрен беләләр), 8 нче сыйныфта өйрәнү объекты булып әдәби алымнар (пейзаж, портрет, символ, әдәби деталь һәм башкалар) тора, 9 нчы сыйныфта татар әдәбияты тарихы өйрәнелә.

5.6. Туган (татар) телдәге әдәбиятны укыту түбәндәге максатларга ирешүгә юнәлдерелгән:

туган мәдәниятнең мөһим өлеше буларак, туган (татар) телдәге әдәбиятка кыйммәти мөнәсәбәт тәрбияләү;

укучыларны үз халкының мәдәни мирасына һәм гореф-гадәтләренә якынайту;

үзбелем чарасы буларак, үз уку эшчәнлеген куллана алган грамоталы укучы формалаштыру.

5.7. Программаны гамәлгә ашыруның куелган максатларына ирешү туган (татар) телдәге әдәбият буенча түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүне күздә тота:

әдәби текстка комментарийлар бирү, анализлау һәм шәрехләү күнекмәләрен үстерү;

укучыларны әдәбият белемендәге анализлау элементларын кертү, аерым теоретик-әдәби төшенчәләр белән таныштыру аша, сүз сәнгате буларак, туган (татар) телдәге әдәбиятка якынайту;

татар әдәбиятының барышы белән танышу һәм аның тарихи барыш белән бәйләнешенә төшенү;

укучыларның коммуникатив күнекмәләрен (татар телендә сөйләм һәм язма диалогик һәм монологик сөйләмнәрен) үстерү;

уку күзаллауларын формалаштыру;

укучыларның әхлакый һәм эстетик хисләрен формалаштыру;

укучыларның туган (татар) телдә иҗади эшчәнлеккә сәләтләрен үстерү;

гомум уку күнекмәләрен һәм универсаль уку гамәлләрен үзләштерү.

5.8. Туган (татар) телдәге әдәбиятны өйрәнү өчен тәкъдим ителгән сәгатьләрнең гомуми саны — 170 сәгать: 5 нче сыйныфта — 34 сәгать (атнага 1 сәгать), 6 нчы сыйныфта — 34 сәгать (атнага 1 сәгать), 7 нче сыйныфта — 34 сәгать (атнага 1 сәгать), 8 нче сыйныфта — 34 сәгать (атнага 1 сәгать), 9 нчы сыйныфта — 34 сәгать (атнага 1 сәгать).

6. 5 нче сыйныфта уку-укыту эчтәлеге.

6.1. Мифлар. Миф турында төшенчә. Мифларның килеп чыгышы, аларны классификацияләү. Татар халык мифлары.

6.1.1. Мифлар: «Җил иясе җил чыгара», «Тавык».

6.2. Халык авыз иҗаты. Халык мирасы буларак халык авыз иҗаты. Фольклор әсәрләренең үзенчәлекләре. Фольклорның төп жанрлары.

6.2.1. Әкиятләр. Әкият төрләре.

Татар халык әкиятләре: «Хәйләкәр Төлке», «Өч кыз», «Ак бүре».

6.2.2. Легендалар һәм риваятьләр. Жанр үзенчәлекләре. Легендаларның риваятьләрдән аермасы.

Легендалар: «Зөһрә кыз», «Кәккүк каян барлыкка килгән?».

Риваятьләр: «Шәһәр нигә Казан дип аталган?», «Тургай моңы».

6.2.3. Халык авыз иҗатының кече жанрлары: табышмаклар, мәкальләр һәм әйтемнәр.

6.3. Татар әдәбияты.

6.3.1. Әдәби (автор) әкияте. Әдәби әкияттә фольклор традицияләре. Әдәби әкияттә әдәби уйдырма.

Г. Тукай, «Шүрәле». Әкиятнең мифологик сюжеты. Әкият-поэманың поэтик үзенчәлекләре. Әкиятнең сәнгати мәгънәсе. Шүрәле образының сәнгатьтә бирелеше.

6.3.2. Проза. Эпик әсәрләр, аларның үзенчәлекләре. Хикәя жанры.

Ф. Яруллин, «Кояштагы тап». Әхлак темасы. Намус, мәрхәмәтлелек, үзара ярдәмләшү төшенчәләре. «Зәңгәр күлдә ай коена». Әдәби әсәрдә фольклор мотивлары. Яхшылыкның явызлыкны җиңүе. Образлар системасы, символик образлар.

Дәрдмәнд, «Богдай». Хикәянең әхлакый асылы: рухи байлык һәм кешенең җәмгыятьтәге урыны.

Г. Сабитов, «Урман кызы Таңсылу». Кеше һәм табигать бердәмлеге. Табигатьнең матурлыгы.

6.3.3. Мәсәл. Мәсәл жанры. Жанр хасиятләре. Геройлар, композиция.

Г. Тукай, «Умарта корты һәм чебеннәр».

Ә. Исхак, «Карт имән белән яшь егет».

6.3.4. Лирик әсәрләр. Лирик әсәр үзенчәлекләре.

Г. Тукай, «Пар ат». Пейзаж лирикасы үзенчәлекләре. Туган җиргә мәдхия җырлау.

М. Җәлил, «Кызыл ромашка», «Имән». Совет солдатының батырлыгына дан җырлау. Ватан алдында бурыч хисе.

М. Әгъләмов, «Матурлык минем белән». Матурлык темасы. Матурлыкны күрә белү.

Г. Афзал, «Матурлык эзлим». Дөньяны эстетик күзаллау.

Р. Миңнуллин, «Әни, мин көчек күрдем», «Олы булсам...». Балачак хыялы. Мәрхәмәтлелек хисе.

Ш. Галиев, «Һәркем әйтә дөресен», «Тагын бер «рәхмәт».

6.3.5. Драма әсәрләре.

Т. Миңнулин, «Гафият турында әкият». Әсәрдәге фольклор башлангыч. Әкияти персонажлар.

6.4. Әдәбият теориясе.

Миф, халык авыз иҗаты, фольклор, әкият, тылсымлы әкият, көнкүреш әкияте, хайваннар турындагы әкият, кабатлау, риваять, легенда, табышмак, мәкаль, әйтем, әдәби әкият, әдәби уйдырма, мифик образ, эпос, лирика, драма, образ, лирик герой, мәсәл, эпитет, тема, юмор, төп герой, ярдәмче герой.

## ПЛАНЛАШТЫРЫЛГАН НӘТИҖӘЛӘР

### Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр

Төп гомуми белем бирү баскычында «Туган (татар) телдәге әдәбият» предметын өйрәнү укучыларда түбәндәге шәхескә кагылышлы нәтиҗәләрне формалаштырачак:

1) ***гражданлык тәрбиясе:***

гражданлык бурычларын үтәүгә һәм хокукларын гамәлгә ашыруга әзер булу, башка кешеләрнең хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен хөрмәт итү, гаилә, белем бирү оешмасы, җирле берләшмә, туган як, туган ил тормышында актив катнашу, шул исәптән әдәби әсәрләрдә чагылдырылган вакыйгалар белән чагыштыру аша да;

экстремизм, дискриминациянең теләсә кайсы формаларын кабул итмәү, кеше тормышында төрле иҗтимагый институтларның ролен аңлау, гражданның төп хокукларын, ирекләрен һәм бурычларын, күп мәдәниятле һәм күп конфессияле җәмгыятьтә шәхесара мөнәсәбәтләрнең иҗтимагый нормаларын һәм кагыйдәләрен күзаллау, шул исәптән туган (татар) телдәге әдәбияттан алынган мисалларга таяну аша да;

төрле уртак эшчәнлеккә әзер булу, үзара аңлашуга һәм үзара ярдәмләшүгә омтылу, шул исәптән әдәбияттан алынган мисалларга таяну аша да; мәктәп үзидарәсендә актив катнашу, гуманитар эшчәнлектә катнашырга әзер булу;

***2) патриотик тәрбия:***

татар әдәбияты, шулай ук рус әдәбияты әсәрләрен өйрәнү контекстында күп мәдәниятле һәм күп конфессияле җәмгыятьтә Россия гражданлыгы тәңгәллеген аңлау, туган телне (татар телен) һәм туган (татар) телдәге әдәбиятны, Россия Федерациясенең һәм үз төбәгеңнең тарихын, мәдәниятен өйрәнү белән кызыксыну;

Ватаныбыз Россиянең казанышларына, фәнгә, сәнгатькә, спортка, технологияләргә, халыкның хәрби батырлыкларына һәм хезмәттәге казанышларына, шул исәптән сәнгать әсәрләрендә чагылдырылганнарына да, зур әһәмият бирү;

Россия символларын, дәүләт бәйрәмнәрен, тарихи, табигый мирасны һәм һәйкәлләрне, илебездә яшәүче төрле халыкларның гореф-гадәтләрен хөрмәт итү, аларның татар әдәбиятында чагылдырылуына игътибар бирү;

***3) рухи-әхлакый тәрбия:***

әдәби әсәрләрдә персонажларның үз-үзен тотышын һәм гамәлләрен бәяләп, әхлакый сайлау ситуацияләрендә әхлакый кыйммәтләр һәм нормаларга таянырга юнәлеш бирү;

үз-үзеңне тоту һәм гамәлләреңне, шулай ук башка кешеләрнең үз-үзләрен тотышы һәм гамәлләрен аларның нәтиҗәләрен исәпкә алып, әхлакый һәм хокукый нормалар позициясеннән бәяләргә әзер булу;

җәмгыятьтә кабул ителмәгән гамәлләрне тулысынча кире кагу, шәхси һәм иҗтимагый киңлек шартларында шәхеснең иреге һәм җаваплылык;

***4) эстетик тәрбия:***

үз халкың һәм башка халыклар сәнгатенең барлык төрләрен, традицияләрен һәм иҗатын кабул итү, сәнгатьнең, шул исәптән өйрәнелә торган әдәби әсәрләрнең эмоциональ тәэсирен аңлау;

аралашу һәм үзеңне чагылдыру чарасы буларак матур әдәбият һәм мәдәниятнең мөһимлеген аңлау;

Россия һәм дөнья сәнгатенең кыйммәтен, этник мәдәни традицияләрнең һәм халык иҗатының ролен аңлау;

сәнгатьнең төрле төрләрендә үзеңне чагылдырырга омтылыш;

***5) физик тәрбия, сәламәтлек һәм эмоциональ иминлек культурасын формалаштыру:***

тормыш һәм уку тәҗрибәсенә таянып, тормыш кыйммәтләрен аңлау, үз сәламәтлегенә җаваплы карау һәм сәламәт яшәү рәвеше (сәламәт туклану, гигиена кагыйдәләрен үтәү, дөрес оештырылган эш һәм ял режимы, даими физик активлык) алып бару;

начар гадәтләрнең (спиртлы эчемлекләр, наркотиклар куллану, тәмәке тарту) һәм физик-психик сәламәтлеккә башка зыян салу формаларын аңлау һәм кире кагу, шул исәптән интернет-мохиттә куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәү:

стресслы ситуацияләргә, үзгәрүчән социаль, информацион һәм табигать шартларына җайлашу, шул исәптән үз тәҗрибәсеннән чыгып һәм алга таба максатлар да куеп, үзеңне һәм башкаларны битәрләми кабул итә белү сәләтенә ия булу;

әдәби әсәрләрдән алынган мисалларга таянып, үзеңнең һәм башкаларның эмоциональ халәтен аңлау, үз эмоциональ халәтең белән идарә итә алу осталыгы, рефлексия күнекмәсе формалашкан булу, әдәби геройларның гамәлләрен бәяләү аша үзеңнең, башкаларның хаталану хокукы булуын тану;

***6) хезмәт тәрбиясе:***

технологик һәм социаль юнәлештәге практик мәсьәләләрне (гаилә, мәктәп, шәһәр, төбәк кысаларында) хәл итүдә актив катнашу максатын кую, мондый эшчәнлекне башлап җибәрү, планлаштыру һәм мөстәкыйль башкара алу сәләтенә ия булу;

өйрәнелгән предмет белемнәрен куллануга һәм әдәби әсәрләрдә геройларның эшчәнлеге белән танышуга да нигезләнеп, һөнәрләрне һәм хезмәт төрләрен гамәли яктан өйрәнү белән кызыксыну;

уңышлы һөнәри эшчәнлек өчен гомер буе белем алуның әһәмиятен аңлау һәм моның өчен кирәкле күнекмәләр булдыру һәм үстерү;

һөнәри мохиткә яраклаша белү; хезмәтне һәм хезмәт эшчәнлеге нәтиҗәләрен хөрмәт итү, шул исәптән татар фольклоры һәм әдәбияты әсәрләрен өйрәнгәндә дә, шәхси һәм иҗтимагый мәнфәгатьләрне, ихтыяҗларны исәпкә алып, бе-

лем алуның һәм тормыш планнарының индивидуаль траекториясен аңлы рәвештә сайлау һәм төзү;

***7) экологик тәрбия:***

иҗтимагый һәм табигать фәннәреннән алган белемнәрне әйләнә-тирә мохит өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл итү, гамәлләрне планлаштыру һәм аларның әйләнә-тирә мохит өчен мөмкин булган нәтиҗәләрен бәяләүдә куллануга юнәлдерү;

экологик культура дәрәҗәсен күтәрү, экология мәсьәләләренең глобаль характерын һәм аларны чишү юлларын аңлау;

экологик проблемаларны күтәргән әдәби әсәрләр белән танышканда формалашкан карашларга да нигезләнеп, әйләнә-тирә мохиткә зыян китерүче гамәлләрне кире кагу;

табигый, технологик һәм иҗтимагый мохитнең үзара бәйләнеше шартларында гражданин һәм кулланучы буларак үз ролен аңлау, экологик юнәлештәге практик эшчәнлектә катнашырга әзер булу;

***8) фәнни танып белү кыйммәтләре:***

үз эшчәнлегендә кеше, табигать һәм җәмгыять үсешенең төп закончалыклары, кешенең табигый һәм иҗтимагый мохит белән үзара бәйләнешләре турындагы фәнни күзаллауларның заманча системасына юнәлгәнлек;

дөньяны танып белү чарасы буларак, тел һәм уку культурасына ия булу;

әдәби белем үзенчәлекләрен исәпкә алып, тикшеренү эшчәнлегенең төп күнекмәләрен үзләштерү, тәҗрибә, күзәтү, эш-гамәлләрне аңлауга юнәлгәнлек һәм шәхси, коллектив иминлеккә ирешү юлларын камилләштерү омтылышына ия булу;

***9) укучының үзгәрүчән социаль һәм табигый мохит шартларына яраклашуын тәэмин итү:***

укучыларның социаль тәҗрибәне, үз яшенең төп эшчәнлегенә туры килә торган иҗтимагый рольләрне, тәртип, нормаларны һәм кагыйдәләрне, төркемнәрдә һәм җәмгыятьтә, шул исәптән гаиләдә, һөнәри эшчәнлек буенча оештырылган төркемнәрдә һәм берләшмәләрдә, шулай ук башка мәдәни мохит кешеләре белән үзара социаль бәйләнеш кы-

саларында иҗтимагый тормыш формаларын үзләштерүе, әдәби әсәр персонажларының социаль рольләрен өйрәнүе һәм бәяләве;

билгесезлек шартларында үзара бәйләнештә эш итү сәләте, тәҗрибә алырга һәм башкаларның белемнәренә таянырга әзер тору, билгесезлек шартларында эш итә алу сәләтенә ия булу, гамәли эшчәнлек аша үзенең компетентлык дәрәҗәсен күтәрү, шул исәптән башка кешеләрдән өйрәнә алу, уртак эшчәнлектә башкаларның тәҗрибәсеннән яңа белемнәр, күнекмәләр һәм компетенцияләргә төшенү;

образларны ачыклау һәм үзара бәйләү күнекмәсе, яңа белемнәр формалаштыру сәләте, билгеле булган һәм моңа кадәр билгесез объектлар һәм күренешләр турында идеяләр, төшенчәләр, гипотезалар тәгъбирләү, үзендә белем һәм компетенцияләрнең җитенкерәмәвен аңлау, үз үсешен планлаштыру;

тотрыклы үсеш концепциясе өлкәсендә төп төшенчәләр, терминнар һәм күзаллаулар белән эш итә белү;

табигать, җәмгыять һәм икътисадның үзара бәйләнешләрен анализлый һәм ачыклый алу;

әйләнә-тирә мохиткә тәэсирне, максатларга ирешү һәм мөмкин булган каршылыкларны җиңүне, глобаль нәтиҗәләрне исәпкә алып, үз гамәлләрен бәяли алу;

стресслы ситуацияне аңлый, тормыш һәм укучы тәҗрибәсенә таянып, дөньяда бара торган үзгәрешләрне һәм аларның нәтиҗәләрен бәяли алу, стресслы ситуацияне кире кагарлык чара күрелергә тиешле чакыру буларак кабул итү, стресслы ситуацияне бәяләү, кабул ителгән карарларны һәм гамәлләрне үзгәртү, килеп туган куркынычларны һәм аларның нәтиҗәләрен тәгъбирләү һәм бәяли алу, төрле юлларын эзләү, билгеле бер ситуациянең уңай ягын таба белү, уңышка ышаныч булмаганда да эшләргә әзер тору.

11.2. Төп гомуми белем дәрәҗәсендә туган (татар) телдәге әдәбиятны өйрәнү нәтиҗәсендә укучыда танып белү универсаль уку гамәлләре, коммуникатив универсаль уку гамәлләре, регулятив универсаль уку гамәлләре, уртак эшчәнлек осталыгы формалаштырылачак.

11.2.1. Танып белү универсаль уку гамәлләренең бер өлеше буларак, укучыда түбәндәге төп логик гамәлләр формалаштырылачак:

объектларның (сәнгати һәм уку текстлары, әдәби геройлар һәм башкалар) һәм күренешләрнең (әдәби юнәлешләр, әдәби-тарихи барыш этаплары) төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү;

классификациянең асыл билгесен раслау һәм әдәби объектларны шуның нигезендә классификацияләү, аларны гомумиләштерү һәм чагыштыруның нигезен гамәлгә кертү, үткәрелгән анализ критерийларын билгеләү;

тәкъдим ителгән мәсьәләне исәпкә алып, карала торган әдәби фактларда һәм текстны күзәтүләрдә закончалыкларны һәм каршылыкларны ачыклау, аларны ачыклау өчен, критерийлар тәкъдим итү;

куелган уку бурычын чишү өчен, кирәкле җитешмәгән мәгълүматны ачыклау;

әдәби күренешләр һәм әдәби барышны өйрәнгәндә, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен ачыклау, дедуктив һәм индуктив фикерләүне, охшашлык буенча фикерләүне кулланып нәтиҗәләр чыгару, аларның үзара бәйләнешләре турында гипотезалар тәгъбирләү;

текстларның төрле төрләре белән эшләү барышында уку мәсьәләсен чишү ысулын мөстәкыйль сайлау (чишелешнең берничә вариантын чагыштыру, мөстәкыйль билгеләнгән критерийларны исәпкә алып, иң кулаен табу).

11.2.2. Танып белү универсаль уку гамәлләренең бер өлеше буларак укучыда түбәндәге төп тикшеренү гамәлләре формалаштырылачак:

әдәби белем алуда сорауларны танып белүнең тикшеренү коралы буларак куллану;

ситуациянең, объектның реаль һәм кирәкле халәте арасындагы аерманы теркәргә ярдәм иткән сорауларны тәгъбирләү һәм нәрсә бирелгән, нәрсәне эзләп табасы икәнлеген мөстәкыйль билгеләү;

үз фикерләреңнең һәм башкалар фикерләренең дөреслеге турында гипотеза формалаштыру, үз позицияңне, фикереңне дәлилләү;

әдәбиятта өйрәнү объектының үзенчәлекләрен, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен һәм объектларның үзара бәйлелеген билгеләүдә мөстәкыйль төзелгән план буенча зур булмаган тикшеренү үткәрү;

тикшеренү (эксперимент) барышында алынган мәгълүматның кулланырлык һәм ышанычлы булуына бәя бирү;

үткәрелгән күзәтү, тәҗрибә, тикшеренү нәтиҗәләре буенча гомумиләштерүләрне һәм нәтиҗәләрне мөстәкыйль рәвештә формалаштыру; алынган нәтиҗәләрнең һәм гомумиләштерүләрнең ышанычлылыгын бәяләү коралларына ия булу;

вакыйгаларның алга таба үсешен һәм аларның бердәй яки охшаш ситуацияләрдә нинди нәтиҗәләргә китерәчәген фаразлау, шулай ук аларның яңа шартларда һәм контекстларда, шул исәптән әдәби әсәрләрдә дә үсеше турында фаразлар тәкъдим итү.

11.2.3. Танып белү универсаль уку гамәлләренең бер өлеше буларак, укучыда мәгълүмат белән эш итүнең түбәндәге күнекмәләре формалаштырылачак:

чыганаклардан тәкъдим ителгән уку бурычын һәм бирелгән критерийларны исәпкә алып, әдәби һәм башка төр мәгълүматны эзләү һәм сайлау барышында төрле инструментлар, ысуллар һәм табу алымнарыннан файдалану;

төрле формада һәм төрдә тәкъдим ителгән әдәби һәм башка мәгълүматны сайлау, анализлау, системалаштыру һәм шәрехләү;

төрле мәгълүмат чыганакларында (бер үк идеяне, версияне раслаучы яки кире кагучы) охшаш аргументлар табу;

әдәби һәм башка төр мәгълүматны тәкъдим итүнең оптималь формасын мөстәкыйль рәвештә сайлау һәм гади схемалар, диаграммалар, башка графика һәм аларның комбинацияләре ярдәмендә чишелергә тиешле уку мәсьәләләрен тасвирлап бирү;

әдәби һәм башка төр мәгълүматның ышанычлылыгын укытучы тәкъдим иткән яки мөстәкыйль рәвештә тәгъбир ителгән критерийлар буенча бәяләү;

мәгълүматны нәтиҗәле истә калдыру һәм системалаштыру.

11.2.4. Коммуникатив универсаль уку гамәлләренең бер өлеше буларак, укучыда түбәндәге коммуникатив күнекмәләр формалаштырылачак:

фикерләрне кабул итү һәм тәгъбирләү, аралашу шартларына һәм максатларына бәйле рәвештә эмоцияләрне белдерү, үзеңне (үз фикереңне) телдән һәм язма текстларда белдерү;

аралашуның вербаль булмаган чараларын тану, социаль билгеләрнең мәгънәсен аңлау, конфликтлы ситуацияләрнең алшартларын белү һәм тану, әдәби әсәрләрдә охшашлыклар табып, конфликтлы ситуацияләрне көйләү, сөйләшүләр алып бару;

башка кешеләрнең ниятләрен аңлау, әңгәмәдәшкә ихтирамлы мөнәсәбәт күрсәтү һәм үзеңнең килешмәгәнлегеңне әдәп белән тәгъбир итү, уку диалогы һәм (яки) дискуссия барышында фикер алышуда төп тема буенча сораулар бирү;

уку мәсьәләсен хәл итүгә юнәлдерелгән идеяләрне җиткерү, аралашуда үзара җылы мөнәсәбәтләрне саклау; үз фикерләреңне әңгәмәдә катнашучыларның фикерләре белән чагыштыру, карашларның аермасын һәм охшашлыгын ачыклау;

үткәрелгән тәҗрибә (әдәби эксперимент, тикшеренү, проект) нәтиҗәләрен башкалар алдында тәкъдим итү;

презентация бурычларын һәм аудитория үзенчәлекләрен исәпкә алып, чыгыш форматын мөстәкыйль сайлау, аңа ярашлы иллюстратив материаллар кулланып, телдән һәм язма текстлар төзү.

11.2.5. Регулятив универсаль уку гамәлләренең бер өлеше буларак, укучыда түбәндәге үз-үзеңне оештыру күнекмәләре формалаштырылачак:

матур әдәбиятта сурәтләнгән ситуацияләрне анализлап, әсәрне өйрәнгәндә һәм тормышта очраган ситуацияләрне хәл итү өчен, проблемаларны ачыклау;

карарлар кабул итүдә төрле алымнарга (индивидуаль, төркемдә карар кабул итү, төркем тарафыннан карарлар кабул итү) юнәлеш тоту;

уку мәсьәләсен (яки аның бер өлешен) чишү алгоритмын мөстәкыйль төзү, булган ресурсларны һәм үз мөмкин-

лекләрен исәпкә алып, уку мәсьәләсен чишү ысулын сайлау, тәкъдим ителгән чишелеш вариантларын дәлилләү;

эш-гамәлләр планын (билгеләнгән чишү алгоритмын гамәлгә ашыру планын) төзү, һәм өйрәнелә торган әдәби объект турында яңа белемнәр алуны исәпкә алып, тәкъдим ителгән алгоритмны үзгәртү;

сайлау һәм карар чыгаруда җаваплылыкны үз өстеңә алу.

11.2.6. Регулятив универсаль уку гамәлләренең бер өлеше буларак, укучыда үз-үзеңне контрольдә тоту, эмоциональ интеллект, үзеңне кабул итү һәм башкаларны тануда түбәндәге күнекмәләр формалаштырылачак:

әдәби белем алуда үз-үзеңне контрольдә тоту, үз-үзеңне мотивацияләү һәм рефлексия ысулларын үзләштерү;

уку ситуациясенә тиешле бәя бирү һәм аны үзгәртү планын тәкъдим итү;

контекстны исәпкә алу һәм уку мәсьәләсен чишү барышында килеп чыгарга мөмкин кыенлыкларны алдан күрү, чишелешне үзгәрүчән шартларга яраклаштыру;

эшчәнлек нәтиҗәләренә ирешү (ирешмәү) сәбәпләрен исәпкә алу, алган тәҗрибәгә бәя бирү, билгеле бер ситуациядә уңай якны таба белү;

яңа шартлар һәм үзгәрешле ситуацияләр, билгеләнгән хаталар, килеп чыккан кыенлыклар нигезендә эшчәнлеккә төзәтмәләр кертү, нәтиҗәнең максат һәм шартларга туры килүен бәяләү;

башкаларның хисләрен һәм үз хисләреңне аеру, атау һәм алар белән идарә итү;

хисләрнең сәбәпләрен ачыклау һәм анализлау;

матур әдәбият үрнәкләрен анализлау барышында үзеңне башка кеше урынына куя белү, башкаларның мотивларын һәм ниятләрен аңлау;

үз хисләрен белдерү ысулын көйләү;

әдәби геройларның үзара мөнәсәбәтләре турында уйланып, башка кешегә, аның фикеренә аңлы рәвештә карау;

хаталанырга хокукыңны һәм башкаларның да шундый ук хокукын тану;

үзеңне һәм башкаларны гаепләмичә кабул итү;

үзеңә һәм башкаларга карата ачык булу;

тирә-юньдәге бар нәрсәне контрольдә тота алмауны аңлау.

11.2.7. Укучыда уртак эшчәнлекнең түбәндәге күнекмәләре формалаштырылачак:

туган (татар) телдәге әдәбият дәресләрендә конкрет мәсьәләләрне хәл итү барышында командалы (парларда, төркемнәрдә, күмәк) һәм индивидуаль эшнең өстенлекләрен аңлау һәм файдалану, куелган бурычны хәл иткәндә, үзара хезмәттәшлекнең төркем формаларын куллану зарурлыгын аңлау;

бергәләп уку эшчәнлегенең максатын аңлау, аңа ирешүдә күмәк рәвештә гамәлләр булдыру: рольләрне бүлү, килешүләр төзү, бергәләп эшләү барышы һәм аның нәтиҗәсе турында фикер алышу;

берничә кешенең фикерен гомумиләштерә белү, җитәкчелек итүгә, йөкләмәләрне үтәүгә, буйсынуга әзерлек күрсәтү;

туган (татар) телдәге әдәбият дәресендә бергәләп эшне оештыруны планлаштыру, үз ролен билгеләү (аралашуда катнашучыларның теләкләрен һәм мөмкинлекләрен исәпкә алып), команда әгъзалары арасында бурычларны бүлеп бирү, төркем эшендә (сөйләшү, фикер алышу, «аң штурмы» һәм башкалар) катнашу;

эштә үз өлешеңне башкару, үз юнәлешең буенча сыйфатлы нәтиҗәгә ирешү һәм үз гамәлләреңне команданың башка әгъзалары белән координацияләү;

әдәбият дәресләрендә катнашучылар тарафыннан тәгъбир ителгән критерийларга таянып, гомуми нәтиҗәгә керткән өлешеңнең сыйфатын бәяләү;

нәтиҗәләрне башта куелган бурыч белән һәм һәр команда әгъзасының нәтиҗәләргә ирешүгә керткән өлеше белән чагыштыру, җаваплылык өлкәсе белән уртаклашу һәм төркем алдында хисап бирергә әзерлек күрсәтү.

11.3. Туган (татар) телдәге әдәбиятны өйрәнүнең предмет нәтиҗәләре.

5 нче сыйныфны тәмамлаганда, укучы:

*татар телендә белем бирү мәктәпләрендә түбәндәгеләрне өйрәнә:*

сәнгатьле итеп укырга һәм программа тарафыннан билгеләнгән әсәрләрне һәм аларның өлешләрен яттан сөйләргә

(әсәрнең эмоциональ эчтәлеген дөрес тапшырырга, шигъри ритмны төгәл кабатларга);

туган (татар) телдәге әдәбиятта бирелгән әсәрләргә үз мөнәсәбәтен формалаштырырга, аларны бәяли белергә, үз фикерләрен текстка таянып нигезләргә;

фольклор һәм матур әдәбиятның төп жанрларын (миф, татар халык әкиятләре һәм әдәби әкият, табышмак, мәкаль, әйтем, риваять, легенда, бәет, дастан, мәсәл, хикәя, повесть, лирик шигырь, пьеса) аера белергә; проза текстларын шигъри текстлардан аерып карарга;

укылган әсәрләр турында эмоциональ фикер белдерергә, әсәр турында тәэсирләре белән уртаклашырга;

укыган әсәрнең темасын, төп фикерен билгеләргә һәм тәгъбирләргә;

әсәрләрнең эчтәлеге нигезендә сораулар бирергә;

әсәр нигезендә фикер алышуда катнашырга;

әдәби геройны характерларга, аны авторның тасвирламасы һәм сәнгатьле детальләр нигезендә телдән сурәтләргә, гамәлләрен бәяләргә;

әдәби текстның эчтәлеген сөйләргә (тәфсилле, кыскартып);

әдәби әсәрнең гади планын төзергә;

үзләштергән әдәби-теоретик төшенчәләрне (образ, эпос, лирика, драма, тема, идея, юмор һ.б.) әдәби әсәрне анализлау барышында кулланырга;

үз язма текстын (күләме 20—30 сүздән ким түгел) булдырырга: әдәби әсәрне белү һәм аңлау белән бәйле сорауга киңәйтелгән җавап бирергә.

*рус телендә белем бирү мәктәпләрендә түбәндәгеләрне өйрәнәчәк:*

сәнгатьле итеп укырга һәм программада билгеләнгән әсәрләрне һәм аларның фрагментларын яттан сөйләргә (әсәрнең эмоциональ эчтәлеген дөрес тапшырырга, шигъри ритмны төгәл кабатларга);

фольклор һәм матур әдәбиятның төп жанрларын (миф, татар халык әкиятләре һәм әдәби әкият, табышмак, мәкаль, әйтем, риваять, легенда, бәет, дастан, мәсәл, хикәя, повесть,

лирик шигырь, пьеса) аера белергә; проза текстларын шигъри текстлардан аерып карарга;

укылган әсәрләргә эмоциональ фикер белдерергә, әсәр турында тәэсирләрне уртаклашырга;

укыган әсәрнең темасын, төп фикерен билгеләргә һәм тәгъбирләргә;

әсәрләрнең эчтәлеге нигезендә сораулар бирергә;

әсәр буенча фикер алышуда катнашырга;

текстка таянып, үз фикерен дәлилләргә;

әдәби геройны характерларга, гамәлләрен бәяләргә;

әдәби текстның эчтәлеген сөйләргә (тәфсилле, кыскартып);

әдәби әсәрнең гади планын төзергә;

үзләштергән әдәби-теоретик төшенчәләрне (образ, эпос, лирика, драма, тема, идея, юмор һ.б.) әдәби әсәрне анализлау барышында кулланырга;

үз язма текстын (күләме 20—30 сүздән ким түгел) булдырырга: әдәби әсәрне белү һәм аңлау белән бәйле сорауга киңәйтелгән җавап бирергә.

## ТЕМАТИК ПЛАНЛАШТЫРУ

### 5 класс — 34 сәгать (рус телендә белем бирү мәктәпләренә)

| № | Тема | Эчтәлек | Сәг. саны | Укучылар эшчәнлегенең төп төрләре |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1 | Мифлар (2 сәгать) | Ияләр — мифик образлар (Татар халык мифлары. «Җил иясе җил чыгара» мифы) | 1 | Уку: мифларны мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Фольклор әсәренең тексты белән эшләү: мифларны һәм мифик образларны анализлау, мифларның тема һәм проблемаларын билгеләү, төп фикерен ачыклау.<br>Әдәби-теоретик төшенчәне үзләштерү |
| | | Тавык турында да миф бар (Мифларның килеп чыгышы, аларны классификацияләү. «Тавык» мифы) | 1 | |
| **Халык авыз иҗаты** | | | | |
| 2 | Әкиятләр (5 сәгать) | Әкиятләрдә дә дөреслек бар (Халык байлыгы буларак татар халык авыз иҗаты. Әкиятләр. Татар халык әкияте «Хәйләкәр Төлке») | 2 | Уку: текстны сәнгатьле уку.<br>Әдәби әсәрне интерпретацияләү: рольләр буенча уку.<br>Фольклор әсәре тексты белән эшләү: укыган әкиятнең эчтәлегенә кагылышлы сорауларга җавап бирү, тексттагы вакыйгалар эзлеклелеген билгеләү, әсәр героена бәя бирү.<br>Текстны сөйләү: план буенча сөйләү. |
| | | Кемнән үрнәк алырга? (Татар халык әкияте «Өч кыз») | 1 | |
| | | Каршына Ак бүре килеп чыккан... (Татар халык әкияте «Ак бүре») | 1 | |

*Таблицаның дәвамы*

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | Тылсымның көче нәрсәдә? (Татар халык әкияте «Ак бүре») | 1 | Әдәби-теоретик төшенчәләр белән эшләү: әкиятләрне төрләргә аеру, халык әкиятләренә хас үзенчәлекләрне, сәнгати алымнары ачыклау; халык авыз иҗаты турында күзаллау формалаштыру, халык иҗаты әсәрләренең үзенчәлекләрен аңлау.<br>Проект эше: проект эшен башкару өчен кирәкле материалны җыю һәм системага салу, фикер алышу, чыгыш ясау |
| | | Әкияткә рәсем ясау җиңелме? (Проект эше: «Татар халык әкиятләренә рәсемнәр ясаучы рәссам-иллюстраторлар» / «Татар халык әкиятләренә иллюстрацияләр» альбомын төзү) | 1 | |
| 3 | Легендалар һәм риваятьләр (2 сәгать) | Хыял һәм чынбарлык (Татар халык легендалары. «Зөһрә кыз» легендасы) | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп риваятьләрне һәм легендаларны уку.<br>Риваятьләр һәм легендаларның эчтәлеген сөйләү.<br>Уку әңгәмәсе: сорауларга җаваплар бирү, тарихи вакыйгаларның һәм мифологик образларның легендаларда, риваятьләрдә ничек чагылуын һәм аларның вазифасын билгеләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләр белән эшләү: легенда, риваять төшенчәләрен үзләштерү, риваять һәм легенда жанры үзенчәлекләрен билгеләү, риваятьләрнең легендалардан аермаларын ачыклау |
| | | Хәтер — рухи байлык (Риваятьләр. «Шәһәр нигә Казан дип аталган» риваяте) | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 4 | Татар халык авыз иҗатының кече жанрлары (4 сәгать) | Кемнең теленә сандугач кунган? (Татар халык авыз иҗатының кече жанрлары. Мәкаль һәм әйтемнәр) | 1 | Тыңлау: сөйләмне ишетеп, тыңлап аңлау, таныш булмаган сүзләрнең мәгънәләрен ачыклау.<br>Фольклорның кече жанрларын һәм алар арасындагы аермаларны билгеләү.<br>Фольклор әсәренең тексты белән эшләү: текстлардагы образлар системасы билгеләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләр белән эшләү: табышмаклар, мәкальләр, әйтемнәр төшенчәләрен үзләштерү, мәкальләрнең, табышмакларның төп жанр үзенчәлекләрен билгеләү.<br>Күнегү: мәкальләр һәм әйтемнәрне язма һәм телдән сөйләмдә куллану.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү өчен булган сорауларга телдән җавап бирү.<br>Тикшерү эше: контроль эшне башкару (тест) |
| | | Әйтем — сөйләмнең бизәге, мәкаль — сөйләмнең җиләге (Мәкаль һәм әйтемнәр) | 1 | |
| | | Табышмак — тапкырлар уены (Табышмаклар) | 1 | |
| | | Үткән материалны кабатлау. Контроль эш. | 1 | |
| **Татар әдәбияты** | | | | |
| 5 | Әдәби экият (автор экияте) (2 сәгать) | Экиятне кем иҗат итә? (Әдәби экият. Г. Тукай «Шүрәле») | 1 | Уку: экиятләрне мәгънәләрен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Әдәби әсәренең тексты белән эшләү: әсәр текстын белү һәм аңлауны ачыклый торган сорауларга җаваплар бирү, текстка таянып үз фикерләрен нигезләү. |
| | | Матурлык һәм батырлык (Г. Тукайның «Шүрәле» экияте) | 1 | |

*Таблицаның дәвамы*

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | | Әсәр героена бәя: автор сурәтләвенә нигезләнеп, телдән, геройның портретын тасвирлау.<br>Текстны сөйләү: план буенча әсәрнең эчтәлеген сөйләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләр белән эшләү: әдәби әкиятнең жанр үзенчәлекләрен билгеләү, әдәби әкиятләрдәге халык авыз иҗаты традицияләрен, мотивларын, образларын ачыклау.<br>Сәнгатьле уку: текстны сәнгатьле итеп яттан сөйләү |
| 6 | Проза (5 сәгать) | Һәр гамәлнең эзе кала (Эпик әсәр үзенчәлекләре. Хикәя жанры. Ф. Яруллинның «Кояштагы тап» хикәясе) | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: текстның исеме, рәсемнәр, ачкыч сүзләр аша әсәрнең эчтәлеген фаразлау, вакыйгалар эзлеклелеген билгеләү, геройның хисләрен билдерә торган сурәтләү чараларын билгеләү.<br>Үз карашын формалаштыру һәм дәлилләү.<br>Әсәр героена бәя: аның гамәлләрен бәяләү.<br>Текстны сөйләү: җентекләп сөйләү. |
| | | Яхшылык итсәң үзеңә кайтыр (Ф. Яруллинның «Зәңгәр күлдә ай коена» хикәясе) | 1 | |
| | | Кеше нинди була? (Дәрдемәнднең «Богдай» хикәясе) | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Үткән теманы кабатлау Иҗади эш: шәхси кичерешләргә нигезләнеп инша язу | 2 | Әдәби-теоретик төшенчәләр белән эшләү: хикәянең жанр үзенчәлекләрен ачыклау.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җаваплар бирү.<br>Иҗади эш: сочинение язу |
| 7 | Мәсәл (2 сәгать) | Эш сөйгәнне ил сөя (Мәсәл жанры. Г. Тукай. «Умарта корты һәм чебеннәр») | 1 | Уку: текстны мәгънәләрен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Уку-укыту әңгәмәсе: исемнең эчтәлек белән бәйләнешен табу, укылган текстның эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү.<br>Әсәр героена бәя.<br>Рәсемнәр һәм иллюстрацияләр буенча сөйләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләр белән эшләү: мәсәлнең жанр үзенчәлекләрен билгеләү |
| | | Яшь акылның тәҗрибәсе аз (Ә. Исхакның «Карт имән белән яшь егет» мәсәле) | 1 | |
| 8 | Лирик әсәрләр (8 сәгать) | Туган җирдә һәр нәрсә изге (Лирик әсәр үзенчәлекләре.<br>Г. Тукай. «Пар ат») | 1 | Уку: шигырь текстын мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Уку әңгәмәсе: укыган шигырьнең эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын билгеләү, сәнгатьлелек чараларын тексттан табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм тексттагы әһәмиятен билгеләү, шигъри әсәрләрдәге хис-тойгы тудыру чараларын бәяләү. |
| | | Батырлыкка чәчәкләр дә баш ия (М. Җәлилнең тормыш юлы һәм иҗаты. «Кызыл ромашка» шигыре) | 1 | |
| | | «Мин тез чүкмәм, катыйль, синең алда» М. Җәлил (Иҗади эш: Х. Якуповның «Хөкем алдыннан» картинасы буенча хикәя төзү) | 1 | |

*Таблицаның дәвамы*

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | Дөнья кайчан матур? (М. Әгъләмов. «Матурлык минем белән») | 1 | Текстны сөйләү: укылган эпизодлар һәм өлешләр буенча сүзләр ярдәмендә сурәт тудыру (тасвирлама сөйләм). Шигъри сөйләмнең чәчмә сөйләмнән аермасын билгеләү. Сәнгатьле уку: текстны сәнгатьле итеп яттан сөйләү. Иҗади эш: рәсемгә карап хикәя төзү. Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җаваплар бирү |
| | | Балачак хыялы (Р. Миңнуллин. «Әни, мин көчек күрдем») | 1 | |
| | | Дөреслек без күрә алганнан зуррак була аламы? (Ш. Галиев. «Һәркем әйтә дөресен») | 1 | |
| | | Үткән теманы кабатлау | 1 | |
| 9 | Драма әсәрләре (3 сәгать) | Син әкият яратасыңмы? (Драма әсәрләре. Т. Миңнуллин. «Гафият турында әкият») | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку. Әдәби әсәрне интерпретацияләү: рольләр буенча уку. Уку әңгәмәсе: укыган текстның эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү, үз фикерен булдыру, сөйләү өчен мөстәкыйль рәвештә план төзү. Әдәби әсәрнең тексты белән эшләү: вакыйгалар эзлеклелеген билгеләү, әсәр геройлары турында фикер йөртү. Текстны сөйләү: кыскача сөйләү. Әдәби-теоретик төшенчәләр белән эшләү: драма әсәренең жанр үзенчәлекләрен билгеләү |
| | | Нәрсә яхшы, нәрсә начар? (Т. Миңнуллинның «Гафият турында әкият»е) | 1 | |
| | | Әкият хакыйкатькә якынайта (Т. Миңнуллинның «Гафият турында әкият»е) | 1 | |
| 10 | Нәтиҗәләр чыгару (1 сәгать) | Үткән материалны кабатлау. Нәтиҗәләр чыгару. | 1 | Комплексלы кабатлау. Гомумиләштерү, сорауларга җаваплар бирү. Контроль тест биремнәрен үтәү |

## 5 класс — 34 сәгать
## (татар телендә белем бирү мәктәпләренә)

| № | Тема | Эчтәлек | Сәг. саны | Укучылар эшчәнлегенең төп төрләре |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1 | Мифлар (2 сәгать) | Ияләр — мифик образлар (Татар халык мифлары. «Җил иясе җил чыгара» мифы) | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп мифларны уку.<br>Фольклор әсәренең тексты белән эшләү: мифларны һәм мифик образларны анализлау, мифларның тема һәм проблемаларын билгеләү, төп фикерен ачыклау.<br>Әдәби-теоретик төшенчәне үзләштерү |
| | | Тавык турында да миф бар (Мифларның килеп чыгышы, аларны классификацияләү. «Тавык» мифы) | 1 | |
| **Халык авыз иҗаты** | | | | |
| 2 | Әкиятләр (5 сәгать) | Әкиятләрдә дә хакыйкать бар (Халык байлыгы буларак татар халык авыз иҗаты. Әкиятләр. «Хәйләкәр Төлке» әкияте) | 1 | Уку: текстны сәнгатьле уку.<br>Әдәби әсәрне интерпретацияләү: рольләр буенча уку.<br>Фольклор әсәре тексты белән эшләү: укыган әкиятнең эчтәлегенә кагылышлы сорауларга җавап бирү, тексттагы вакыйгалар эзлеклелеген билгеләү, әсәр героена бәя бирү.<br>Текстны сөйләү: план буенча сөйләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләр белән эшләү: әкиятләрне төрләргә аеру, халык әкиятләренә хас үзенчәлекләрне, сәнгати алымнары |
| | | Кемнән үрнәк алырга?(Татар халык әкияте «Өч кыз») | 1 | |
| | | Каршына Ак бүре килеп чыккан... (Татар халык әкияте «Ак бүре») | 1 | |

*Таблицаның дәвамы*

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | Тылсымның көче нәрсәдә? (Татар халык әкияте «Ак бүре») | 1 | ачыклау; халык авыз иҗаты турында күзаллау формалаштыру, халык иҗаты әсәрләренең үзенчәлекләрен аңлау.<br>Проект эше: проект эшен башкару өчен кирәкле материалны җыю һәм системага салу, фикер алышу, чыгыш ясау. |
| | | Әкияткә рәсем ясау җиңелме? (Проект эше: «Татар халык әкиятләренә<br>рәсемнәр ясаучы рәссам-иллюстраторлар» / «Татар халык әкиятләренә иллюстрацияләр» альбомын төзү) | 1 | |
| 3 | Легендалар һәм риваятьләр (2 сәгать) | Хыял һәм чынбарлык (Татар халык легендалары. «Зөһрә кыз», «Кәккүк каян барлыкка килгән?» легендалары) | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп риваятьләрне һәм легендаларны уку.<br>Риваятьләр һәм легендаларның эчтәлеген сөйләү.<br>Уку-укыту әңгәмәсе: сорауларга җаваплар бирү, тарихи вакыйгаларның һәм мифологик образларның легендаларда, риваятьләрдә ничек чагылуын һәм аларның вазифасын билгеләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләр белән эшләү: легенда, риваять төшенчәләрен үзләштерү, |
| | | Хәтер — киләчәк сакчысы (Риваятьләр. «Шәһәр нигә Казан дип аталган?», «Тургай моңы» риваятьләре) | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | риваять һәм легенда жанры үзенчәлекләрен билгеләү, риваятьләрнең легендалардан аермаларын ачыклау |
| 4 | Татар халык авыз иҗатының кече жанрлары (4 сәгать) | Кемнең теленә сандугач кунган? (Мәкаль һәм әйтемнәр) | 1 | Тыңлау: сөйләмне ишетеп, тыңлап аңлау, таныш булмаган сүзләрнең мәгънәләрен ачыклау.<br>Фольклорның кече жанрларын һәм алар арасындагы аермаларны билгеләү.<br>Фольклор әсәренең тексты белән эшләү: текстлардагы образлар системасы билгеләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләр белән эшләү: табышмаклар, мәкальләр, әйтемнәр төшенчәләрен үзләштерү, мәкальләрнең, табышмакларның төп жанр үзенчәлекләрен билгеләү.<br>Күнегү: мәкальләр һәм әйтемнәрне язма һәм телдән сөйләмдә куллану.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү өчен булган сорауларга телдән җавап бирү.<br>Тикшерү эше: контроль эшне башкару (тест) |
| | | Әйтем — сөйләмнең бизәге, мәкаль — сөйләмнең җиләге (Мәкаль һәм әйтемнәр) | 1 | |
| | | Табышмак — тапкырлар уены (Татар халык авыз иҗатының кече жанрлары. Табышмаклар) | 1 | |
| | | Үткән материалны кабатлау. Контроль эш. | 1 | |
| **Татар әдәбияты** | | | | |
| 5 | Әдәби әкият (автор әкияте) (2 сәгать) | Әкиятне кем иҗат итә? (Әдәби әкият. Г. Тукай «Шүрәле») | 1 | Уку: әкиятләрне мәгънәләрен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Әдәби әсәренең тексты белән эшләү: әсәр текстын белү һәм аңлауны ачыклый торган сорауларга җаваплар бирү, текстка таянып үз фикерләрен нигезләү. |
| | | Матурлык һәм батырлык (Г. Тукайның «Шүрәле» әкияте) | 1 | |

*Таблицаның дәвамы*

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | | Әсәр героена бәя: автор сурәтләвенә нигезләнеп, телдән, геройның портретын тасвирлау.<br>Текстны сөйләү: план буенча әсәрнең эчтәлеген сөйләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләр белән эшләү: әдәби әкиятнең жанр үзенчәлекләрен билгеләү, әдәби әкиятләрдәге халык авыз иҗаты традицияләрен, мотивларын, образларын ачыклау.<br>Сәнгатьле уку: текстны сәнгатьле итеп яттан сөйләү |
| 6 | Проза (6 сәгать) | Һәр гамәлнең әзе кала (Эпик әсәр үзенчәлекләре. Хикәя жанры. Ф. Яруллинның «Кояштагы тап» хикәясе) | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: текстның исеме, рәсемнәр, ачкыч сүзләр аша әсәрнең эчтәлеген фаразлау, вакыйгалар эзлеклелеген билгеләү, геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын билгеләү.<br>Үз карашын формалаштыру һәм дәлилләү.<br>Әсәр героена бәя: аның гамәлләрен бәяләү.<br>Текстны сөйләү: җентекләп сөйләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләр белән эшләү: хикәянең жанр үзенчәлекләрен ачыклау.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җаваплар бирү.<br>Иҗади эш: сочинение язу |
| | | Яхшылык итсәң үзеңә кайтыр (Ф. Яруллинның «Зәңгәр күлдә ай коена» хикәясе) | 1 | |
| | | Кеше нинди була? (Дәрдемәнднең «Богдай» хикәясе) | 1 | |
| | | Урман кызы ак томан сыман... (Г. Сабитовның «Урман кызы Таңсылу» хикәясе) | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Күңелендә юкның күзе юк (Г. Сабитовның «Урман кызы Таңсылу» хикәясе) | 1 | |
| | | Үткән теманы кабатлау. Иҗади эш: шәхси кичерешләргә нигезләнеп инша язу | 1 | |
| 7 | Мәсәл (2 сәгать) | Эш сөйгәнне ил сөя (Мәсәл жанры. Г. Тукай. «Умарта корты һәм чебеннәр») | 1 | Уку: текстны мәгънәләрен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Уку әңгәмәсе: исемнең эчтәлек белән бәйләнешен табу, укылган текстның эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү.<br>Әсәр героена бәя.<br>Рәсемнәр һәм иллюстрацияләр буенча сөйләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләр белән эшләү: мәсәлнең жанр үзенчәлекләрен билгеләү |
| | | Яшь акылның тәҗрибәсе аз (Ә. Исхакның «Карт имән белән яшь егет» мәсәле) | 1 | |
| 8 | Лирик әсәрләр (8 сәгать) | Туган җирдә һәр нәрсә изге (Лирик әсәр үзенчәлекләре. Г. Тукай. «Пар ат») | 1 | Уку: шигырь текстын мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку.<br>Уку әңгәмәсе: укыган шигырьнең эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын билгеләү, сәнгатьлелек чараларын тексттан табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм тексттагы әһәмиятен билгеләү, шигъри әсәрләрдәге хис-тойгы тудыру чараларын бәяләү. |
| | | Батырлыкка чәчәкләр дә баш ия (М. Җәлилнең тормыш юлы һәм иҗаты. «Кызыл ромашка» шигыре) | 1 | |

*Таблицаның дәвамы*

| 1 | 2 | 3 | | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | «Мин тез чүкмәм, катыйль, синең алда» М. Җәлил (Иҗади эш: Х. Якуповның «Хөкем алдыннан» картинасы буенча хикәя төзү) | 1 | Текстны сөйләү: укылган эпизодлар һәм өлешләр буенча сүзләр ярдәмендә сурәт тудыру (тасвирлама сөйләм).<br>Шигъри сөйләмнең чәчмә сөйләмнән аермасын билгеләү.<br>Сәнгатьле уку: текстны сәнгатьле итеп яттан сөйләү.<br>Иҗади эш: рәсемгә карап хикәя төзү.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җаваплар бирү |
| | | Эшең калсын мең яшәрлек имән булып (М. Җәлилнең «Имән» шигыре) | 1 | |
| | | Дөнья кайчан матур? (М. Әгъләмов. «Матурлык минем белән», Г. Афзал «Матурлык эзлим») | 1 | |
| | | Балачак хыялы (Р. Миңнуллин. «Әни, мин көчек күрдем», «Олы булсам...») | 1 | |
| | | Дөреслек без күрә алганнан зуррак була аламы? (Ш. Галиев. «Һәркем әйтә дөресен») | 1 | |
| | | Рәхмәтне саныйлармы? (Ш. Галиевнең «Тагын бер «рәхмәт» шигыре)<br>Үткән теманы кабатлау | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 9 | Драма әсәрләре (2 сәгать) | Син әкият яратасыңмы? (Драма әсәрләре. Т. Миңнуллин. «Гафият турында әкият») | 4 | Уку: мәгънәсен аңлап, сәнгатьле итеп уку. Әдәби әсәрне интерпретацияләү: рольләр буенча уку. Уку-укыту әңгәмәсе: укыган текстның эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү, үз фикерен булдыру, сөйләү өчен мөстәкыйль рәвештә план төзү. Әдәби әсәрнең тексты белән эшләү: вакыйгалар эзлеклелеген билгеләү, әсәр геройлары турында фикер йөртү. Текстны сөйләү: кыскача сөйләү. Әдәби-теоретик төшенчәләр белән эшләү: драма әсәренең жанр үзенчәлекләрен билгеләү |
| | | Әкият хакыйкатькә якынайта (Т. Миңнуллинның «Гафият турында әкият»е) | 1 | |
| 10 | Нәтиҗәләр чыгару (1 сәгать) | Үткән материалны кабатлау Контроль эш. Нәтиҗәләр чыгару | 1 | Комплекслы кабатлау. Гомумиләштерү, сорауларга җаваплар бирү. Контроль тест биремнәрен үтәү |

## ДӘРЕСЛЕК БЕЛӘН ЭШЛӘҮ ТӘРТИБЕ

5 нче сыйныф, башлангыч сыйныфта өйрәнгәннәргә нигезләнеп, әдәби әсәрне сәнгати яктан кабул итү һәм аның үзенчәлекләрен аңлау, анализлауга керешү чоры. Ул янәшә кую, чагыштыру һәм нәтиҗәләр ясау юлы белән башкарыла. Укучы әсәрнең эчке структур өлешләрен, алар арасындагы бәйләнеш үзенчәлекләрен аңлауга ирешергә тиеш.

Укучыларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, әдәби әсәрне өйрәнү укытучы җитәкчелегендә оештыруга, әсәрнең тиешле урыннарын сыйныфта укуга, максатка яраклаштырып алдан әзерләнгән сораулар ярдәмендә материалны бергәләп үзләштерүгә ирешү яхшы. Балаларны кызыксындыру, сөйләмнәрен дөрес оештыру һәм телләрен баету максатыннан аудио, видеоязмаларга мөрәҗәгать итү, аерым әсәрләрне сәхнәләштерү, образларның асылын ачуда рәсем сәгате ярдәменә таяну уңышлы алым булып тора.

Дәреслекнең төзелеше, материалның күләме, фәнне өйрәнү өчен кирәкле төшенчәләр белән таныштыру яңа калыпка салынды. Дәреслектәге материал телне бик аз белгән укучыдан алып, югары әзерлекле укучының да ихтыяҗын канәгатьләндерә ала, ягъни дәреслек ике төрле мәктәпне (татар һәм рус телендә белем бирүче мәктәпләрне) күздә тотып төзелде. Шул рәвешле, әлеге дәреслектә төрле дәрәҗәдә өйрәнелә торган материаллар аерылып тора. Татар телендә белем бирүче мәктәп укучылары өчен алар өстәмә рәвештә дәреслекнең чите буйлап график сурәт (пунктирлар) ярдәмендә билгеләнә. Ике дәрәҗәгә аерып бирү әсәр ахырыннан соң килгән сорау-биремнәрдә дә чагылыш таба. Телне белү һәм әдәби үсеш дәрәҗәләрен исәпкә алып татар телендә белем бирүче мәктәп укучылары өчен әдәбият материалда чагыштырмача күләмлерәк тәкъдим ителә.

Укытучы өчен методик әсбапта предметны тирәнтен өйрәнү буенча киңәшләр, аерым темалар зәңгәр төс белән билгеләнә.

Дәреслектәге биремнәр, аеруча нигез өлешендәгеләре, теманы үзләштерүдә артык кыенлык тудырмаска тиеш. Тирәнтен өйрәнүчеләр өчен булган өстәмә материаллар, сорау-би-

ремнәр укучыларның иҗади мөмкинлекләрен, билгеле бер әдәби-теоретик төшенчәләрне аңлау дәрәҗәләрен күздә тотып төзелде.

Тексттан соң бирелгән сүзлекчәдә таныш булмаган сүз, аның татар телендәге синонимы (синоним булмаган очракта — урыны буш калдырылган) һәм рус теленә тәрҗемәсе бирелә.

Дәреслектә сүз белән эшләү максатыннан әдәби текстларда очраган фразеологизмнарга, канатлы сүзләргә, образлы гыйбарәләргә аңлатма махсус рубрикада күрсәтелеп бара.

Әдәбият дәресләрендә халыкның матди һәм рухи кыйммәтләре белән танышу аша буыннан буынга тапшырыла торган тарихи, мәдәни, әхлакый һәм эстетик тәҗрибәне актив үзләштерү алып барыла. Шул рәвешле, әдәбиятны сүз сәнгате буларак өйрәнгәндә укучыларда туган телдәге әдәбиятны милли мәдәниятнең бер өлеше итеп аңлау белән бәйле мәдәният белеме компетенциясе формалаша. Этномәдәни материал яңа УМКларда туган (татар) телдәге әдәбиятны өйрәнүнең барлык этапларында да тәкъдим ителә, моны дәреслекләрнең эчтәлегендә дә ачык күреп була. Мәсәлән, укучылар әдәби-тарихи материал белән танышкан вакытта, комментарий-аңлатмалар, шул исәптән теге яки бу вакыйга, мәдәни объект, күренеш яки төшенчә турында тарихи мәгълүматлар да бирелә. Бу укучыларның танып белүгә кызыксынуларын арттыруга, шул исәптән татар халкының мәдәнияте, тарихы турында белемнәрне киңәйтүгә ярдәм итә. Моннан тыш, биредә милли мәдәниятнең халык тарихы белән генә түгел, ә гомумән ил тарихы белән дә үзара бәйләнеше күзәтелә.

Дәреслектә милли-мәдәни һәм тарихи характердагы комментарийлар әдәби әсәрләрне уку барышында бирелеп бара. Әдәби текстта очрый торган, теге яки бу сәбәпләр аркасында укучыларга таныш булмаган аерым сүзләр, милли-мәдәни компонентлы төшенчәләр әлеге рубрикада урын ала. Беренче чиратта архаизмнар, тарихи сүзләр, татар халкының һәм гомумән Россиянең ерак үткәнендә булган төшенчә-күренешләр турында сүз бара. Комментарийлар укучыларны төрле сәнгать әсәрләре белән таныштыру максатыннан да тәкъдим ителә. Милли-мәдәни компонент дәреслектәге иллюстрация-

ләрдә сурәтләнгән киемдә, бизәнү әйберләрендә, көнкүрештә, йортларның бизәлешендә, интерьерда чагылыш тапкан.

Дәреслектә урын алган «Бу кызыклы», «Файдалы фикер» рубрикалары белән танышу укучыларның дөньяга карашларын, белемнәрен киңәйтер дип өметләнәбез.

«Шәхесләребез» рубрикасында татар халкы тарихы, сәнгате, әдәбиятына зур өлеш керткән шәхесләребез турында кыска гына гомуми күзәтү ясала. Дәреслектә программа кысаларында өйрәнүне күздә тоткан аерым язучыларыбызның тормыш юлы һәм иҗатын киңрәк яктыртуга урын бирелә. (Укучыларны таныштыру максатыннан, төрле чорда яшәгән күренекле шәхесләребезнең биографиясенә бәйле фотоархив белән https://photo.miras.info/№ сылтамасы буенча кереп танышырга мөмкин.)

Дәреслек заман укучысына гына түгел, заман укытучысына да яраклаштырылды. Аның тулы электрон варианты, видеодәресләр, өстәмә материалны табу өчен чыганаклар һәм методик ярдәмлек тә шуңа хезмәт итә. Дәреслекнең электрон вариантында, төп материал белән беррәттән, һәр дәрестә куллану өчен өстәмә заманча материаллар урын алды: рәсемнәр, интерактив форматтагы эш төрләре, биремнәр һ.б. Текст белән эшләгәндә, электрон дәреслектәге аудиоязмаларны тыңлатып була.

Дәреслектәге уку материалы өлешчә видеодәресләр форматында да тәкъдим ителә. 5 нче сыйныф өчен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы сайтында урнаштырылган видеороликларның эчтәлеге Федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләренә туры килә, һәм алар федераль белем бирү программалары нигезендә эшләнгән. Видеодәресләрнең төп максаты — укучыларны яңа материал белән таныштыру, аны презентация яки анимация чаралары ярдәмендә аңлату. Бу видеоязмалардан дәресләрдә дә, дистанцион укытуда материалны мөстәкыйль үзләштерү барышында да файдаланырга мөмкин. Шулай ук укучылар белән дәрестән тыш эшләгәндә дә, аларны уңышлы кулланып була.

Әлеге видеодәресләр һәм шулай ук туган (татар) телдәге әдәбиятны уку-укыту барышында файдаланыла торган нор-

матив документлар, федераль эш программалары, дәреслекләрнең электрон вариантлары, методик әсбаплар, медиаматериаллар, татар балалар әдәбияты антологиясе белән «Мәгърифәт» медиаплатформасында (https://magrifat.antat.ru) танышырга мөмкин.

## ДӘРЕС ЭШКӘРТМӘЛӘРЕНЕҢ ҮРНӘКЛӘРЕ[1]

Методик ярдәмлектә бирелгән дәрес үрнәкләре укытучыга бары юнәлеш бирү һәм бу дәрестә игътибардан читтә калмаска тиешле төп моментларны искәртүне генә максат итә, ләкин дәрестә әлеге үрнәкләрдәгечә генә эш итеп булмый, чөнки сыйныфтагы укучыларның гомум һәм шәхси мөмкинлекләре исәпкә алынырга тиеш. Әсәрне уку, сүзлек белән эшләү, сорауларга җавап бирү, әңгәмәнең ни рәвешле үткәрелүе укытучы ихтыярында. Өстәмә сорау-биремнәр төзегәндә, әңгәмәне үзе сайлаган темага оештырганда, ул үзе теләгәнчә эшли ала. Шуңа күрә дәрес үрнәкләрендә бу өлешкә киң тукталмадык.

**Тема**:Ияләр — мифик образлар (Татар халык мифлары. «Җил иясе җил чыгара» мифы).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — экологик культура дәрәҗәсен күтәрү, экология мәсьәләләренең глобаль характерын һәм аларны чишү юлларын аңлау; табигатьнең көче, бөеклегенә төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, чишү юлларын билгеләү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен ачыклау; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү, үз фикерләреңне әңгәмәдә катнашучыларның фикерләре белән чагыштыру.

*Предмет нәтиҗәләр* — татар халык мифлары турында мәгълүматлы булу; «Җил иясе җил чыгара» мифының эчтәлеген белү, идеясен аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 5 нче сыйныф : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова

[1] Аерым дәрес үрнәкләре берләштереп тәкъдим ителә.

Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 5—9.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

1. Исәнләшү.
2. Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Дәрес кереш сүздән башланып китә. Дәреслектә авторларның укучыларга мөрәҗәгате бирелә. Шулар белән таныштырганнан соң, «Мифлар» темасына кереп китәбез. Шулай ук бу очракта видеодәрес материалыннан файдаланырга мөмкин.

Алга таба бу этапны *Сез ничек уйлыйсыз, җилне мичкәдә саклап буламы*? дигән сорау белән дәвам итәбез. Укучылар «юк» дигән очракта, «Элек борынгы заманнарда кешеләр саклап була дип белгәннәр, чөнки үзләреннән башка да ниндидер мифик затлар яшәгәнлегенә, аларның кеше тормышында катнашы булуына ышанганнар», дигән фикерне җиткерәбез.

Алга таба бирем тәкъдим итәбез: «Без бүген көнне төн алыштыруның сәбәбен фәнни яктан аңлата алабыз. Элек исә кешеләр бу күренешне башкача аңлатканнар. Хәзер үзебезне борынгы кеше итеп күз алдына китереп, тәкъдим ителгән сүзләрдән көннең ни өчен төн белән алышынуын төшендереп карыйк», дип төркемнәргә берләшеп шул турыда 5—6 җөмләлек хикәя төзергә куша алабыз. Укучыларга түбәндәге сүзләр тәкъдим ителә:

*Күк, Күк илаһы, Кояш, Йолдызлар, Ай, төнлә, көндез, йокы, караңгы, якты.*

Укучылар төзегән хикәяләр тыңлана. Шуларның берсе түбәндәгечә булырга мөмкин: *Борынгы заманнарда гел көн, якты булган, төн булмаган. Беркөн Кояш Күк илаһына: «Бик арыдым, ял итәр идем», — дип зарланган. Күк илаһы күк җисемнәрен үзенә җыеп әмер кылган: «Кояш көндез чыгып, көне буе җирне яктырта. Бар дөньяга нур бөркеп,*

*җылылык бирә. Аның вазифасы бик авыр. Ул бик арый, аңа ял итү мөмкинлеге дә бирергә кирәк. Без төнлә күккә Айга чыгарга кушыйк. Ул Кояшны төнгә алыштырып торыр. Кешеләргә бөтенләй караңгы булмасын өчен, яктыртып торыр. Аңа күңелсез булмасынга, иптәшкә йолдызлар чыгар». Ай белән йолдызлар риза булганнар. Ә кояш, төнлә йоклап ял итеп торганнан соң, яңадан күккә чыга торган булган, аның яктыртуы тагын да көчлерәккә әйләнгән.*

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алдагы этапта сөйләгәннәргә нигезләнеп, дәреснең максатлары билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Укучылар мифлар белән беренче тапкыр очраша. Әлегә кадәр аерым мифологик хикәятләрне ишеткән булсалар да, әлеге жанр белән чагыштырмача тирәнтен танышу, аның үзенчәлекләренә төшенү нәкъ менә 5 нче сыйныфта башлана. Укучылар алдына *Нәрсә ул миф?* дигән сорауга җавап табу максаты куела. Алга таба мифлар белән танышкач, *Миф тагын нинди жанрларга охшаган? Мифларны алардан ничек аерырга?* дип куелган сораулар да мифларның үзенчәлекләрен танып белүдә ярдәм итә.

Мифология ул — борынгыларның дөньяга карашы, яшәешнең асылын күзаллауның иң борынгы формасы. Элек-электән кешеләр бөтен табигатьне җанландырганнар, шулар нигезендә ияләр уйлап чыгарганнар һәм мәҗүси илаһлар барлыкка килгән. Кеше үзенең табигать белән берлеген аңлаган һәм уртак тел табарга тырышкан.

Иң элек укучылар мифларның уйлап табылган, реаль фактларга нигезләнмәгән булуын аңларга тиешләр. Шулай ук укучыларга миф геройлары да чынлыкта булмый торган затлар булуын җиткерергә кирәк. Укучылар бу әсәрләрдә төрле сәер мифик затлар (Су иясе, Шүрәле), алыплар (Алып-батыр, Зур кешеләр), Илаһлар (Күк илаһы, Җир илаһы) хәрәкәт итүен аңлыйлар.

Татар мифларын өйрәнү «Җил иясе җил чыгара» мифы белән танышудан башлана. Мифны укыганчы, Интернет челтәрендә тәкъдим ителә торган видеоролик күрсәтергә

мөмкин. Бу очракта видеодәрес материалын да файдалана алабыз, әлеге миф буенча төшерелгән видеоролик биредә дә урын алган.

Җил иясенә характеристика биргәндә, аның төс-кыяфәтен күзаллауда дәрестәге иллюстрация ярдәмгә килә ала.

Теманы өйрәнү барышында «Милли-мәдәни һәм тарихи мирасыбыздан» рубрикасында бирелгән мәгълүмат белән таныштырып була. Сөйләшүнең дәвамы итеп рәссамчы, сынчы Әхсән Фәсхетдинов һәм аның иҗат җимешләре белән таныштыру файдалы. Бу вакытта укучыларның мисал итеп китерелгән ияләрне күзаллауларын рәссамның күзаллавы белән чагыштыру да отышлы. Татар мәктәбе укучыларыннан нинди ияләр турында ишеткән булуларын, аларның сыйфатлары турында да сораштырып була.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Бу этапта дәреслектәге 5—6 нчы сорауларга җавап бирү рәвешендә чынбарлыкта җилнең ничек барлыкка килүе турында фикер алышу үткәреп була.

«Жил иясе җил чыгара» мифында җилнең ничек барлыкка килүе турында сөйләнелә. Фәндә бу табигать күренеше башкача аңлатыла. Җил — һава агымының хәрәкәте. Диңгезләр, кара урманнар, эссе чүлләр өстендә һава бертуктаусыз хәрәкәт итә. Җылы һава өскә күтәрелә, ә салкын һава аста кала. Шулай итеп, Җир шарында өзлексез һава алмашы бара: бер урыннан икенче урынга күчә. Шуннан җил барлыкка килә. Борынгы кешеләр мондый фәнни мәгълүматларны белмәгәнгә, аны үзләренчә, укылган мифтагыча аңлатырга тырышканнар.

Укучылар мифтагы аңлатманың фәнни аңлатмадан нык аерылуын күрәләр. Аның әкияткә охшатып тасвирлануын билгели алалар. *Җил иясе җил чыгара» мифы кайсы ягы белән әкияткә охшаш дип уйлыйсыз?* дигән сорауны бирәбез. Бу урында укучылар әкияти элементлардан Каф тавын, Җил иясен, җил саклана торган мичкәне, мичкәне ачкач, җил-бураннар башлануын, мичкәнең тишеген ябып куйганнан соң җилнең туктавын күрсәтә алачаклар.

Дәрестә шулай ук Каф тавы турында белешмә бирү отышлы булачак.

**VI. Өйгә эш бирү.**

Дәреслектә миф турындагы мәгълүмат белән танышырга. «Җил иясе җил чыгара» мифын укырга, эчтәлеген сөйләргә өйрәнергә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Тавык турында да миф бар (Мифларның килеп чыгышы, аларны классификацияләү. «Тавык» мифы).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — иҗтимагый һәм табигать фәннәреннән алган белемнәрне әйләнә-тирә мохит өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл итү, гамәлләрне планлаштыру һәм аларның әйләнә-тирә мохит өчен мөмкин булган нәтиҗәләрен бәяләүдә куллануга юнәлдерү; дус, тату яшәүнең әһәмиятен аңлау, башкаларны кайгыртырга кирәклегенә төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү, фикерләрне кабул итү һәм тәгъбирләү.

*Предмет нәтиҗәләр* — татар халык мифлары турында мәгълүматлы булу; «Тавык» мифының эчтәлеген белү, идеясен аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 5 нче сыйныф : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 10—13.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эше тикшерелә.

2. *Сез тавыкның ни өчен суны башын өскә күтәреп эчкәнен беләсезме?* кебек проблемалы сорау белән укучыларны теманы өйрәнүгә этәрәбез.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Дәрестә «Тавык» мифын өйрәнү күздә тотыла. Миф тексты укылганнан соң, түбәндәге сорауларны биреп була:

— *Миф нәрсә турында?* (Тавыкның суны ни өчен башын өскә күтәреп эчүе турында.)

— *Тавык ни өчен башка хайваннардан аерыла?* (Ялкау һәм кире булганга.)

— *Тавык ярдәм сорап кемгә мөрәҗәгать итә?* (Аллага.)

— *Ничек уйлыйсыз, хайваннар Тавыкка җәзаны дөрес биргәннәрме?* (Җәзаны дөрес биргәннәр, чөнки ул бик кире һәм ялкау, башка хайваннарга кое казышканда булышмый, эшләшми. Шуңа күрә сусыз кала.)

— *«Тавык» дигән тексттан мифка хас булган билгеләрне табыйк.* (Хайваннарның дөньяда берәр генә булуы, Алла образы, Тавыкның Алладан ярдәм соравы, Тавыкның суны ни өчен башын күтәреп эчүен аңлату.)

— *«Тавык» мифы кайсы төргә карый?* (Хайваннар турындагы мифка.)

Мифлар арасында хайваннар турында булганнары аерым урын алып тора. Бу төркемдә хайваннарның яшәү рәвеше, физиологик үзенчәлекләре турында аңлатма бирелә. «Тавык» мифы да шундыйлардан. Мондый мифларда хайваннар дөньясы аша дөнья, кешеләр, аларның үзара мөнәсәбәтләре турында күзаллау булдырыла, кешеләр дөньясына кагылышлы мөһим булган тормыш кагыйдәләре ачыла.

Бу кагыйдәләрне «Тавык» мифының текстында табып күрсәтергә, шулар нигезендә мифның төп фикерен билгеләргә кушабыз. Укучылар мифта җәмгыятьтә урнашкан түбәндәге кагыйдәләр күрсәтелә: дус-тату яшәүнең зарурлыгы; бер-береңә ярдәм итеп хезмәттәшлек итү; күмәк эшнең әһәмияте; гаделлекне истә тотып эш итү кебекләре күрсәтәләр.

«Табык» мифының төп фикерен билгеләгән вакытта дус, тату яшәргә, эшчән булырга кирәклеге, үз-үзеңне генә уйламыйча, башкаларны да кайгырту сине барысы да хөрмәт итүгә, бәхеткә ирешергә мөмкинлеге әйтелә.

Табыкның физиологиясе аңа суны бары тик башын өскә күтәргән килеш эчү мөмкинлеген бирә. Табык болай эшләмәсә, һава агымы аның үңәченә эләгә. «Табык» мифында әлеге хәл табыкның үз-үзен тотышы, башка хайваннарга карата мөнәсәбәте белән бәйле тасвирлана. *Борынгы кешеләр бу күренешне мифка нинди образны кертү аша аңлатырга тырышканнар? Ни өчен дип уйлыйсың? Моның белән борынгы кешеләр нәрсә әйтергә теләгәннәр? Мифның тәрбияви ягы нәрсәдә?* (Борынгы кешеләр, Табык белән булган хәлне аңлату өчен, Алла образына мөрәҗәгать иткәннәр. Чөнки Табык шундый кырыс җәзага дучар ителә: ул Алла рөхсәтеннән башка суны йота алмый торган булып кала. Мондый җәза аңа үзен генә кайгыртып, башка хайваннарга булышырга теләмәве өчен бирелә. Борынгы кешеләр шул рәвешле күмәк эшләрдә катнашырга, башкаларга булышырга, бер-береңне кайгыртырга, үзең турында гына уйламаска кирәклеген искәртәләр.)

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Шулай итеп, укучылар мифологик хикәятләрнең темасын, идеясен күрсәтәләр һәм текстта мифның билгеләрен, мифның төрләрен аерып чыгаралар. Нәтиҗәдә укучылар мифны тирәнтен аңлауга ирешәләр, бу белемнәр нигезендә алар мөстәкыйль рәвештә мифка билгеләмә бирә алачаклар.

Моның өчен түбәндәге биремнәрне кулланып була:

1) Мифка караган бу билгеләмәдә дөрес булган фикерләрне билгелә.

Миф — уйдырмага нигезләнгән тылсымлы, могҗизалы, көнкүреш характерындагы әсәр. Мифта хайваннар, үсемлекләр, төрле табигать күренешләренә аңлатма бирелә, Илаһлар тормышы, каһарманнарның яшәеше турында сөйләнә. Мифта яхшылык явызлыкны җиңеп чыга.

Укучылар бу билгеләмәдә бары тик ике фикернең дөрес булуын билгелиләр: мифта хайваннар, үсемлекләр, төрле

табигать күренешләренә аңлатма бирелә һәм Илаһлар тормышы, каһарманнарның яшәеше турында сөйләнә.

2) Мифка билгеләмәне укы. Дөрес булмаган артык фикерне тап.

Миф — уйдырмага нигезләнгән тылсымлы, могҗизалы, көнкүреш характерындагы әсәр. Мифта төрле табигать күренешләренә аңлатма бирелә, хайваннар һәм үсемлекләр, Илаһлар тормышы, каһарманнарның яшәеше турында сөйләнә. Мифның нигезенә тирән мәгънә салына.

Укучылар уйдырмага нигезләнгән тылсымлы, могҗизалы, көнкүреш характерындагы әсәр дигән фикерне сайлап алалар.

2) Түбәндә китерелгән билгеләрдән мифка хас булганнарын сайлап алып, мифка билгеләмә бирегез.

**Сайлап алу өчен сүзләр:** *төрле табигать күренешләренә аңлатма бирелә, хайваннар һәм үсемлекләр турында сөйләнә; яхшылык явызлыкны җиңеп чыга; тарихи геройлар турында сөйләнә; тирән мәгънә салына.*

Теманың ахырында *Мифларның әкият белән уртаклыгы һәм аермалы ягы нинди?* дигән проблемалы сорау тәкъдим ителә. Укучылар бу турыда үз фикерләрен әйтәләр.

**VI. Өй эше бирү.**

Тәкъдим ителгән яки үзләре теләгән тематикага күләме зур булмаган миф иҗат итәргә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Әкиятләрдә дә дөреслек бар (Халык байлыгы буларак татар халык авыз иҗаты. Әкиятләр. «Хәйләкәр Төлке» әкияте).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — татар халкының бай мираслы халык булуын аңлау; хәйләкәрлек, беркатлылык күренешләренең асылына төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — фаразлау, уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; клас-

сификациянең асыл билгесен раслау һәм әдәби объектларны шуның нигезендә классификацияләү, объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен ачыклау; диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, үз фикерен дәлилләп әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — татар халык авыз иҗаты төшенчәсе белән таныш булу; әкиятләр турында мәгълүматлы булу; «Хәйләкәр «Төлке» әкиятенең эчтәлеген белү.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 5 нче сыйныф : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 14—26.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эшен тикшерү. Алдагы дәрестә үткән материалны искә төшерү. «Тавык» мифына караган сорауларга җавап бирү.

2. Укучыларның үзләре теләгән хайван турында иҗат иткән мифологик хикәятләрен тыңлау.

3. Мифларның әкиятләр белән охшаш һәм аермалы якларын барлау.

Шуларга бәйле рәвештә әлеге этапны халык тарафыннан иҗат ителеп, телдән-телгә сөйләнеп килгән әкиятләр турында әңгәмә үткәреп, белгән әкиятләрне искә төшереп үткәрергә мөмкин.

Тагын бер вариант: укучыларга Сабантуй бәйрәме сурәтләнгән рәсем тәкъдим итеп, түбәндәге сорауларны бирәбез:

*Картинада нинди бәйрәм сурәтләнгән?*

*Бу бәйрәм ничек барлыкка килгән дип уйлыйсыз?*

*Бәйрәмнәр халык авыз иҗатынамы яки фольклорга карыймы? Халык авыз иҗаты фольклордан нәрсә белән аерыла? Бу сорауга җавап бирә аласызмы? Бу турыда беләсегез киләме?*

**IV. Уку мәсьәләсен кую.**

Алдагы этапта эшләнгәннәрдән чыгып, дәреснең темасы, максаты билгеләнә.

**V. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Дәреснең төп өлеше иң беренче чиратта укучыларда татар халык авыз иҗаты турында күзаллау булдыруга юнәлдерелгән. Укучылар, башлангыч сыйныфларда алган белемнәренә таянып, әкиятләр, мәкаль-әйтемнәр, табышмаклар, эндәшләр, санамышлар, мәзәкләр турында искә төшерәләр. Татар халык авыз иҗатына аңлатма бирәләр. Аның кеше тормышындагы ролен ачыклыйлар. Фольклордан аермасын күрергә өйрәнәләр. Нәтиҗә буларак, халык авыз иҗаты жанрлары буенча иҗади һәм тикшеренү эше башкаралар.

Татар халык авыз иҗаты турында сөйләшүне түбәндәгечә оештырырга мөмкин. Аңлатмалары белән бирелгән сүзләргә игътибар иттерәбез. Шуларны кушып бер төшенчәгә берләштергәч, нәрсә килеп чыгуын ачыклыйбыз.

Татар — татар халкының авыз иҗаты
Халык — иҗат итүче халык
Авыз — телдән иҗат ителгән
Иҗат — әсәрләр тупланмасы

Татар халык авыз иҗаты — татар халкының телдән сөйләнә торган әсәрләр тупланмасы дигән нәтиҗәне әйттерәбез.

Укучылар халык авыз иҗатының халык тарафыннан телдән иҗат ителеп, халык хәтерендә сакланып килгән чәчмә яки тезмә әсәрләр җыелмасы булуын, халык авыз иҗаты һәр халыкның үткәнен бүгенге белән бәйләп, мәдәни байлыгын чагылдыруын аңларга тиешләр.

Татар халык авыз иҗаты әсәрләрен барлаганда, дәреслектә бирелгән схеманы карауны оештырып була. Бу вакытта *Схемада күрсәтелгән халык авыз иҗаты жанрларының сез кайсыларын беләсез? Кайсыларын укып танышканыгыз бар?* дигән сорау-биремнәрне тәкъдим итәбез.

Бу схемадан укучылар үзләре инде белгән халык авыз иҗаты жанрларын әйтәләр, беренче ишеткән яки таныш булмаган жанрларны алга таба өйрәнәчәкләрен аңлауга ки-

ләләр. Укучыларга билгеле булган жанрларны искә төшерү максатыннан, алдагы биттә материал тәкъдим ителә.

Шулай ук халык авыз иҗаты төшенчәсе белән фольклор төшенчәсе арасында ачыклык кертү сорала.

Халык иҗаты турында сөйләгәндә, фольклор төшенчәсен кулланалар, ләкин ул халык авыз иҗатына караганда киңрәк мәгънәдә аңлашыла, *Сезнеңчә, фольклор нәрсә ул?* дип сыйныфта фикерләшәбез.

*Ничек уйлыйсыз, фольклор үз эченә халыкта иҗат ителгән тагын нинди жанрларны ала?* дигән сорау укучыларга фольклорга телдән сөйләнә торган жанрлар гына кермәвен төшендерә. Шулай итеп, укучылар фольклорга халык авыз иҗатыннан аермалы буларак телдән сөйләнә торган жанрлар гына түгел, ә шулай ук халык биюләре, йолалар, гореф-гадәтләр, бәйрәмнәр, уеннар да керүен аңларга тиешләр. Мисал итеп, дәреслектәге уеннар, өмәләр, биюләр һ.б. фольклор жанрлары турындагы материалны файдаланырга мөмкин. Дәреслектә шулай ук Каюм Насыйри турында мәгълүмат урын алган. Аның белән танышу да укучыларга кызыклы һәм файдалы булачак.

Әлеге темага нәтиҗә ясалганнан соң, алга таба укучылар өчен әкият жанры белән танышу күздә тотыла. Бу дәрес кысаларында «Әкиятләр» темасын өйрәнү дә каралган. Дәреслектә ул аерым зур тема рәвешендә бирелә. Әлеге темага тулаем бирелгән проблемалы сорауга игътибар иттерәбез, укучыларның аңа кагылышлы төрле җавапларын тыңлыйбыз.

Әкият турында аңлатма аңа билгеләмә бирүне, татар халык әкиятләренең үзенчәлекләре, әкиятләрне җыючы галимнәр турында сөйләүне күздә тота.

Алга таба укучылар белән хайваннар турындагы әкиятләр хакында сөйләшү үткәрәбез. Бу вакытта *Сез хайваннар турында тагын нинди татар халык әкиятләрен беләсез? Аларда кайсы хайваннар әкият геройлары булып алынган? Кайсысы турында иң күп әкият иҗат ителгән?* дигән сораулар ярдәм итәр.

«Хәйләкәр Төлке» әкияте белән танышу, аның турында сөйләшү дәреслектә бирелгән сорауларга нигезләнеп алып барыла. Әкият жанрының үзенчәлекләрен барлаган вакытта,

аларда еш очрый торган кабатлау алымына игътибар иттерәбез.

Кабатлау — халык әкиятләрендә еш очрый торган стилистик алым, әкияттә вакыйгаларның, күренешләрнең, сүзләрнең берничә тапкыр кабатлануы. Бу вакыйгалар бер-берсе белән бәйле булалар һәм бөтенлекне саклыйлар. Кабатлау вакыйгаларның эзлеклелеген, үстерелешен һәм әкияти геройларның эш-гамәлләрен, хис-кичерешләрен күрсәтү өчен кирәк, дигән нәтиҗә чыгарабыз.

**VI. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

1. Укылган әкияткә нигезләнеп *Кабатлау әсәрдә ни өчен кирәк?* дигән сорауга җавап табу максатыннан сыйныфта фикер алышабыз. «Хәйләкәр Төлке» әкиятен кабатламыйча укып карарга тәкъдим итәбез. *Нәрсә үзгәрә?* дигән сорауга уйландырабыз.

Укучылар кабатлауның әсәр эзлеклелеген саклау, үстерелешен тәэмин итү, геройларның эш-гамәлләрен, хис-кичерешләрен күрсәтү өчен кирәк булуын билгелиләр. Әкиятне кабатлауларсыз укыгач, әсәрнең бөтенлеге югала, вакыйгалар үстерелми, геройларның гамәлләрен тулаем күреп, аңлап, хис-кичерешләренә төшенеп булмый дигән нәтиҗәгә киләләр.

2. Беркатлылык сыйфаты турында сөйләшү. Бу эшне түбәндәгечә оештырырга мөмкин:

*«Хәйләкәр Төлке» әкиятендә Төлкенең хәйләкәрлеге әкият геройларының нинди сыйфаты белән капма-каршы куела? Түбәндәге сүзләрдән шушы сыйфатны сайлап әйтик:*

*Битарафлык, беркатлылык, гаделлек.*

*Сайлаган төшенчәне ничек аңлыйсыз? Ничек уйлыйсыз, уңай сыйфатмы бу? Ул тормышта кешегә комачау итә аламы? Ни өчен?* Укучылар тарафыннан «Бу — беркатлылык. Кайбер кешеләр тиз ышанучан, беркатлы булалар. Ләкин аларны начар кеше дип әйтеп булмый. Чөнки үзләре беркайчан ялганларга күнекмәгәннәр. Бу әкияттә дә Төлке нәкъ менә шундый беркатлы кешеләрне, хайваннарны алдый. Шуңа күрә хәйлә белән эш иткән кешеләргә тиз ышанырга, беркатлы булырга кирәкми, чөнки әкияттәгечә уңайсыз хәлдә калуың бар» дигән нәтиҗә ясала.

**VII. Өй эше бирү.**

Әкиятне укырга, эчтәлеген сөйләргә өйрәнергә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Кемнән үрнәк алырга? (Татар халык әкияте «Өч кыз»).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — әдәби әсәрләрдә персонажларның үз-үзен тотышын һәм гамәлләрен бәяләп, әхлакый сайлау ситуацияләрендә әхлакый кыйммәтләр һәм нормаларга таянырга юнәлеш бирү; игелеклелек, ата-анага хөрмәт хисенә төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — фаразлау, уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; классификациянең асыл билгесен раслау һәм әдәби объектларны шуның нигезендә классификацияләү, объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү, үз фикерләреңне әңгәмәдә катнашучыларның фикерләре белән чагыштыру.

*Предмет нәтиҗәләр* — «Өч кыз» татар халык әкиятенең эчтәлеген белү, төп фикерне билгели алу.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 5 нче сыйныф : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 26—30.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай эмоциональ халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эше тикшерү. Алдагы дәрестә үткән теманы кабатлау йөзеннән халык авыз иҗатына билгеләмәне, аңа хас үзенчәлекләрне, жанрларны искә төшерәбез.

«Хәйләкәр Төлке» әкиятенең эчтәлеген искә төшерү, әкиятнең төп фикере булып хәйләкәрлекнең җиңүен, беркатлылыкның җиңелүен ассызыклап, гадәттә, әкиятләрдә яхшылык явызлыктан өстен чыга дип «Өч кыз» әкиятеннән өзек тәкъдим итәбез.

*«Тиен Уртанчы кызга чапкан. Уртанчы кыз, бу кайгылы хәбәрне ишеткәндә, киндер суга икән.*

*Тиенгә әйткән:*

*— Һай, — дигән, — әнием янына хәзер үк чыгып йөгерер идем дә бит, менә ярминкәгә киндер сугып өлгертәсем бар иде шул, — дигән. Тиен бик ачуланган да: — Алайса, син гомерең буе киндер сугып кына тор! — дигән.*

*Уртанчы кыз шунда ук үрмәкүчкә әверелгән».*

Алга таба зур булмаган әңгәмә оештырабыз:

*Ничек уйлыйсыз, бу өзектә үрмәкүчкә әйләнгән герой уңаймы яки тискәреме? Ул кайсы әкияттән? Сез бу әкиятне беләсезме, укыганыгыз бармы? Шул әкият белән танышасыгыз киләме?* дигән сораулар ярдәмендә укучыларның кызыксынуын арттырабыз.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Укучылар дәрестә тормыш-көнкүреш әкиятләре белән танышачакларын фаразлыйлар.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

1. «Өч кыз» әкиятен уку һәм анализлау.

Әкият белән танышу укытучының кычкырып укуыннан башлана. Шулай ук электрон дәреслектә әлеге әкиятнең аудиоязмасы бар, беренче тапкыр танышканда, аны да кулланырга мөмкин. Әкиятне тыңлаганнан соң, укучыларның беренчел тәэсирләре турында сораштырабыз. Алга таба әкият тексты укучылар белән бергәләшеп укып чыгыла.

Әлеге әкиятне анализлаганда иң элек, кызларга характеристика бирүгә игътибарны юнәлтәбез. Һәрберсендә булган холык сыйфатларын ачыклыйбыз, гамәлләрен бәялибез. Укучылар Олы һәм Уртанчы кызларның гамәлләрен берничек тә аклап булмаганны аңлыйлар, аларның авыру аналарының хәлен белергә ашыкмауларын, эшләре булуын сәбәп итеп, өйдә калуларын тискәре яктан бәялиләр. Кече кызның

бар эшен ташлап авыру әнисе янына йөгерүен, аңа ярдәмгә ашыгуын билгелиләр, аның киң күңелле, игътибарлы, игелекле булуын күрәләр.

Нәтиҗәдә укучылар әнинең һәркайсыбыз өчен дә иң кадерле кеше булуына, һәр кешенең бурычы — әниләрне олылау, аларга ярдәм итү, аларны хөрмәт итү һәм кадерләү икәнлегенә төшенергә тиеш.

Әкияттә игелеклелек сыйфаты мактала. Әкияттәге төп фикер — кешеләргә, ата-анага карата яхшылык, игелек кыл, шул вакытта сине яратырлар, тормышың да бәхетле булыр.

2. Тормыш-көнкүреш әкиятләренә төшенчә бирү.

Алга таба тормыш-көнкүреш төрендәге әкиятләр турында сөйләшүгә алып чыгабыз. Укытучы әлеге кызларның нинди әкияти геройлар булуын сораштырып, укучылар аларны гадәти кешеләр дип билгелиләр. «Өч кыз» әкиятендә тормышта була торган вакыйгалар турында сөйләнелә. Өч бертуганның өчесе өч төрле, аларның эти-әниләренә төрле мөнәсәбәт күрсәтүе — тормышта очрый торган хәл. Халык авыз иҗатында гадәти тормышта кешеләр арасындагы хәлләр турында сөйләгән әкиятләр булуын әйтәбез, тормыш-көнкүреш әкиятләре дип аталуын ассызыклыйбыз. Монда уйдырмага, могҗизага да урын бирелә. Мондый әкиятләрдә яхшылык һәм яманлык көрәше күрсәтелә. Тормыш-көнкүреш әкиятләрендә ялкаулык, саранлык, куркаклык, наданлык көлкегә алына, тырышлык, уңганлык, киң күңеллелек сыйфатлары мактала, дип бу төрдәге әкиятләрнең үзенчәлекләрен билгелибез.

Алга таба укучылардан шундый әкиятләрдән кайсыларын белүен сораштырабыз. *Ничек уйлыйсың, мондый әкиятләрнең геройлары кемнәр була ала?* дигән проблемалы сорау бирәбез. Укучылар мондый әкиятләрнең зирәк кешеләр, байлар һәм хәерчеләр, бертуганнар, ата-аналар һәм балалар, караклар һ.б. турында булуын билгеләргә тиеш.

Тормыш-көнкүреш әкиятләрендә шул ук вакытта уйдырмага, тылсымга, могҗизага да урын бирелүен билгелибез. Сөйләнелә торган хәлнең әкият булуын раслаучы тылсым элементлары бар. Бу «Өч кыз» әкиятендә тылсымлы күренешләрне укучылардан таптырабыз.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

«Өч кыз» әкиятенә иллюстрацияләр белән эш.

Әлеге әкияткә берничә рәссамыбыз иллюстрацияләр эшләгән. Дәреслектә рәссам Диләрә Нәүрузованың рәсеме урын



Диләрә Нәүрузова рәсеме



Фәридә Хәсьянова рәсеме



Рушан Шәмсетдинов рәсеме

алган. Укучылардан биредә нәрсә сурәтләнгәнен, әкиятнең кайсы өлешенә туры килүен билгеләтәбез.

Алга таба әлеге әкияткә ясалган башка рәссамнарның иллюстрацияләрен карарга тәкъдим итәбез. Аларның охшаш һәм аермалы якларын ачыклатабыз, детальләргә, образларның бирелешенә игътибар юнәлтәбез. Шул рәвешле, укучылар әкият иллюстраторларының иҗаты белән танышалар. Нәтиҗәдә бу бирем укучыларны иҗади эшкә тартачак — алар татар халык әкиятләренә ясалган иллюстрацияләр җыентыгын төзи алачаклар.

**VI. Өй эше бирү.**

1. Әкиятне укырга. Эчтәлеген сөйләргә өйрәнергә.
2. Интернет челтәреннән «Өч кыз» татар халык әкиятенә ясалган иллюстрацияләрне барлап чыгарга, аларны ясаган иллюстратор-рәссамнарны ачыкларга.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: 1. Каршына Ак бүре килеп чыккан... («Ак бүре» татар халык әкияте);

2. Тылсымның көче нәрсәдә? («Ак бүре» татар халык әкияте);

3. Әкияткә рәсем ясау җиңелме (Проект эшен яклау: «Татар халык әкиятләренә рәсемнәр ясаучы рәссам-иллюстраторлар» / «Татар халык әкиятләренә иллюстрацияләр» альбомын төзү).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — үз халкың һәм башка халыклар сәнгатенең барлык төрләрен, традицияләрен һәм иҗатын кабул итү, сәнгатьнең, шул исәптән өйрәнелә торган әдәби әсәрләрнең эмоциональ тәэсирен аңлау; үз көчеңә ышану, башкаларның фикерен хөрмәт итә белү, олыларга ихтирам, яхшылыкның явызлыктан өстен чыгуы турында аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, матур әдәбиятта сурәтләнгән ситуацияләрне анализлап, әсәрне өйрәнгәндә һәм тормышта очраган ситуацияләрне хәл

итү өчен, проблемаларны ачыклау, үзбәя; классификациянең асыл билгесен раслау һәм әдәби объектларны шуның нигезендә классификацияләү, куелган уку бурычын чишү өчен, кирәкле җитешмәгән мәгълүматны ачыклау, әдәбиятта өйрәнү объектының үзенчәлекләрен, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен һәм объектларның үзара бәйлелеген билгеләүдә мөстәкыйль төзелгән план буенча зур булмаган тикшеренү үткәрү; проект нәтиҗәләрен башкалар алдында тәкъдим итү, үз фикерен дәлилләп әйтә белү, фикерләрне кабул итү һәм тәгъбирләү.

*Предмет нәтиҗәләр* — «Ак бүре» татар халык әкиятенең эчтәлеген белү, төп фикерне билгели алу; тема буенча йомгак ясый белү, проект эшен яклау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 5 нче сыйныф : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 30—55.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

1. Исәнләшү.
2. Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерү. Үткән дәрестә өйрәнгәннәрне сораштыру. «Өч кыз» әкиятендә тылсымның урынын билгеләтеп, әлеге төшенчә турында сөйләшү үткәрәбез. Укучыларның тылсымны ничек аңлауларын сораштырабыз. *Сез тылсымга ия булсагыз, ниләр эшләр идегез?* дип, укучыларны теманы өйрәнүгә кызыксындырабыз.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Укучылар дәрестә сүз тылсым турында баруын билгелиләр.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Укучылар тылсымлы әкият укып, аның үзенчәлекләрен күрсәтәләр. Моңа бәйле рәвештә дәресләрдә чагыштырмача

күләмле булган татар халык әкияте «Ак бүре» өйрәнү өчен тәкъдим ителә.

Тылсым турында төшенчә бирәбез: *Тылсым — сихри, могҗизалы көч; аңлап, төшенеп булмаслык сыйфат, як*. Укучылар татар халык авыз иҗатында тылсымлы әкиятләрнең бик күп булуын аңларга тиешләр. Шул очракта үзләре дә мисал китерә алачаклар.

Тылсымлы әкиятләр — хыялга, сергә бай әкиятләр, аларда фантастик элементлар өстенлек итә, геройлар төрле тылсымлы сәләтләргә ия була. Бу әкиятләрдә уңай геройның дию, убырлы карчык, җен-пәри, юха елан, аждаһа кебек мифик персонажлар белән көрәшкә чыгуы турында сөйлибез һәм дәреслектә тәкъдим ителгән әлеге әкияти затлар хакында фикер алышу үткәрәбез.

«Ак бүре» әкиятен өйрәнүгә 2 сәгать вакыт каралган. Әкият — күләме белән зур әсәр. 2 сәгать җитмәгән очракта кыскартып укытабыз, яки өченче дәрескә әкиятләр темасын кабатлау, проектлар яклау дәресенә дә чыгара алабыз. (Татар мәктәпләрендә предметны атнага 2 сәгать вакыт белән укыту очрагында, әкиятне иркенләп өйрәнергә мөмкин, материал күп, 4 сәгатькә дә җитә.)

Әкиятнең күләме аны тулаем дәрестә генә укып чыгу мөмкинлеген бирми, шуңа күрә аерым бер өлешен өйдә укып килергә кушып була.

Әкиятне анализлаган вакытта геройларга характеристика бирү кирәк. Укучылар Олы, Уртанчы малайларның ни өчен шундый хәлгә калуларын аңларга тиешләр, ягъни «Патшаның уллары барысы да батыр, кыюлар, әниләрен эзләргә дип бер дә уйламыйча, икеләнмичә чыгып китәләр. Шулай да патшаның Кече улы зирәгрәк, акыл белән эш итәргә ярата. Һәрвакыт ярдәмгә килергә әзер. Башкаларның фикеренә колак сала, бик игътибарлы һәм ихтирамлы» дигән нәтиҗә ясарга тиеш булалар. Шулай ук егетнең әнисе хакына күп газап-михнәтләргә әзер булуын ассызыклап әйтәбез.

Сөйләшүгә *Ак бүрене тискәре герой дип атап буламы? Ни өчен?* дигән сораулар алып чыга ала. Укучылар, «Ак бүрене тискәре герой дип атап булмый, ул бик зирәк, акыл белән эш итә, төп геройга ярдәм итәргә тырыша, үзенә яхшы

мөнәсәбәттә булганнарга тими, диячәкләр. Патшаның Олы һәм Уртанчы улларын да, табигатькә зыян китермәсеннәр өчен генә, таш сыннарга әйләндерә, энеләре сорагач, шунда ук аларны яңадан кеше сурәтенә кертә» дип, уртак фикергә киләләр.

Тылсымлы әкиятләр темасын дәвам итеп, «Ак бүре» әкиятендә тылсым катнашкан күренешләрне ачыклатабыз. Укучылар «Ак бүре» әкиятендә тылсым күп өлешләрдә катнашуын билгелиләр. Диюнең патша хатынын Каф тавы артына алып китүе, аны эзләп чыгып киткән улларына Ак бүре очравы, аларны таш сыннарга әйләндерүе, Ак бүренең төрле сурәтләргә кереп патша малаена булышуы, патша малаеның Дию белән сугышуы, Диюдән котылгач, өйләренә оча торган машинада кайтулары әкиятнең тылсымлы булуын күрсәтә.

Укучылар әлеге әсәрдә дә кабат Каф тавы белән очрашалар. Мифларны өйрәнгән вакытта бу образ турында алган белемнәрен тулыландыралар, аның турында өстәмә мәгълүмат алалар.

Әсәрнең идеясен билгеләгән вакытта бирелгән мәкальләрдән кайсысы әкиятнең төп фикерен ачып бирүдә ярдәм итүен ачыклата алабыз. Моның өчен түбәндәге мәкальләрне тәкъдим итеп була:


*Батыр үзе өчен туар, кеше өчен үләр.*
*Батырларга юл туры.*
*Батырның башы икәү булмый.*

«Ак бүре» әкиятендәге төп фикерне ачуда «Батырларга юл туры» мәкале ярдәм итә. «Әкияттә бернидән дә курыкмыйча үз максатыңа ирешергә, башкаларга карата игътибарлы, ярдәмчел булырга кирәк» дигән төп фикерне аңлыйбыз.

Әсәрне анализлауга дәреслектәге сорау-биремнәр дә юнәлеш бирә.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Бу дәрестә дә иллюстрацияләр белән эшне дәвам итеп, түбәндәге биремне тәкъдим итәбез: *«Ак бүре» әкиятенә иллюстрацияләрне кара. Аларны кайсы рәссамнар ясаган? Бу рәсемнәрдә Ак бүре нинди булып күз алдына килеп баса?*



Виталий Булатов рәсеме



Диләрә Нәүрузова рәсеме



Рушан Шәмсетдинов рәсеме

Иллюстрацияләрне Виталий Булатов, Диләрә Нәүрүзова, Рушан Шәмсетдинов ясаганнар. Виталий Булатов рәсемендә Ак бүре кешегә охшатып ясалган. Моның өчен рәссам аңа камзул кидергән. Диләрә Нәүрузова рәсемендә ул чын бүрегә охшатып ясалган. Өчесендә дә ул кешегә теләктәшлек итә, кешенең дошманы түгел, ә дусты икәнлеге күренә, дип билгелиләр укучылар.

Йомгаклау дәресендә «Хәйләкәр Төлке», «Өч кыз», «Ак бүре» әкиятләренең эчтәлеге нигезендә укучылар фольклор әсәренең темасын, идеясен ачыклыйлар, текстта әкият билгеләрен күзәтәләр, әкиятнең төрләрен аерып чыгаралар. Шул рәвешле, алар әкиятне тирәннән аңлауга киләләр, бу белемнәр нигезендә мөстәкыйль рәвештә әкияткә билгеләмә бирә алалар.

Укучыларның белемнәрен түбәндәгечә тикшерергә мөмкин.

Әкияткә билгеләмәдә нокталар урынына тиешле фикерләрне сайлап куярга тәкъдим итеп була.

Әкият — ___________ бер жанры. Ул ________________. Әкияттә _________________. Әкият герое_____________________, төрле авырлыкларны җиңеп чыгарга сәләтле кеше буларак сурәтләнә. Әкиятнең ____________ дигән төрләре бар.

Билгеләмәгә кертү өчен фикерләр: *халык авыз иҗатының; аллалар (илаһлар) тормышы турында сөйләнелә; хай-*

*ваннар турында, тормыш-көнкүреш, тылсымлы әкиятләр; үзенчәлекле уйдырмага нигезләнгән тылсымлы, мавҗаралы яки көнкүреш характерындагы эпик сәнгать әсәре; киң күңелле, гадел, юмарт, матур, акыллы, батыр; яхшылык җиңеп чыга; тормыш-чынбарлык турында сөйли торган тылсымлы, мавҗаралы, көнкүреш характерындагы шигъри әсәр.*

Әкиятләрнең билгеләрен барлаганда, аларга үзенчәлекле башлам һәм бетем хас икәнен, аларның, гадәттә, «Борын-борын заманда...» дигән сүзләр белән башланып китүен, бетем дә традицион формада булуын, әкият геройларының күп сынаулар-киртәләрне үтеп ахырда бәхетле тормыш итүләре белән тәмамлануын укылган әкиятләрнең мисалларында билгеләтеп була.

Теманың ахырында *Ни өчен төрле халыкларда эчтәлеге белән охшаш әкиятләр бар?* дигән проблемалы сорау бирелә. Укучылар бу турыда сыйныфта фикерләшәләр. Төрле халык әкиятләрен искә төшереп, аларның сюжет, мотив, образлар ягыннан охшашлыгын күрсәтәләр, шул рәвешле «мәдәниятләр диалогы» принцибы тормышка ашырыла.

Шулай ук бу дәрестә укучыларның алдан әзерләп килергә кушылган проект эшләрен («Татар халык әкиятләренә рәсемнәр ясаучы рәссам-иллюстраторлар» / «Татар халык әкиятләренә иллюстрацияләр» альбомын төзү) яклау күздә тотыла. Укучылар әкиятләр иллюстраторларының иҗаты белән алдагы дәресләрдә таныша башлаганнар иде. Әлеге бирем укучыларны иҗади эшкә тарта: алар татар халык әкиятләренә ясалган иллюстрацияләр җыентыгын төзиләр һәм сыйныфташларның хөкеменә тапшыралар. Өй эше итеп китапханә ресурсларыннан һәм Интернет чыганакларыннан файдаланып, татар халык әкиятләренә ясалган 9—10 иллюстрациядән торган электрон җыентык әзерләргә, аны презентация рәвешендә сыйныфта тәкъдим итәргә кушылган була. Әлеге проектны укучылар күмәкләп (парларда, төркемнәрдә) эшләсәләр, тагын да яхшы була.

**VI. Өй эше бирү.**

Әкитне укырга, эчтәлеген сөйләргә. «Әкиятләр» темасын кабатларга, ошаган бер әкияткә иллюстрация ясап килергә. Аның турында сыйныфта сөйләргә әзерләнергә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Хыял һәм чынбарлык (Татар халык легендалары. «Зөһрә кыз», «Кәккүк каян барлыкка килгән?» легендалары).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — Россия һәм дөнья сәнгатенең кыйммәтен, этник мәдәни традицияләрнең һәм халык иҗатының ролен аңлау; илебездә яшәүче төрле халыкларның гореф-гадәтләрен хөрмәт итү; легендаларның тәрбияви, танып белү көчен аңлау; мәрхәмәтлелек, теләктәшлек, кызгыну хисләренә төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү, үз фикерләреңне әңгәмәдә катнашучыларның фикерләре белән чагыштыру.

*Предмет нәтиҗәләр* — халык авыз иҗаты жанры буларак, легенда төшенчәсен үзләштерү, «Зөһрә кыз», «Кәккүк каян барлыкка килгән?» легендалары буенча сорауларга җавап бирә белү.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 5 нче сыйныф : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 56—62.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Укучыларның халык авыз иҗаты турындагы белемнәренә нигезләнеп, әкиятләргә хас үзенчәлекләрне, гомумән фольклор жанрларын искә төшерергә мөмкин.

«Халык хәтере — хәзинә; чынбарлык та, хыял да бар үзендә», дигән гыйбарәгә нигезләнеп әңгәмә оештыру.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

*Хыял, фантастика белән чынбарлыкның чиге кайда?* дигән сорауны биреп, темага кызыксыну уятабыз. Укучылар дәрестә хыялый, фантастик элементлар кергән әсәрләр турында сүз баруын фаразлый алалар.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Фантастика турында сөйләшү үткәрәбез.

*Укучылар, ничек уйлыйсыз, нәрсә ул фантастика? Фантастик элементлар кергән нинди әсәрләрне беләсез*? дигән сорауларга укучыларның җавапларыннан соң нәтиҗә ясап, фантастикага билгеләмә бирәбез.

Кайчандыр булган яки булуы мөмкин булган эш-хәлләр, вакыйгалар, дөреслеген кире кагып булмый торган нәрсәләр *чынбарлык*, чынбарлыкта булмый торган хәлләр турында сөйләү *фантастика* дип атала.

Бу фикергә мисал итеп түбәндәгеләрне сөйлибез: *Ай Җирдәге кешеләргә төнлә күренә. Ул Җирдән бик еракта урнашкан. Аның өслегендә нәрсәләр барын без ачык күрә алмыйбыз. Ай өслегенең рельефы Җирдән бик аз гына төсмерләнә.*

*Сезнең Айдагы Зөһрә кызга охшаган сурәткә игътибар иткәнегез бармы? Ул анда ничек барлыкка килгән дип уйлыйсыз?*

Дәвам итеп сөйлибез: *Ай түгәрәк чакта аңа карагыз әле. Анда басып торган кызны күрерсез. Ул кайчандыр җирдә яшәгән Зөһрә исемле кыз булган. Үги әнисенең бик рәнҗеткәнен күреп, Ай аны үзенә алган. Зөһрә хәзер Айда яши. Кичләрен ул Җирне күзәтергә чыга.*

*Ничек уйлыйсыз, фантастиканың катнашы бармы монда?* соравын биреп, укучыларга «Зөһрә кыз» исемле легенданы укырга тәкъдим итәбез.

Укучылар легенданы укытучы укуында тыңлый алалар, видеодәрес итеп бирелгән материалны да кулланырга мөмкин. Шулай ук бу текстның аудиоязмасын электрон дәреслектән дә тыңлатырга була.

Әсәрне анализлауга түбәндәге сорау-биремнәр юнәлеш бирә:

*Ай ни өчен Зөһрә кызны үзенә ала?*

*Легендада Айдагы көянтә-чиләкле кыз сурәте булу ничек аңлатыла?*

*Легендада тормышта мөмкин булмаган нинди фантастик вакыйга бар?*

*«Зөһрә кыз» легендасы ничек барлыкка килгән? Моңа нинди күренеш сәбәп булган дип уйлыйсыз?*

*«Зөһрә кыз» легендасының төп фикере нинди?*

Татар мәктәпләрендә бу дәрестә «Күке ничек барлыкка килгән?» легендасын да өйрәнү каралган.

*Сез күке турында нәрсәләр әйтә аласыз?* дип укучыларның әлеге кош турында белгәннәрен ачыклыйбыз.

Легенданы укыганнан соң, аның ничек барлыкка килүе турында фаразлап сөйләтәбез.

Легендада бирелгән төп фикерне ачыклатабыз: эшләнгән эшне үкенү белән генә кире кайтарып, төзәтеп булмый.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

1. Дәреслектә бирелгән күке кошы һәм аның турындагы төрле халык авыз иҗатына караган ышанулар, легендалар хакында «Милли-мәдәни һәм тарихи байлыгыбыз» рубрикасы кысаларында бирелгән мәгълүмат белән танышабыз. Бу вакытта «мәдәниятләр диалогы» принцибы гамәлгә ашырыла. Биредә күке образының рус, белорус халкы фольклорында тасвирлануы карала. Төрки фольклорда бирелешен күзәтү аерым урын алып тора. Башкорт халык легендасы эчтәлеге нигезендә, укучылар төрле халыкларның күке образын төрлечә, шул ук вакытта ниндидер охшашлык белән сурәтләнүен дә билгелиләр.

2. Әлеге этапта легендага хас үзенчәлекләрне укылган текстларга таянып күзәтә алабыз.

Түбәндәге мәгълүматны бирәбез:

Легендалар эчтәлекләре белән төрле-төрле темага карыйлар:

- көнкүреш легендаларында уйдырма вакыйгалар яки хәлләр тормыш-көнкүрешкә бәйләп сөйләнелә;

• төрле хайван һәм кош-кортларның барлыкка килүен, аларга хас билгеләр турында сөйләгән легендалар — зоогоник;

• географик атамаларның килеп чыгышын уйдырмага нигезләп аңлаткан легендалар — топонимик;

• күк җисемнәре белән бәйле темага караганнары космогоник;

• тарихи вакыйга һәм тарихи шәхесләргә багышланганнары тарихи легендалар дип йөртелә.

Шулай ук легенда төрләренә тукталып, әлеге дәрестә өйрәнелгән легендаларның төрен билгеләтәбез.

Укучылар «Зөһрә кыз» легендасын космогоник төргә, «Күке ничек барлыкка килгән?» әсәрен зоогоник легендага кертәләр.

Легендалар һәм риваятьләрне өйрәнгәндә «Милли-мәдәни һәм тарихи мирасыбыздан» рубрикасында бирелгән мәгълүматлар белән танышу файдалы булыр.

**VI. Өй эше бирү.**

Дәреслектән легенда турында мәгълүмат белән танышырга, дәрестә өйрәнелгән легендаларны укырга, эчтәлеген сөйләргә өйрәнергә. Көнкүреш яки топонимик легендаларны табып әзерләп килергә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Хәтер — киләчәк сакчысы (Риваятьләр. «Шәһәр нигә Казан дип аталган?», «Тургай моңы» риваятьләре)

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — Россия Федерациясенең һәм үз төбәгеңнең тарихын, мәдәниятен өйрәнү белән кызыксыну, туган җиргә мәхәббәт хисен аңлау, халык тарихына, аның үткәненә, бүгенгесенә, киләчәгенә хөрмәт хисенә төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — фаразлау, уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, диалог һәм әң-

гәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, монологик сөйләм төзү, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — халык авыз иҗаты жанры буларак, риваять төшенчәсен үзләштерү, «Шәһәр нигә Казан дип аталган?», «Тургай моңы» риваятьләре буенча сорауларга җавап бирә белү.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 5 нче сыйныф : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 63—67.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай эмоциональ халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эшен тикшерү. Үткәннәрне искә төшерү.

2. Казан шәһәре турында мәгълүмат бирү. Казан күренешләре фотосурәтләре белән аралаштырылып бирелсә, уңышлы булыр.

*Казан — меңьеллык тарихы һәм бай мәдәнияте булган шәһәр, Татарстан Республикасының башкаласы. Бүген ул Россиянең иң алдынгы һәм кунакчыл төбәкләренең берсе булып санала.*

*Рәсми юрама буенча, Казанга бер меңнән артык ел элек нигез салынган. 2005 елда Казан шәһәре 1000 еллыгын бәйрәм итте.*

*Казан Иделнең сул ягында, аңа Казансу кушылган төшендә урнашкан. Ул Идел Буе Болгарының төньягында чик буе кальгасы буларак нигезләнгән. Шәһәрнең үсешенә сәүдә юллары киселешендә уңайлы географик урыны булышлык иткән.*

*Казан илнең иң зур икътисади һәм фәнни-белем бирү үзәкләренең берсе булып тора. Россиянең спорт башкаласы да. Хәзерге вакытта Казан — халыкара форматтагы иң зур ярышларны кабул итәргә сәләтле шәһәр.*

Укучыларның Казан шәһәре турында тагынниләр белгәнен ачыклап, әңгәмә үткәреп була.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

*Ә сез беләсезме, ни өчен бу шәһәр Казан дип аталган?* соравы белән укучыларны теманы өйрәнүгә кызыксындырабыз.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

1. «Шәһәр ни өчен Казан дип аталган?» риваяте укып чыгыла.

Әсәрнең тексты белән эшләгәндә, түбәндәге сорау-биремнәрне тәкъдим итеп була:

*«Шәһәр ни өчен Казан дип аталган?» риваятен хикәяләүче нинди максат белән сөйли?*

*Риваятьтә сөйләнгән вакыйгаларга син ышандыңмы? Тормышта мондый хәлләр булырга мөмкин дип уйлыйсыңмы?*

*Риваятьтә тормышта мөмкин булмаган, фантастик вакыйга бармы?*

Сорауларга җавап бирү барышында укучылар әлеге риваятьтә булган яки булуы мөмкин булган эш-хәлләрнең, вакыйганың фантастик, тормышта булмаслык хәл белән кушылып китүен билгелиләр.

Татар мәктәпләрендә әлеге дәрес кысаларында шулай ук «Тургай моңы» риваятен өйрәнү дә күздә тотыла. Әсәрне анализлаганда, *«Тургай моңы» риваятен иҗат итәргә чынбарлыктагы нинди күренеш сәбәп булган дип уйлыйсың?; «Тургай моңы» риваятендә сөйләнгән тарихи фактны билгеләә; «Тургай моңы» риваятендәге төп фикерне билгелә* кебек сорау-биремнәр ярдәмгә килә.

Укучылар бу вакытта Болгар иленә дошман явы һөҗүм итүен, халкыбызның җырлары тургай моңыдай матур булуын, аларда тургай моңы чагылуын билгелиләр.

2. Риваять турында төшенчә бирү.

*Риваять* — гарәп телендә «хәбәр, хикәят» дигән сүз. Риваятьләр — халыкның хәтере, үткәндәге вакыйгаларны алдагы буыннарга җиткерү алымы. Риваятьләр дөреслеккә бик якын тора.

Риваятьләрдә төрле тарихи фактлар, тарихи шәхесләрнең язмышлары, җирле атамаларның килеп чыгышы турында сөйләнә. Кызыксындыру һәм тәэсирле итү өчен, төрле фольклор мотивлары, образлары файдаланыла.

Риваятьләрне тематик яктан тарихи һәм топонимик төрләргә аералар:

- тарихи риваятьләрдә тарихта булган вакыйгалар, аларда катнашкан тарихи шәхесләр турында сөйләнә;
- топонимик риваятьләрдә төрле атамаларның ничек барлыкка килгәнлеге аңлатыла.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Тема ахырында бирелгән *Ни өчен легенда һәм риваять дигән ике төрле жанр барлыкка килгән?* дигән проблемалы сорау легендалар белән риваять арасында охшаш һәм аермалы якларны күрсәтергә ярдәм итә. Мисал өстендә аңлатып бу билгеләрне үзләреннән таптырабыз. Укучы текстның эчтәлегеннән чыгып, аның легенда яки риваять жанрына карагылыгын әйтә ала.

Мәсәлән, риваятьләрдә булган яки булуы мөмкин булган эш-хәлләр, вакыйгалар турында сөйләнә. Ул чынбарлыкка якын итеп аңлатыла. Эчтәлек, нигездә, дөреслеккә туры килә.

Легендаларда вакыйгалар фантастик, тормышта булмаслык хәлләр белән кушылып китә. Ул фантастик юл белән аңлатыла. Эчтәлек чынбарлыкка туры килми.

Алга таба нәтиҗә ясала: Риваятьләрдә сөйләнгән эш-хәлләр чынбарлыкка якын тора, төп вакыйга тормышчан фактлар белән раслана, легендаларда сөйләнгән күренешләр чынбарлык белән бәйләнешле булса да, фантастик хәлләр белән үрелеп килә. Шулай да тыңлаучы тарафыннан ул чыннан да булган вакыйга кебек кабул ителә.

**VI. Өй эше бирү.**

Үзең теләгән темага зур булмаган (7—8 җөмләдән торган) легенда яки риваять иҗат итәргә.

Болгар дәүләте турында мәгълүмат әзерләп килергә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** 1) Кемнең теленә сандугач кунган? (Татар халык авыз иҗатының кече жанрлары. Мәкаль һәм әйтемнәр);

2) Әйтем — сөйләмнең бизәге, мәкаль — сөйләмнең җиләге (Мәкаль һәм әйтемнәр).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — татар әдәбияты, шулай ук рус әдәбияты әсәрләрен өйрәнү контекстында күп мәдәниятле һәм күп конфессияле җәмгыятьтә Россия гражданлыгы тәңгәллеген аңлау, җор теллелек, халык тапкырлыгы, зирәклек, татар халык авыз иҗатының бай мираслы булуын аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — фаразлау, укытучы ярдәмендә максатны формалаштыру, иптәшләренең җавапларын бәяләү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, мәгълүматны нәтиҗәле истә калдыру һәм системалаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү, үз фикерләреңне әңгәмәдә катнашучыларның фикерләре белән чагыштыру.

*Предмет нәтиҗәләр* — халык авыз иҗаты жанры буларак, мәкаль һәм әйтем төшенчәләрен үзләштерү, мәкаль һәм әйтемнәрне тану, аларны бер-берсеннән аеру; мәкаль һәм әйтемнәрнең төп фикерен билгели һәм әйтеп бирә алу.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 5 нче сыйныф : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 68—72.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай эмоциональ халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

*Сезгә дәрестә начар билге алган дустыңны тынычландырырга кирәк, ди. Син аны ничек юатыр идегез? Тәэсирлерәк булсын өчен, нинди сүзләрдән файдаланыр идегез? Ничек уйлыйсыз, бу очракта мәкаль һәм әйтемнәр ярдәмгә килә аламы? Кулланырга мөмкин булган шундый мәкаль яки әй-*

*темне әйтеп карагыз.* Укучылар ситуациягә туры китереп мәкальләрне мисал итеп китерергә авырсынсалар, берничә мәкальне үзебез тәкъдим итәбез, туры килгәннәрен укучылар үзләре сайлап алалар.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең темасы, максаты билгеләнә. Укучылар дәрестә мәкаль һәм әйтемнәр турында сүз барачагын әйтәләр.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Дәрескә алынган темалар татар халык авыз иҗатынының кыска афористик жанрларын — мәкаль һәм әйтемнәрен өйрәнүгә юнәлдерелгән. Укучылар аларның үзенчәлекләрен, тематикасын, идеясен билгелиләр. Мәкаль һәм әйтемнәрнең тематик төрләрен күрсәтәләр. Шул рәвешле, мәкаль һәм әйтемнәрне бер-берсеннән аерып торучы билгеләрне хәтерләрендә калдыралар. Халык авыз иҗаты әсәрләре арасында бу жанрларның кулланылыш үзенчәлеген, аларның башка жанрдан аермасын ассызыклыйлар. Алга таба алар бу белемнәрен мөстәкыйль рәвештә дә куллана алалар.

Укучыларны теманы өйрәнүгә дәреслектә бирелгән *Ни өчен мәкаль сакалдан олырак?* дигән проблемалы сорау кызыксындыра ала.

Иң элек, башлангыч сыйныфларда мәкаль турында белгәннәр искә төшерелә. Дәреслектә бирелгән материалга өстәмә рәвештә түбәндәгеләрне җиткерә алабыз: Табышмаклар, мәкальләр һәм әйтемнәр — халык авыз иҗатының кече жанрлары, үзләренә кыска күп мәгънә сыйдыра, шуңа аларны афористик жанрлар дип йөртәләр. Табышмакларда җавабы яшерелгән нәрсә турында читләтеп әйтелә. Мәкальләрдә тормыш тәҗрибәсе нәтиҗәсендә гомумиләштерелгән фикер җиткерелә, әйтемнәрдә читләтеп бәя бирелә.

Мәкальләр тормышта тупланган тәҗрибәне бик кыска һәм аңлаешлы итеп әйтеп бирә. Аларның төп үзенчәлеге — гомумиләштереп нәтиҗә ясау, кешене хаталанудан, ялгышудан саклау. Мәкальләр кешенең холкы, әти-әнинең, туганнарның, дусларның, туган ил, туган телнең кадере, нәрсә яхшы, нәрсә начар икәнлеге турында булырга мөмкин.

Шуннан соң укучылар үзләре белгән мәкальләрен искә төшерәләр. Дәреслектә биргән мәкальләр, аларның мәгънәләрен аңлаталар.

Алга таба әйтемнәр белән танышу күздә тотыла. Укучыларга мәкальләрдән аермалы буларак, әйтемнәрнең кешенең холкына, эш-гамәленә, тәрбиясенә һәм төрле күренеш — вакыйгаларга бәя бирүләрен аңларга тиешләр. Өстәмә итеп түбәндәгеләрне җиткерәбез: «Әйтемнәрнең мәгънәсе, эчтәлекләре тормыш вакыйгалары белән бәйләнешкә кергәндә генә ачыла. Алар кулланылышка әзер килеш хәтердә саклана. Әйтемнәрдә киңәш, акыл бирү түгел, бары үткен бәя була».

Теманы өйрәнүнең азагында укучылар мәкальләрне әйтемнәрдән аерырга өйрәнергә тиешләр. Аларга *Әйтем һәм мәкальләрнең аермасы нәрсәдә?* дигән проблемалы сорау тәкъдим ителә. Укучылар бу турыда үз фикерләрен әйтәләр.

Уртак билге итеп мәкаль һәм әйтемнәрнең икесенең дә халык авыз иҗатының кыска жанрлары булуын, халыкның күп гасырлык тәҗрибәсен чагылдыруын, тотрыклы гыйбарә буларак саклануын, сөйләмебезне матурлавын, фикерләребезне кыска һәм ачык әйтергә ярдәм итүен күрсәтә алабыз. Аермалы якларыннан мәкальнең мөстәкыйль яшәвен, вакыйганың үзенә бәя бирүен, тәмамланган фикерне белдерүен, ә әйтемнең мөстәкыйль яши алмавын, тормыш вакыйгалары белән бәйләнешкә кергәндә генә ачылуын; нәрсәнеңдер бер ягына гына бәя биреп килүен ачыкларга тиеш булабыз.

**VI. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Әлеге этапта мәкаль һәм әйтемнәр белән практик эш оештырып була. Мәсәлән, түбәндәге биремнәрне куллана алабыз.

*1) Әйтемнәрдән кешенең яхшы сыйфатын гына бәяли торганнарын күрсәт.*

*2) Тәкъдим ителгән рәсемнәргә мәкальләр яки әйтемнәр уйла.*

*3) Бирелгән мәкаль һәм әйтемнәрдән әйтемнәрне генә аерып яз. Фикерләреңне дәлиллә.*

*4) Бирелгән ачкыч сүзләр арасыннан мәкальләр һәм әйтемнәргә хас уртак билгеләрне һәм аларның аермасын күрсәткән сүзләрне сайлап яз.*

*5) Мәкальләр ярдәмендә мактанчык дустыңа, көнчел иптәшеңә, елак сеңлеңә яки энеңә акыллы киңәш бир.*

**VII. Өй эше бирү.**

Хезмәт (яки башка) темасы белән бәйле алты-җиде мәкаль һәм әйтем тупларга; үзләре теләгән берсенең рәсемен ясарга.

**VIII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Табышмак — тапкырлар уены (Табышмаклар).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — тапкырлык, зирәклек турында төшенчә алу.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — фаразлау, уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, мәгълүматны нәтиҗәле истә калдыру һәм системалаштыру; диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, үз фикерен әйтә белү, үз фикерләреңне әңгәмәдә катнашучыларның фикерләре белән чагыштыру.

*Предмет нәтиҗәләр* — халык авыз иҗаты жанры буларак, табышмак төшенчәсен үзләштерү, табышмакларның төзелешен, табышмак иҗат итү алымнарын белү.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 5 нче сыйныф : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 73—76.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай эмоциональ халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эшен тикшерү.
2. Укучыларга табышмак турында табышмак әйтү:

*Аны әйтсәң — шатлык,*
*Җавабын белсәң — татлык.*

Бу нәрсә була, укучылар?

Җавап алынгач, укучылардан табышмак турында белгәннәрен сораштырабыз.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Укучылар дәрестә табышмаклар турында сөйләшәчәкләрен фаразлап әйтәләр.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Дәреснең бу өлешендә дәреслектә бирелгән табышмаклар белән танышабыз, җавапларын табабыз. Укучылардан үзләре белгән табышмакларны әйттерәбез.

Табышмакның үзенчәлекләрен, ясалышын, төзелешен тикшергәндә түбәндәге мәгълүмат җиткерелә ала.

Бәя биргәндә, тасвирлаганда, бер нәрсәне икенчесе белән чагыштыру алымы еш кулланыла. Табышмакларда да охшаш сыйфатлы әйберләр чагыштырыла, бер әйбер аңа охшаш икенче нәрсә аша аңлатыла. Күренешләрнең охшашлыгына яки каршылыгына нигезләнгән эчке чагыштыруда *сыман, шикелле, төсле, кебек бәйлекләре - дай/ - дәй* кебек кушымчалар кулланылмаса, метафора дип аталган сурәтләү чарасы барлыкка килә. Табышмакларда ул бик еш очрый. Мәсәлән, җир җиләген кызыл төймә дип атыйлар: *кызыл төймә таптым, авызыма каптым*.

Табышмак эченә яшерелгән әйберне төрлечә аңлатып бирергә мөмкин. Әйбернең сүзләр ярдәмендә сурәте тудырылса, ул *сурәтле табышмак* дип атала. Күпчелек табышмаклар шул рәвешле ясала. Әле без танышкан табышмаклар шундыйлардан. Моннан тыш, математик исәпләүне сорый торган *арифметик табышмаклар,* сорау эченә яшерелгән, хәйләне аңлаганда гына җавабын табып була торган *сорау-табышмаклар*, укучыдан җавап көтә торган әкият-табышмаклар да бар. Арифметик табышмакларда да хәйлә, тыңлаучыны ялгыштыра торган сорау куелырга мөмкин. Мәсәлән, *агач ботагында өч чыпчык утыра иде, берсен песи тотты. Ничә чыпчык утырып калды? Җавап ике чыпчык түгел, чөнки бер чыпчыкны песи тотканда, калган икесе куркып очып китә.* Сүз, аваз-хәрефләр белән бәйле табышмакларны *грамматик табышмаклар* дип атыйлар.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Тема ахырында *Ни өчен табышмакларны афористик жанр дип атыйлар?* дигән проблемалы сорау тәкъдим ителә. Укучылар бу турыда үз фикерләрен әйтәләр.

Биредә табышмаклар белән бәйле төрле эш төрләрен кулланып эшләргә була. Мәсәлән, табышмакларның җавапларын табу, тәкъдим ителгән табышмакларның төрләрен билгеләү, төрле предмет-күренешләргә табышмаклар уйлап табу.

Шулай ук табышмак әйтешү буенча уен-ярыш үткәрергә мөмкин.

**VI. Өй эше бирү.**

Табышмаклар уйларга, яки билгеле бер темага табышмаклар туплап килергә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Татар халык авыз иҗаты темасын кабатлау.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — татар халык авыз иҗатының халык тормышындагы әһәмиятен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, мәгълүматны нәтиҗәле истә калдыру һәм системалаштыру, гомумиләштерә һәм нәтиҗә ясый белү; диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, үз фикерен әйтә һәм дәлилле белү, үз фикерләреңне әңгәмәдә катнашучыларның фикерләре белән чагыштыру.

*Предмет нәтиҗәләр* — «Татар халык авыз иҗаты» дип аталган зур темада үзләштерелергә тиешле әһәмиятле өлешләрне хәтердә калдыру, сорауларга җавап бирә белү.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 5 нче сыйныф : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 14—76.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Алдагы дәресләрдә нинди зур тема өйрәнүләрен, нинди әсәрләр укуларын искә төшереп алу.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Актуальләштерү өлешендәге сөйләшү ярдәмендә бу дәреснең өйрәнгәннәрне искә төшерү, нәтиҗә ясау дәресе булачаган билгелиләр. Укытучы ачык итеп аның темасын әйтә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Кабатлау дәресен ничек уздыру укытучы ихтыярына бәйле. 5 нче сыйныф укучыларының яшь үзенчәлекләренә бәйле рәвештә ул дәрес-сәяхәт, дәрес-ярыш, дәрес-уен, дәрес-конференция формасын алырга мөмкин. Кабатлау дәресендә эчтәлек сөйләү, традицион рәвештә сорауларга җавап бирү, төрле табышмак-ребусларга җавап табу, тест эшләү һ.б. эш төрләрен кулланып була. Иң мөһиме — бу дәрес үткән материалдан иң әһәмиятле нәрсәләрне хәтердә ныгытып куюга хезмәт итәргә, гомуми нәтиҗә чыгарырга булышырга тиеш.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Үтелгән теманы гомумиләштереп, нәтиҗә ясауга киләбез.

**VI. Өй эше.**

Электрон дәреслектә бирелгән тестны чишәргә тәкъдим итәбез.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** 1) Әкиятне кем иҗат итә? (Әдәби әкият. Габдулла Тукай. «Шүрәле»);

2) Матурлык һәм батырлык (Габдулла Тукайның «Шүрәле» әкияте).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — авыр ситуациядә югалып калмауның, тапкырлык, зирәклекнең әһәмияте турында аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — фаразлау, матур әдәбиятта сурәтләнгән ситуацияләрне анализлап, әсәрне өйрәнгәндә һәм тормышта очраган ситуацияләрне хәл итү өчен, проблемаларны ачыклау, иптәшләренең җавапларын бәяләү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилле әйтә белү, фикерләрне кабул итү һәм тәгъбирләү.

*Предмет нәтиҗәләр* — Г. Тукайның «Шүрәле» поэмасының эчтәлеген аңлау, әсәрнең темасын билгели алу.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 5 нче сыйныф : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 77—90.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Теманы өйрәнүгә дәреслектә бирелгән *Әкият язу өчен ни кирәк*? дигән проблемалы сорау юнәлеш бирә.

Укучыларга рәсемнәрне карап, әкият исемнәрен, авторларын билгеләргә кушып була.





Укучылар әкиятләрнең авторы да булырга мөмкинлекләрен аңлыйлар. Авторы булган, үзләре белгән әдәби әкиятләргә мисаллар әйтәләр.

Икенче дәрестә әлеге этапта өй эшен тикшерү, белгәннәрне кабатлау башкарыла ала.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алдагы сөйләшү нигезендә укучылар теманы, максатны билгелиләр.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Әлеге тема буенча дәресләрне оештырганда, Г. Тукайның «Шүрәле» әкиятен ике өлешкә бүлеп уку-анализлауны максат итеп куеп эшләргә мөмкин. Беренче дәрестә әкиятнең беренче өлеше укыла һәм анализлана. Әсәрнең эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирелә.

Әлеге темага әзер видеодәрес бар. Әсәрне өйрәнгәндә, аны куллана алабыз.

Алдагы дәрескә укучылар әсәрне тулысынча укып килергә тиешләр. Әсәрне ничек аңлаганнарын сораулар ярдәмендә белеп була:

*«Шүрәле» әкиятен ике өлешкә бүлегез. Өлешләргә исем бирегез. Һәр өлештә сүзнең нәрсә турында барганын билгеләгез.*

*Әкияттә Шүрәле төрле халәттә сурәтләнә. Шүрәленең көчле, мәкерле булуын тасвирлаган юлларны һәм аңа карата кызгану хисе уяткан урыннарны табып укыгыз. Шүрәле егетне очратканчы, очраткач, егет киткәч нинди халәттә була?*

*Шүрәле әкияттә бик күңелсез хәлгә кала. Бик кызганыч, әлбәттә. Шул ук вакытта аның мәкерлелеге өчен җәза алу түгелме? Ни өчен?*

*Былтыр — батыр егет. Ул һәрвакыт дөреслек, гаделлек ягында. Шуңа күрә Шүрәледән дә куркып калмый. Былтыр Шүрәленең бармагын ярыкка кыса, дидек. Шүрәлегә үзенең исемен Былтыр дип әйтеп калдыра. Ничек уйлыйсыз, Былтыр дөрес эшлиме?*

*Сез геройларга нинди киңәш бирер идегез?*

*Габдулла Тукай Шүрәлене тасвирлаган урынны табып укыгыз. Шүрәленең ямьсезлеген, котсызлыгын күрсәтер өчен, автор нинди сүзләр куллана?*

*«Шүрәле» әкиятендә табигать күренешләрен укып күрсәтегез. Алар ни өчен бирелгән дип уйлыйсыз?*

*Габдулла Тукай түбәндәге өзектә сиңа таныш булмаган нинди искергән сүзләр кулланган? Аларның мәгънәләрен аңлатып карагыз.*

*«Шүрәле» әкиятендә авторның геройларга карата мөнәсәбәтен билгеләгез. Тукай бу әсәре белән безгә нәрсә әйтергә тели?*

Укучылар авторның егет яклы булуын аңларга тиешләр. Шүрәлене ул кызганмый, аннан көлә генә. Шагыйрь тормышта була торган төрле ситуациядән чыгу юлын табарга мөмкин икәнлеген искәртә. Шүрәле кебек тупас, дорфа урман сарыгы булмаска, егет кебек батыр, кыю, тәвәккәл булырга өнди.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Бу этапта Шәүрәле белән бәйле мифик образ төшенчәсенә билгеләмә бирә алабыз. Башта әңгәмә үткәрәбез:

*Ничек уйлыйсыз, Шүрәле Габдулла Тукай әкиятенә ничек килеп кергән икән?*

*Әйе, Шүрәле халык әкиятендә, мифларда очрый. Иң элек ул — мифик образ. Моның шулай булуын дәлиллик әле.*

Мифтан башта Шүрәле халык әкиятенә кергән, аның аша әдәби әкияткә күчкән, шулар аша Г. Тукай Шүрәлене үз әкиятенә герой итеп ала дигән нәтиҗә ясала. Дәреслектә дә бу турыда мәгълүмат урнаштырылган.

Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай турында дәреслектә «Татар халкының танылган шәхесләре» рубрикасы аша танышырга була.

Шулай ук «Шүрәле» әкиятенә нигезләнеп иҗат ителгән сәнгать әсәрләре хакында сөйләшергә мөмкин. Татар сынчысы Бакый Урманче турында язманы уку бик урынлы.

Программа кысаларында «Шүрәле» балеты, аның авторлары турында мәгълүмат алу күздә тотыла. Бу урында «Шүрәле» балетыннан өзек күрсәтеп китү отышлы. Дә-

реслектә бирелгән иллюстрацияләргә аңлатма биреп, әлеге балетның төрле постановкалары булуын күрсәтергә кирәк.

Теманы өйрәнү ахырында әдәби әкиятләрнең халык әкиятләре белән охшашлыгы һәм аерымлыклары турында сөйләшү үткәрә алабыз, нәтиҗә ясатабыз.

**VI. Өйгә эш бирү.**

Әкиятне укырга, эчтәлеген сөйләргә әзерләнергә, әкияттән өзекне ятларга.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Һәр гамәлнең үзе кала (Эпик әсәр үзенчәлекләре. Хикәя жанры. Фәнис Яруллинның «Кояштагы тап» хикәясе).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — үз-үзеңне тоту һәм гамәлләреңне, шулай ук башка кешеләрнең үз-үзләрен тотышы һәм гамәлләрен аларның нәтиҗәләрен исәпкә алып, әхлакый һәм хокукый нормалар позициясеннән бәяләргә әзер булу; алдауның начар гамәл икәнен аңлау, ата-анага хөрмәт хисенә төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, матур әдәбиятта сурәтләнгән ситуацияләрне анализлап, әсәрне өйрәнгәндә һәм тормышта очраган ситуацияләрне хәл итү өчен, проблемаларны ачыклау; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, үз позицияңне, фикереңне дәлилләү; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү, үз фикерләреңне әңгәмәдә катнашучыларның фикерләре белән чагыштыру.

*Предмет нәтиҗәләр* — Ф. Яруллинның «Кояштагы тап» хикәясенең эчтәлеген аңлау, темасын һәм төп фикерне билгели алу.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 5 нче сыйныф : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова

Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 91—96.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Укучыларга кояш тотылу турындагы рәсемне күрсәтеп, түбәндәге өзекне тыңлатабыз.

*...Күктә яп-якты булып янучы кояш кинәт карала башлаган. Дөнья коточкыч ямьсезләнеп киткән. Кош-кортлар, куркышып, ояларыннан качканнар. Шомлы итеп, елап-елап, этләр өрергә тотынган.*

Шуннан соң түбәндәге сорауларны бирәбез:

*Сез кояш тотылу күренешен күзәткәнегез бармы? Ул нидән гыйбарәт?* Укучылар белмәсә, аңлатма биреп китәбез: Табигатьтә кояш тотылу дип аталган астрономик күренеш бар. Бу вакытта Ай өлешчә яки тулысынча Кояшны каплый.

*Ә кояшта тап ничек барлыкка килә? Шул турыда беләсегез киләме?* дип укучыны кызыксындырабыз.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алда әйтелгәннәргә нигезләнеп, дәреснең темасы һәм максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Хикәяне уку, сүзлек белән эш, сорауларга җавапны укытучы үзе дәреснең максатына яраклаштырып уздыра.

Хикәянең эчтәлеге авыр түгел. Түбәндәге сорауларга җаваплар табу да кыенлык тудырмас:

*Малай кем белән яши?*

*Авыру әнисе малайга нинди эш кушкан?*

*Малай әнисенә ничек җавап бирә? Ул әнисенең хәленә керә алганмы? Ни өчен?*

*Сез малайның җавабы белән килешәсезме? Бу очракта сез ничек җавап бирер идегез?*

*Малай кабат урамга чыккач, дөнья нишләгән?*

*Малай нинди начарлык эшли? Бу яман эшне нәрсә күрә?*

*Кояшның каралу сәбәбен әни кеше ничек аңлата?*

*Малай үз хатасын аңлаганмы?*

*Ни өчен кояштагы кара тап бетмәгән?*

Әкиятне ике өлешкә бүләргә кушабыз. Һәр өлешкә исем бирәбез. Беренче бүлектә әнисенең улыннан су алып кайтуын соравы турында сөйләнә. Малай, әнисенең үтенечен тыңламыйча, суны ерак чишмәгә барып алмыйча, якын чишмәдән генә алып кайта. Бу өлешкә «Әни үтенече» дигән исем биреп була. Икенче бүлектән кояшның караңгылануы, анда тап калуы турында беләбез. Малай әнисеннән гафу үтенә. Бу өлешне «Кояшта тап нигә кала?» дип исемлибез.

*Малай турында нәрсә әйтә аласыз? Ул нинди? Аңа хас сыйфатларны билгеләгез* (укучылар малайны ялкау, куркак, ләкин гаебен таный белә дип тасвирлыйлар).

*Малайның үз-үзен тотышы әсәр буена ничек үзгәрә? Ни өчен дип уйлыйсыз? Малайның гамәлләрен аклап буламы?* (Малай башта әнисенең авыруына битарафлык күрсәтә, ул аны бер дә кызганмый, әнисенең хәленә керергә уйламый да, чөнки әзердә яши. Соңыннан, гаебен танып, әнисеннән гафу үтенә. Малайның гамәлләрен аклап булмый. Әни кешеләргә тупас эндәшергә ярамый, чөнки алар безне тәрбияли, ашата, киендерә, бөтен тормышын багышлый. Малай әнисенең кушканын берсүзсез үтәргә тиеш иде.)

Хикәянең идея-проблематикасы түбәндәге сорау-биремнәр ярдәмендә ачыклана:

*«Кояштагы тап» хикәясендә төп вакыйганы билгеләгез* (укучылар аны кояшта тап калу дип билгелиләр.)

*Әсәрдә «тап төшерү» төшенчәсе нинди күренеш белән бәйле?* (аны ялганлау белән бәйлиләр.)

*«Кояштагы тап» әкиятендә төп фикерне белдергән җөмләне тексттан табыгыз. Сез автор фикере белән килешәсезме?* (*Дөньяда бер генә яманлык та, бер генә ялган да эзсез калмый шул* җөмләсе әсәрдәге төп идеяне белдереп тора. Автор фикере белән килешәм. Ялган, яман эш барыбер кайчан

да булса беленәчәк. Аннан беркемгә дә яхшы булмаячак. Ул хәтта кире кайтарып булмас хәлгә китереп, тормыштагы күп нәрсәләрне бозарга мөмкин.)

*Фәнис Яруллин «Кояштагы тап» әкиятендә ни өчен кояш образына мөрәҗәгать итә? Ул кояшны кем белән чагыштыра? Ни өчен? Автор моның белән нәрсә әйтергә тели?* (Автор кояшны әни белән чагыштыра. Чөнки кояш та бер генә, әни дә. Кояш булмаса, җирдә тереклек тә булмас иде. Әни булмаса, без дә тумас идек. Язучының әниләр — безнең өчен иң кадерле кешеләр, дип әйтәсе килә. Моның белән ул әниләрнең сүзләрен тыңларга кирәклеген искәртә.)

Бу дәрестә эпик төргә билгеләмә бирү күздә тотыла.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

*Ни өчен Фәнис Яруллин бу күренешне үзенең «Кояштагы тап» әкиятендә кулланырга уйлаган икән?* (Кояш тотылу — куркыныч хәл, ә кояшта тап калу тагын да куркынычрак, чөнки аның яктылыгы кими, ә җир өчен бу зур фаҗига. Язучы моның белән ялганлауның кояш тотылу кебек куркыныч күренеш икәнен күрсәтәсе килә.)

*Фәнис Яруллинның «Кояштагы тап» әкияте нәрсә турында? дигән сорауга җавап бирүче төшенчәне билгеләгез. Сезнеңчә, бу төшенчә тагын нинди мәгънәләрдә килә ала?* (Бу — тап төшерү дигән төшенчә. Әсәрдә кояшка тап төшә. Туры мәгънәсендә «ул нинди дә булса чиста әйбергә тап төшерү» дигәнне аңлата. Әдәби әсәрләрдә күчерелмә мәгънәдә кулланыла ала. Бу — абруеңа тап төшү, күңелгә тап төшү дигән мәгънәләре аңлашыла.)

**VI. Өйгә эш бирү.**

Хикәянең эчтәлеген эзлекле итеп сөйләргә өйрәнергә; хикәянең геройларына бәя бирергә. Хикәянең үзенә ошаган өлешенә рәсем ясарга. Яхшылыкның тормышны матурлавы турында әкият иҗат итәргә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Яхшылык эшләсәң, үзеңә кайтыр (Фәнис Яруллинның «Зәңгәр күлдә ай коена» хикәясе).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — әдәби әсәрләрдә персонажларның үз-үзен тотышын һәм гамәлләрен бәяләп, әхлакый сайлау ситуацияләрендә әхлакый кыйммәтләр һәм нормаларга таянырга юнәлеш бирү; яхшы гамәлләр кылуның әһәмиятен аңлау, мәрхәмәтлелек, теләктәшлек кебек сыйфатларның асылына төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — укытучы ярдәмендә максатны формалаштыру, матур әдәбиятта сурәтләнгән ситуацияләрне анализлап, әсәрне өйрәнгәндә һәм тормышта очраган ситуацияләрне хәл итү өчен, проблемаларны ачыклау, үзбәя; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү, фикерләрне кабул итү һәм тәгъбирләү.

*Предмет нәтиҗәләр* — Ф. Яруллинның «Зәңгәр күлдә ай коена» хикәясенең эчтәлеген белү, идея-проблематикасын аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 5 нче сыйныф : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 96—102.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эшен тикшерү. Үткәннәрне искә төшерү.

2. *Ай кешегә ни өчен кирәк?* проблемалы соравын куеп, әңгәмәгә чыгабыз.

Бу вакытта укучылардан *Айның нинди эше бар? Кешеләргә ул ничек файдалы була ала, аларга ничек ярдәм итә?* дип сорый алабыз. Укучылар: «Ай төне буе дөньяны яктырта, ай булмаса, төнге юлчылар барыр юлларын таба алмаслар, дың-

гезләрдә кораблар батар, караңгыда юлбасарлар, караклар бер гөнаһсыз кешеләрне таларлар иде», — дип җавап бирә алалар.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең темасы, максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Әсәрне укып чыкканнан соң, эчтәлеген ачыкларга ярдәм иткән түбәндәге сорауларны бирә алабыз:

*Ай Зәңгәр күлдә кайчан коена? Ни өчен? Төнлә кешеләр йоклап беткәч, күктә нинди могҗизалар була? Шул урынны табып укы. Ай ни өчен бата башлый? Айны кем коткара? Ай Айсылуга рәхмәтен ничек белдерә?*

Әсәрдә бирелгән образларны характерлаганда вакытта, аларның гамәлләрен бәяләргә кушып була. Чуртан Айның шундый матур, шундый якты булуына, бөтен дөньяны соклandырып торуына бик көнләшеп йөргән. Аннары Чуртанның Айның ашамыйча-эчмичә яши алуына да бик эче пошкан. «Без монда көн саен тамак туйдыру турында уйлыйбыз, әллә кемнәрнең кармакларына эләгәбез. Ә син эшләмичә рәхәт кенә яшисең», — дигән Чуртан. Ә Гөберле бака Айга ярдәм итмәвенең сәбәбе — Ай аны мактамый, җырлый алмавы турында ачыктан әйтә. Әлбәттә, Чуртан һәм Гөберле бака дөрес эшләми, чөнки башкаларның кайгысына битараф калырга ярамый.

*Айсылу ни өчен үзен, аямыйча суга сикереп, Айны коткарырга ашыккан? Аның Айның рәхмәтен аласы килеп, матурлану нияте беләнме?* дигән сорауга укучылар: Ул Айның батуына битарафлык күрсәтә алмыйча, үзен аямыйча, аны коткарам дип, суга сикергән. Айсылу Айны суга батудан коткара. Шуның өчен Ай аңа яхшылык белән җавап бирә, аның йөзенә матурлык яга. Айсылу Айга ярдәм итмәгән булса, гомере буе ямьсез булып йөрер иде», — дип җавап бирәчәк.

«Зәңгәр күлдә Ай коена» әкияте яхшылык эшләүнең әһәмияте турында. Әсәрдә төп фикерне чагылдырган вакыйга Айның Айсылуга рәхмәт әйтүендә чагылыш таба.

*Әкияттә «Ай үзенең якты нурын бары тик күңеле матур кешеләрнең йөзенә генә яга ала. Чын-чын. Әгәр минем сүзләремә генә ышанмасагыз, кемгә дә булса яхшылык эшләп карагыз, шунда сез айның тылсымлы нурларында коенгандай матурланып китүегезне күрерсез» дигән автор сүзләре белән килешәсеңме? Язучы моның аша нәрсә әйтергә теләгән?* Язучының бу сүзләре Айсылуның күңел матурлыгын ассызыклый. Чыннан да аның күңеле матур, алай булмаса, Чуртан һәм Гөберле бака кебек битарафлык күрсәтеп, Айга ярдәмгә килмәс иде. Әсәрдәге төп фикер дә шуңа бәйле — эшләгән яхшылык һәрвакыт синә яхшылык белән әйләнеп кайта.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Әлеге этапта чагыштырма анализ методын кулланып эшләргә мөмкин. Бу уңайдан укучыларга түбәндәге сорауларны биреп була. *Фәнис Яруллинның «Кояштагы тап» әкиятендә тап төшерү дигән төшенчә бар. Бу төшенчә «Зәңгәр күлдә Ай коена» әкиятендә дә очрый. Анда ул нинди күренеш белән бәйле, кайсы вакыйгада бирелә?* Укучылар беренче әсәрдә кояшка тап төшүен билгелиләр. Бу әсәрдә абруеңа тап төшү, күңелгә тап төшү дигән мәгънәләрдә аңлашыла. «Зәңгәр күлдә Ай коена» әкиятендә ул Айга тап төшү күренеше буларак телгә алына. Гөберле бакага Ай үзенең ялганлый алмавы, кире очракта йөзе каралачагы турында әйтә.

**VI. Өй эше бирү.**

Әсәрне укырга, әсәр эчтәлегенә туры килгән мәкальләр уйлап килергә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Кеше нинди була? (Дәрдмәнднең «Богдай» хикәясе).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — булдыклылык, уңганлык, тупаслык, тәкәбберлек төшенчәләрен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — укытучы ярдәмендә максатны формалаштыру, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, үз позицияңне, фикереңне дәлилләү; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп җиткерә белү, үз фикерләреңне әңгәмәдә катнашучыларның фикерләре белән чагыштыру.

*Предмет нәтиҗәләр* — Дәрдмәнднең «Богдай» хикәясенең эчтәлеген белү, идея-эстетик үзенчәлеген аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 5 нче сыйныф : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 103—104.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик язмалар.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай эмоциональ халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эшен тикшерү. Алдагы дәрестә үткәннәрне искә төшерү.

2. Темага алып кереп китү өчен, *Борыныңны бик күтәрмә, агач башына эләкмәсен* мәкале буенча әңгәмә оештырып була.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алдагы этапта башкарылганнарга нигезләнеп, укучылар дәрестә сүзнең нәрсә турында барачагын билгели алачаклар.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Дәрестә Дәрдмәнднең зур булмаган, ләкин тирән мәгънәле «Богдай» хикәясен укып үзләштерү күздә тотыла.

Әсәр геройлары басуга килгәч, башларын түбән игән бодайларны күрәләр. Хөсәен төз баскан бодайлар яхшы, ә башларын игән бодайлар начар дип уйлый, башларын күтәргән бодайларны мактый: «Нинди теп-текә, егет сыман торалар». Аның уенча, бу яхшы. Ә башларын түбән игәннәрен кызга-

на: «Карачы бу богдайларны: мескеннәр! Ничек муеннары бөгелгән. Болары начар». Әтисе аңа моның болай түгеллеген гамәли яктан күрсәтеп аңлата: башлары иелгән башакта бодай күп, ягъни яхшы, ә төз басып торганда орлык аз, ягъни начар.

Хикәядә кешеләрнең төрләрен автор бодай мисалында аңлата. Бодайның мәгънәсе — кешеләр булдыклы яки булдыксыз булырга мөмкин. Башын түбән игән бодайлар — булдыклы кешеләр. Алар бервакытта да үзенең эш-гамәлләре белән мактанмыйлар, аларны башкалар мактый. Ә башын төз тоткан бодайлар — булдыксыз кешеләр. Алар мине күрсеннәр, мине мактасыннар, дип башларын күтәреп тора, ләкин эшләгән эшләре беркемгә дә файда китерми.

Дәрдмәнднең «Богдай» әсәренең эчтәлегенә нигезләнеп, *Булдыклы кешеләр нинди була?* дигән соравын бирәбез. Булдыклы кешеләр һәр эшне җиренә җиткереп эшлиләр. Алар җаваплы, тыйнак, белемле, ярдәмчел, эшчән, яхшы, мәрхәмәтле. Алардан үрнәк алырга була. Булдыклы булсаң, сине һәркем хөрмәт итә.

Дәрдемәнднең «Богдай» әсәренә нигезләнеп, *Буш кешеләр нинди була?* дигән сорау бирәбез. Булдыксыз кешеләр бер эшне дә ахырына кадәр эшләмиләр, ярты юлда калдырып китәләр, алар — мактанчык, җавапсыз, тупас һәм тәкәббер кешеләр, алар кебек булырга ярамый», — диячәк.

Укучылар нәтиҗә ясый: тук башак — булдыклы, тыйнак кеше, буш башак — мактанчык, буш кеше.

Шулай ук игенче һәм аның улына характеристика бирергә мөмкин. Бу вакытта игенченең бодай үстерүен, улын эшкә өйрәтүен, үзенең үрнәгендә тәрбияләвен, улын яратуын, үтемле итеп аңлата белүен билгелибез. Малай эшчән, тәрбияле, акыллы, ул әтисенә булыша, аны игътибар белән тыңлый, нәтиҗәләр ясый дигән нәтиҗә ясыйлар укучылар.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Эпик төрнең үзенчәлекләрен искә төшереп, әлеге хикәянең эпик төргә керүен исбатлата алабыз. Укучылар әсәргә хикәяләү хас булуын, үзәктә вакыйга чәчмә форма, геройларның диалогы урын алуы кебек үзенчәлекләрне билгелиләр.

**VI. Өй эше бирү.**

Хикәяне укырга.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Урман кызы ак томан сыман... (Габделхәй Сабитовның «Урман кызы Таңсылу» хикәясе);

Күңелендә юкның күзе юк (Габделхәй Сабитовның «Урман кызы Таңсылу» хикәясе).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — үз-үзеңне тоту һәм гамәлләреңне, шулай ук башка кешеләрнең үз-үзләрен тотышы һәм гамәлләрен аларның нәтиҗәләрен исәпкә алып, әхлакый һәм хокукый нормалар позициясеннән бәяләргә әзер булу; табигатьнең матурлыгын күрә белү, аны саклауның әһәмиятен аңлау; экологик культура дәрәҗәсен күтәрү, экология мәсьәләләренең глобаль характерын һәм аларны чишү юлларын аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — матур әдәбиятта сурәтләнгән ситуацияләрне анализлап, әсәрне өйрәнгәндә һәм тормышта очраган ситуацияләрне хәл итү өчен, проблемаларны ачыклау, матур әдәбият үрнәкләрен анализлау барышында үзеңне башка кеше урынына куя белү иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерләрен әңгәмәдә катнашучыларның фикерләре белән чагыштыру, үз фикерен дәлилләп җиткерә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* — Г. Сабитовның «Урман кызы Таңсылу» хикәясенең идея-проблематикасын аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 5 нче сыйныф : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 105—127.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, аудиоязмалар.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай эмоциональ халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эшен тикшерү. Үткәннәрне искә төшерү.

2. *Бар кеше дә матурлыкны күрә беләме?* дигән проблемалы сорау куеп, укучыларны уйландырабыз, теманы өйрәнүгә юнәлеш бирәбез.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алдагы этапта эшләгәннәргә нигезләнеп, укучылар дәрестә сүзнең нәрсә турында барачагын билгели алачаклар.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Габделхәй Сабитовның «Урман кызы Таңсылу» хикәясен өйрәнүгә программада ике сәгать каралган. Ул эпик әсәрләрне өйрәнүне дәвам итүгә юнәлдерелгән. Хикәянең эчтәлеге нигезендә укучылар эпик әсәрнең темасын билгелиләр, сорауларга җавап табалар, геройларның гамәлләренә бәя бирәләр, әсәрнең сәнгатьчә эшләнешен өйрәнәләр. Шул рәвешле, укучылар эпик әсәрне тирәнтен аңлауга ирешәләр һәм бу белемнәр нигезендә хикәяне анализлыйлар.

Хикәянең эчтәлеген ачыклау максатыннан, түбәндәге сорауларны биреп була: 1*) Булат әти-әнисе белән кайда яши? Ни өчен? 2) Газизулла абый улы Булатка нинди киңәш бирә? Шул урынны табып укыгыз. 3) Таң алдыннан Булат урманда кемне күрә? 4) Таңсылу нинди? Шул урынны табып укыгыз. 5) Кәли Булат белән ничек дуслашып китә? 6) Кәли белән Булат Таңсылуны күрәме? 7) Булат Кәлине урман кызының барлыгына ничек ышандырырга тели? 8) Урманда төшерелгән фотографиядә нәрсә күренә? 9) Малайлар нинди эш башлыйлар? 10) Соңгы тапкыр урманда Кәли белән Булат кемне күрә?*

Габделхәй Сабитовның «Урман кызы Таңсылу» хикәясендә төп вакыйга булып Булат белән Кәлинең урманда Карурман бабай җырын ишетүе тора.

*Кемнәр Карурман бабайның җырын ишетә ала? Күңел күзе кайчан ачыла?* кебек сораулар әсәрнең проблематика-

сын ачыкларга ярдәм итә. Хикәядә *күңел күзе* төшенчәсен табигатьне ярату, урман күренеше белән бәйләргә кирәк. Әлбәттә, урман матурлыгы һәм күңел матурлыгы арасында бәйләнеш бар. Күңеле матур кеше генә һәр нәрсәдә матурлык күрә ала. Ә инде күңел күзе күрмәгән кешеләр әкияти матурлыкны да күрми узып китәргә мөмкиннәр.

Әсәр геройларына характеристика биргәндә, Булатның кешелекле һәм нечкә күңелле, кызыксынучан, тыйнак малай булуын ачыклыйбыз. Ул гаиләсен һәм дусларын ярата, әтисе кебек табигатькә гашыйк һәм аның матурлыгын күрә белә, шуңа аңа урман кызы Таңсылу да күренә. Башкалар исә урмандагы тавышларны да ишетмиләр һәм матурлыкны күрмиләр. Таңсылу Булатның табигатькә ярдәм иткәнен белә (кыш көне песнәкләргә җим бирү) һәм шуңа аны усал түгел дип атый. Аннан аермалы буларак, дусты башта табигатькә битарафлык күрсәтә, чөнки ул аның матурлыгын күрми. Кәли хайваннарга, хәтта яшьтәшләренә карата үзен дорфа тота. Ул баштарак үзен башкалардан өстен куючы, дорфа малай була. Аның бар дөньясы башкаларга фокус күрсәтүгә һәм күңел ачуга кайтып кала. Аннан — табигатьне яратучы һәм аңа тартылучы малай булып ачыла. Соңыннан Булатның төшергән фотолары аша күңеле үзгәрә, матурлыкка тартыла башлый. Булатның дусты Кәли чын күңеленнән табигатьне ярата башлагач кына, урман матурлыгын һәм Карурман бабайны күрә. Булат белән дә аерылмас дусларга әйләнәләр.

Булатның әтисе Газизулла абзый гомер буе табигать белән бер дулкында яшәгән. Башта Иртеш буенда сал агызган, аннан урманчы булып эшләгән. Сугыштан соң урман күле буендагы пионер лагеренда каравылчы. Ул — гади һәм күңеле теләгәнчә табигать кочагында яшәргә яратучы. Башкалар җайлырак урында яшәргә омтылганда, андый кешеләр сәер булып тоела. Ул башкалар шикелле булырга һәм яшәргә омтылмый. Улын да үзе шикелле «урман җене» кагылган итеп тәрбияләргә тырыша.

«Җыр яраткан, урман-кырларны сөйгән, кошларны кызганган кеше ничек инде начар булсын?!» дигән җөмлә әсәрдәге төп фикерне чагылдыра. Табигатьне яраткан һәм матурлыкны күрә белгән кеше генә гармониядә яши алачак.

Күңеле матур кешегә тирә-як та әкияти гүзәл булып күренә. Әсәрнең идеясе — гүзәллекне күрә белгән кеше табигатькә дә, башкаларга да зыян сала алмый.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Бу этапта Габделхәй Сабитов турында дәреслектә бирелгән материал белән таныштырырга мөмкин.

Шулай ук табигатьне күрергә, тоярга, яратырга өйрәнүнең әһәмиятен билгеләгән әңгәмә үткәрерә алабыз. Текстта бирелгән үлән исемнәрен барлап, алар турында сөйләшергә мөмкин.

Бу этапта белемнәрне тикшерү максатыннан әсәр буенча тест эшләргә тәкъдим итеп була.

**VI. Өй эше бирү.**

Хикәяне укырга, эчтәлеген сөйләргә өйрәнергә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Үткән теманы кабатлау. Иҗади эш*:* шәхси кичерешләргә нигезләнеп инша язу (кабатлау).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр**:

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — уртак эшчәнлеккә әзер булу, үзара аңлашуга һәм ярдәм итүгә омтылу.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; гомумиләштерү, нәтиҗә чыгару, мәгълүматны нәтиҗәле истә калдыру һәм системалаштыру; әңгәмәдә катнашу, монологик сөйләм үстерү, үз фикерен дәлилләп әйтә белү, телдән һәм язма текстлар төзү.

*Предмет нәтиҗәләр* — белемнәрне гомумиләштереп системага сала белү.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 5 нче сыйныф : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 91—127.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

1. Исәнләшү.
2. Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Үткән дәрес материалларын искә төшерү.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Укучылар алдагы дәресләрдә өйрәнелгән теманы гомумиләштереп кабатлаячакларын беләләр.

**IV. Белемнәрне ныгыту.**

Бу дәрестә эпик төр темасын өйрәнү барышында алган белемнәр искә төшерелә, гомумиләштерүләр, нәтиҗәләр ясала. Белемнәрне тикшерү максаты белән тест үткәрергә мөмкин. Бу вакытта электрон дәреслектә бирелгән тесттан да файдаланырга була.

Шулай ук программада, бу тема кысаларында шәхси кичерешләргә нигезләнеп инша язу каралган. Шуңа күрә әзерлекне берничә дәрес алдан башлау кулайрак. Зур теманы өйрәнгәндә алган белемнәр дә ярдәмгә килер.

**V. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Эш сөйгәнне ил сөя (Мәсәл жанры. Габдулла Тукай. «Умарта корты һәм чебеннәр»).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — әдәби әсәрләрдә персонажларның үз-үзен тотышын һәм гамәлләрен бәяләп, әхлакый сайлау ситуацияләрендә әхлакый кыйммәтләр һәм нормаларга таянырга юнәлеш бирү; тырышлык, ялкаулык төшенчәләрен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, үз фикерен әйтә белү, үз фикерләрен әңгәмәдә катна-

шучыларның фикерләре белән чагыштыру, телдән һәм язма текстлар төзү.

*Предмет нәтиҗәләр* — мәсәл жанры турында төшенчә алу, Г. Тукайның «Умарта корты һәм чебеннәр» мәсәленең эчтәлеген белү, идея-эстетик үзенчәлеген аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 5 нче сыйныф : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 128—131.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

*Яманны күрмәсәң, яхшыны танымассың* мәкален тәкъдим итеп, укучыларны аның буенча фикерләштерәбез.

*«Умарта корты һәм чебеннәр» мәсәле нәрсә турында дип уйлыйсыз?* соравы ярдәмендә укучыларны фаразлатабыз, өйрәнеләчәк темага кызыксыну уятабыз.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алдагы этапта сөйләгәннәрне нигезләп дәреснең максатын билгеләтәбез.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Ике сәгатькә исәпләнгән тема мәсәл жанрын өйрәнүгә юнәлдерелгән. Моңа Габдулла Тукайның «Умарта корты һәм чебеннәр», Әхмәт Исхакның «Карт имән белән яшь егет» текстлары нигез булып тора. Аларның эчтәлегенә таянып укучылар мәсәлнең темасын, идеясен күрсәтәләр, текстта мәсәлгә хас билгеләрне күзәтәләр, аллегория, читләтеп әйтү, мәсәлнең морале төшенчәләре белән танышалар, әлеге жанр төзелешендәге үзенчәлекне билгелиләр, бу белемнәр нигезендә мөстәкыйль рәвештә мәсәл төшенчәсенә аңлатма бирәләр. Жанр үзенчәлекләренә туры китереп, мәсәл иҗат итә алалар.

Габдулла Тукайның «Умарта корты һәм чебеннәр» мәсәлен өйрәнгәндә түбәндәге нәрсәләрне истә тотарга кирәк.

Иң элек мәсәлне укытып, аның эчтәлеген ачыклатабыз. Бу вакытта әсәрнең сюжеты буенча сораулар ярдәмгә киләр. Әсәрнең идея-проблематикасы турында сүз йөрткәндә дәреслектә бирелгән сораулардан тыш *Әгәр Чебен: «Мин бу илләрдән китәм. Мине монда яратмыйлар», — дип зарланса, Умарта корты Чебенгә нинди киңәш бирер дип уйлыйсыз?* соравын тәкъдим итәбез. Укучы: «Син кешеләргә файда китерергә өйрән, шул очракта сине бөтен җирдә яратырлар», — дип җавап бирер. Әсәр геройларын характерлаганда, аларның сыйфатларына игътибар иттерәбез. Укучыларга *Мәсәлдәге геройларны алыштырырга туры килсә, сез алар урынына нинди образлар сайлар идегез? Ни өчен?* дигән сорау да кызыклы булачак, аларда күзаллый белү күнекмәләрен формалаштырачак.

Мәсәлдә Чебеннең башкалар хезмәтеннән генә файдаланырга яратучы ялкау кешегә охшавына игътибар юнәлтәбез. Шуннан соң укылган текстка нигезләнеп, мәсәл жанрына хас үзенчәлекләрне әйттерәбез. Укучылар мәсәлнең ике өлештән торуын билгелиләр. «Бер өлештә гыйбрәтле вакыйга сөйләнә. Аның геройлары хайваннар, төрле әйберләр, үсемлекләр, бөҗәкләр булырга мөмкин. Икенче өлеш читләтеп яки турыдан туры үгет-нәсыйхәт, акыл бирә, әдәпкә өйрәтә», дип җавап бирәләр.

Шуларга өстәп мораль турында аңлатма бирү кирәк. Мәсәлдәге икенче өлешне мәсәлнең морале дип атыйлар. Ул мәсәлнең башында яки ахырында урнаша.

Мәсәлләр әдәп-әхлак тәрбиясе бирү максаты белән иҗат ителә, яхшыны яманнан аерырга өнди. Ул турыдан-туры акыл өйрәтми, читләтеп әйтә, бер әйберне икенчесе аша күрсәтә, ягъни аллегорик образлар тудыра. Аллегорик образлар мисалында җәнлекләр, хайваннар, кош-кортлар, үсемлекләр килә. Мәсәлләрдә җанландыру чарасы кулланыла: җансыз әйберләр һәм хайваннар кеше кебек сөйләшә, төрле гамәлләр кыла. «Аллегорик образлар ярдәмендә тормыштагы кимчелекле күренешләр, кеше холкындагы тискәре сый-

фатлар тәнкыйтьләнә, мораль чыгарыла», дип укучыларның белемнәрен тулыландырабыз.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Укучыларның фикерләренә нәтиҗә ясап, мәсәлгә билгеләмә бирергә кушабыз. Тезмә (шигъри формада) һәм чәчмә (хикәя рәвешендә) язылган, ахырда морале булган әсәр *мәсәл* дип атала. Мораль өлеше мәкальләргә якын тора. Гадәттә, беренче өлеш әкият яки мәзәккә охшый. Әкиятләрдә һәм мәзәкләрдә мораль өлеше булмый.

**VI. Өй эше бирү.**

Мәсәлне сәнгатьле итеп укырга. Бирелгән мәкальләр (*Акыл хәйләдән өстен; Кем эшләми, шул ашамый; Иярсәң яхшыга ияр*) белән танышырга. Бер мәкальгә нигезләнеп, 8—10 җөмләдән торган мәсәл иҗат итәргә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Яшь акылның тәҗрибәсе аз (Әхмәт Исхакның «Карт имән белән яшь егет» мәсәле).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — әдәби әсәрләрдә персонажларның үз-үзен тотышын һәм гамәлләрен бәяләп, әхлакый сайлау ситуацияләрендә әхлакый кыйммәтләр һәм нормаларга таянырга юнәлеш бирү; кешеләргә файда китерүнең әһәмиятен аңлау, өлкәннәргә, аларның хезмәтенә хөрмәт белән карый белү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, матур әдәбиятта сурәтләнгән ситуацияләрне анализлап, әсәрне өйрәнгәндә һәм тормышта очраган ситуацияләрне хәл итү өчен, проблемаларны ачыклау; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, үз позицияңне, фикереңне дәлилләү; диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, үз фикерен әйтә белү, үз фикерләреңне әңгәмәдә катнашучыларның фикерләре белән чагыштыру.

*Предмет нәтиҗәләр* — Ә. Исхакның «Карт имән белән яшь егет» мәсәленең эчтәлеген белү, идея-проблематикасын аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 5 нче сыйныф : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 131—133.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерү рәвешендә үткәрелә ала.

*Кешеләргә ничек файдалы булырга?* дигән проблемалы сорау куеп, укучыларны уйландырабыз, шуның аша теманы өйрәнүгә юнәлеш бирәбез.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең темасы һәм максатлары билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Әхмәт Исхакның «Карт имән белән яшь егет» мәсәленең эчтәлеген *Имән агачын кем утырткан? Егет имән агачы турында нәрсә уйлый? Имән егеткә нинди сорау бирә?* һ.б. сораулар ярдәмендә аңлыйбыз.

Идея-проблематикасын түбәндәге сораулар ярдәмендә ачыкларга мөмкин: *Яшь егеткә бәя биререргә нәрсә ярдәм итә? Егетнең бабасына хөрмәт сакламавын нәрсәдән аңлыйбыз?* һ.б. Әсәрдә бирелгән образларны характерлаганда имәннең карт һәм тәҗрибәле икәнлеген, йортны җилләрдән саклап, күләгәләп тору өчен, аны егетнең бабасы утыртканда бабасының истәлеге булып торуын, аның күләгәсендә ял итүләрен игътибар үзәгенә алабыз. Яшь егет исә имәнне рәнҗетә, бабасына хөрмәт сакламый, ашау гына файда бирә дип уйлый; ялкау, үзе бер файдалы эш эшләмәсә дә, башкалардан файда көтә дип билгелиләр укучылар. Шулай ук

текстта Имән сүзенең баш хәрефтән, егет сүзенең юл хәрефеннән язылуының сәбәбен ачыклау кирәк булачак.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

*Габдулла Тукайның «Умарта корты һәм чебеннәр» мәсәлендәге Чебенгә һәм Әхмәт Исхакның «Карт имән белән яшь егет» мәсәлендәге яшь егеткә нинди уртак сыйфатлар хас?* дигән сорау биреп, укучыларны уйландырырга мөмкин. Бу вакытта укучылар: «Чебен һәм яшь егет икесе дә ялкау, беркемгә дә файда китермиләр, үзләренең гаебен башкалардан эзлиләр, җиңел юл белән әзерне файдаланып кына яшәргә телиләр. Икесе дә тискәре сыйфатларга ия», диләр.

Шулай ук кешеләргә файдалы булу, башкаларның хезмәтен күреп дөрес бәяли белү турында әңгәмә оештырырга мөмкин.

**VI. Өй эше бирү.**

Мәсәлне сәнгатьле итеп укырга.

Иҗади эш, мәсәлән, төркемнәргә бүленеп, дәрестә өйрәнелгән бер татар халык мәсәлен сәхнәләштерергә тәкъдим итеп була.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Туган җирдә һәр нәрсә изге (Лирик әсәр үзенчәлекләре. Габдулла Тукай. «Пар ат»).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — туган якка мәхәббәт, аны сагыну, аны күрүдән шатлану хисләренә төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, матур әдәбиятта сурәтләнгән ситуацияләрне анализлап, әсәрне өйрәнгәндә һәм тормышта очраган ситуацияләрне хәл итү өчен, проблемаларны ачыклау; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү, фикерләрне кабул итү һәм тәгъбирләү.

*Предмет нәтиҗәләр* — Г. Тукайның «Пар ат» шигыренең эчтәлеген аңлау, төп идеясен билгеләү, әсәр буенча сорауларга җавап бирә белү.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 5 нче сыйныф : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 134—137.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Бу этапта, темага алып керү максаты белән, Татарстан Республикасының фольклор музыкасы дәүләт ансамбле башкаруында Г.Тукайның «Пар ат» шигыренә язылган җырны тыңлатабыз. Шигырьнең аһәңлелегенә, андагы авазлар кабатлануының ат тоягы тавышлары тудыруына игътибар иттерәбез. *Җыр сездә нинди хисләр уятты, аның бизәлеше шигырь эчтәлеген ачарга ярдәм итәме?* дигән сорауга укучылар түбәндәгеләрне билгели алалар: Җыр пар атка тагылган кыңгырау чыңлаган тавышлар белән башлана. Шуңа туры килгән музыкага шигырьдәге [к, т, п, р] тартык авазларының кабатлануыннан барлыкка килгән яңгыраш ат тоякларының тавышын тудыруга хезмәт итә. Җырның музыкасы шигырьдәге күтәренке рух һәм шатлыкны чагылдыра. Татар халык җырыннан алынган кушымта өлеше моңсулык, аерылу сагышын бирүгә хезмәт итә. Җырга төшерелгән видеоклип шул тормышны, атлар белән ерак араларны ничек үтүләрен күрсәтә.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Уку мәсьәләсен кую.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Шигырьне өйрәнү аны сәнгатьле итеп укудан башлана (электрон дәреслектәге аудиоязманы кулланырга мөмкин). Г. Тукайның «Пар ат» шигыре күптөрле хисләр белән сугарылган, аларны әлеге әсәрне сәнгатьле итеп уку процессында ачыклап була. Шагыйрь-лирик герой бу хисләрне Казанга

кайтуы белән бәйле рәвештә кичерә. Шигырьнең үзе дә атның тигез чабышын хәтерләтә.

Г. Тукайның «Пар ат» шигырен өйрәнгәндә, укучылар иң элек лирик геройның туган якларыннан аерылган вакытта туган хисләрен билгеләргә тиешләр. Шигырьнең язылу тарихы турында дәреслектә бирелгән мәгълүмат белән таныштыру файдалы булачак.

Лирик геройның күңелен төрле уйлар һәм хисләр биләп ала: ул я кайгыра, борчыла, я шатлана, я аны билгесезлектән туган курку хисе яулый, я хыялларга бирелә, үз максатына омтылып, аның күңелендә өмет хисе уяна. Әлеге хисләрне шигырь өйрәнү барышында билгеләтергә тырышабыз.

Укучыларга әсәрнең темасы, геройның хисләре турында сораулар тәкъдим итәбез:

*1) Шигырьнең беренче өлешендә нәрсәләр сурәтләнә? Лирик герой үзен ничек хис итә? Ул борчыламы, әллә, киресенчә, тынычмы?*

*2) Лирик геройның туган җиренә кайтканлыгын кайсы шигырь юлларыннан белеп була? Туган якның табигате ничек тасвирлана?*

*3) Лирик геройның күңел халәте дүртенче дүртьюллыкта нинди үзгәреш кичерә? Анда нинди уй-хисләр туа? Бу юллар нинди хис белән әйтелергә тиеш?*

*4) Бишенче-алтынчы дүртьюллыкта лирик герой кемгә мөрәҗәгать итә? Бу юллар нинди хис белән сугарылган?*

*5) Лирик герой ни өчен моңсулана? Аның сәбәбе нәрсәдә?*

*6) Лирик герой нәрсәдән курка? Бу юлларны ничек укырга кирәк?*

*7) Кайсы юлларда хис-кичерешләр кинәт үзгәрә? Бу нәрсәгә бәйле? Кучер һәм лирик герой сүзләрен нинди интонация белән укырга кирәк?*

*8) Шигырьнең ахырында лирик геройның күңелен нинди уй-кичерешләр биләп ала?*

Укучылар бу вакытта шигырь «лирик геройның кичерешләре, рухи дулкынланулары турында» дип билгелиләр, «аның борчылулары берничә ел яшәгән җиреннән аерылуы

белән бәйле», «ул тиздән туган якларын күрүенә шатлана», «лирик герой биредә киләчәге якты булачагына өметләнә». Шул вакытта укучыларның җавапларына без лирик геройның хисләре туган җирне, аның киңлекләрен тасвирлау белән бәйле һәм бу аның хис-кичерешләрен билгеле бер юнәлештә алып барырга ярдәм итә, дип өсти алабыз. Шулай итеп, әлеге барлык сораулар лирик геройның кичерешләрен ачыкларга булышачак һәм шул ук вакытта шигырьне уку барышында шул ук хисләрнең укучыларда да тууына китерәчәк.

Бу дәрестә лирика төренә билгеләмә бирәбез. Лирикада нәкъ менә хис өстенлек итүен ассызыклап әйтәбез. Моны укучылар Габдулла Тукайның «Пар ат» шигырен анализлаганда да күрделәр.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Дәреслектә Г. Тукайның «Пар ат» шигыренә рәссам Фәрит Якупов ясаган рәсем урнаштырылган. Шул рәсемгә укучыларның игътибарын юнәлтеп эшләгәндә, түбәндәге сораубиремнәрне тәкъдим итеп була: *Рәсемне игътибар белән карагыз. Сезнеңчә рәсемдә рәссам шигырьдәге нинди хисләрне чагылдыруга өстенлек биргән? Төсләргә, сурәтлелеккә игътибар итегез.*

Укучылар рәсем белән эшләү барышында рәссам шигырьдәге геройның торган җирдән аерылу сагышы белән янган вакытларын сурәтләвен билгелиләр. Агачларның шәрәлеге, төсләрдәге караңгылык, кучерның бик җитди утыруы «бер матурның балдагын я калфагын» җырламавы, герой йөзендәге җитдилек тә шуны күрсәтеп тора. Атларның ашкынып чабуы, геройның еракка төбәлгән карашы туган җиргә омтылу, аңа өмет баглауны гәүдәләндерә, — дип җавап бирәләр.

**VI. Өй эше бирү.**

Шигырьне ятларга.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Батырлыкка чәчәкләр дә баш ия (Муса Җәлилнең тормыш юлы һәм иҗаты. «Кызыл ромашка» шигыре).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — совет солдатының батырлыгы турында аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү, фикерләрне кабул итү һәм тәгъбирләү.

*Предмет нәтиҗәләр* — М. Җәлилнең тормыш юлы һәм иҗаты турында мәгълүматлы булу, «Кызыл ромашка» шигыренең эчтәлеген аңлау, төп идеясен билгеләү, әсәр буенча сорауларга җавап бирә белү.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 5 нче сыйныф : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 138—141.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Алдагы дәрестә өйрәнелгәннәрне искә төшерү, өй эшен тикшерү рәвешендә үткәрелә ала.

*Батырлык матур була аламы?* дигән проблемалы сорауны куеп, укучыларны сөйләшүгә алып чыгабыз, дәреснең темасын аңлауга юнәлеш бирәбез.

*Кем ул Муса Җәлил? Аның батырлыгы турында нәрсә беләсез? Син Муса Җәлилнең кайсы әсәрләре белән таныш?* сорауларын кулланып, зур булмаган әңгәмә оештырабыз.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең максатларын билгеләү.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Программада 5 нче сыйныфта Муса Җәлилнең тормыш юлы һәм иҗатын өйрәнү каралган. Шуңа күрә шагыйрь турында биографик белешмә бирәбез. Тормыш юлы һәм иҗаты турында сөйләгәндә, күрсәтмәлектән файдалану отышлы. Шулай ук М. Җәлилнең кечкенә вакытында рәсем ясарга яратуы, мандолинада уйнавы, үзенең китапханәсен булдырырга хыяллануы, шигырьләреннән кечкенә китапчыклар төзүе, аларга Габдулла Тукай, Александр Сергеевич Пушкин әсәрләрен дә урнаштыруы, китапчыкка рәсемнәрне үзе ясавы кебек кызыклы фактларга да игътибарны юнәлтү уңышлы булачак. М. Җәлил, «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыганда, Тукай, Дәрдмәнд, Рәмиев иҗатлары белән якыннан таныша. Шулар тәэсирендә үзе дә шигырьләр яза башлый. Аның беренче шигырьләре «Кечкенә Җәлил» имзасы белән басыла. 10—11 яшьләрендә шигырьләр язып карый. Ләкин алар югала. Матбугатта иң беренче булып унөч яшендә язылган «Бәхет» шигыре (1919 ) басыла.

Аерым игътибарны М. Җәлилнең Бөек Ватан сугышында катнашуы, әсирлеккә эләгүе, андагы көрәш юлы, җәза алу белән бәйле фактларга юнәлтергә кирәк.

Бу дәрестә М. Җәлилнең «Кызыл ромашка» шигырен өйрәнү күздә тотыла. Шигырь сәнгатьле итеп укылганнан соң, сораулар ярдәмендә әсәрнең эчтәлеге ачыклана. Кызыл чуклы ромашка батыр солдатның яралы хәлен, түгелгән канын күрсәтә. Аның ялгыз моңаеп утыруы — батыр сугышчыдан аерылып калу сагышы. Шигырьдәге төп фикер ромашкаларның үзара сөйләшүендә күренә. Кызыл ромашка егетнең дошманга каршы батырларча сугышуын сөйли. Яралы булса да, аның кабат сугышка китүен һәм аны көтәчәге турында әйтә. Без солдатның бу батырлыгына сокланабыз. Әлеге әсәр герое белән М. Җәлилнең язмышлары охшаш. М. Җәлил дә, иртә таңда яраланып, аңын югалтып, яралы хәлдә, әсирлеккә эләгә. Тоткынлыкта газаплар кичерсә дә, үзен кыю тота, фашизмга каршы көрәшен туктатмый. Гомеренең соңгы минутларында да ул көрәшчеләр сафында була.

Шигырьдә бирелгән хисләрдән укучылар соклану, ярату, горурлану, сагыну хисләрен билгелиләр.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Муса Җәлилгә багышланган музейлар турында сөйләшеп, аларга виртуаль экскурсия оештырырга мөмкин.

Татарстанда шундый берничә музей Казанда, Минзәләдә, Балтач районы Карадуган авылында эшләп килә. Алар турында Интернет челтәрендә мәгълүмат табып, укучыларны таныштырабыз.

Минзәлә шәһәрендәге М. Җәлил музее да бу легендар шәхес истәлеген кадерләп саклый. Ул шагыйрь исемен йөртә торган урамда урнашкан педагогия колледжы бинасында эшләп килә. Фронтка китәр алдыннан, шушы йортта Җәлил политхезмәткәрләр курсларында укыган. Монда яшәгән 56 көннең барысы да актив рәвештә иҗат итү, шигырьләрен бастырып чыгару, минзәләлеләр алдында чыгышлар ясау белән үткән: еракта калган ул елларның кабатланмас үзенчәлеген чагылдырган экспозиция, күргән-белгәннәрнең истәлекләре шулар хакында сөйли.

Балтач районы Карадуган авылындагы укытучылар һәм мәктәп укучылары күп еллар үткәргән эзләнү эшләре нәтиҗәсендә монда Муса Җәлил һәм аның якыннары, дуслары, чордашлары турында кызыклы материаллар җыелган. Ядкәрләр арасында — Җәлилнең үз кулы белән бүләк итү сүзләре язылган Татар әдәбияты тарихы китабы, мәшһүр татар рәссамы Бакый Урманче тарафыннан ясалган скульптура.

Казанның нәкъ уртасында (М. Горький урамы, 17 нче йорт) Муса Җәлилнең музей-квартирасы урнашкан.

Ул 1983 елның 15 февралендә 1940—1941 елларда монда Татарстан Язучылар союзы идарәсенең рәисе М. Җәлил яшәгән, нәкъ менә шушыннан ул Ватанны саклау өчен сугышка киткән. Җәлил яратып җыйган, шкафка һәм этажеркага куелган китаплар, аның әсәрләре, үзе сайлаган фоторәсемнәрдән тупланган альбом, уен партиясе төгәлләнмәгән шахмат тактасы ята торган язу өстәле, үзе исән чакта ук ясалган бюсты, дисбесе, хуҗасының сизгер кулларын тойган һәм бу йортка килеп йөргән дусларын хәтерләгән мандолина.

**VI. Өй эше бирү.**

Шигырьне ятларга.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: «Мин тез чүкмәм, катыйль, синең алда». М. Җәлил (Иҗади эш: Х. Якуповның «Хөкем алдыннан» картинасы буенча хикәя төзү).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — үз халкың һәм башка халыклар сәнгатенең барлык төрләрен, традицияләрен һәм иҗатын кабул итү, сәнгатьнең, шул исәптән өйрәнелә торган әдәби әсәрләрнең эмоциональ тәэсирен аңлау; батырлык төшенчәсен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; телдән һәм язма текстлар төзү, үз фикерен әйтә белү, фикерләрне кабул итү һәм тәгъбирләү.

*Предмет нәтиҗәләр* — Харис Якуповның «Хөкем алдыннан» картинасы буенча хикәя төзи алу.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 5 нче сыйныф : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 141—143.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Алдагы дәрестә өйрәнелгәннәрне искә төшерү, өй эшен тикшерү рәвешендә үткәрелә ала.

М. Җәлилнең биографиясен хәтердә яңартып, тоткынлыкта булган тормышын ассызыклап сөйлибез. Озак вакыт дошман тылында яшерен көрәш алып баруы, араларында хыянәтче аркасында яшерен, эшләренең фашистларга билгеле булуы, төрмәгә ябылуы һәм үлем җәзасына хөкем ителүе

турында сөйлибез. Аерым игътибарны М. Җәлилнең характер сыйфатларына биреп, аның төрмәдә дә нык ихтыярлы, көчле кеше булуын әйтәбез (бу вакытта ук Харис Якуповның картинасын слайдта күрсәтергә мөмкин).

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Уку мәсьәләсен кую, дәреснең максатларын хәбәр итү.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Картина буенча сөйләм үстерү эше түбәндәгечә алып барыла.

Х. Якуповның «Хөкем алдыннан» картинасы буенча хикәя төзү өчен, картинаны игътибар белән карарга һәм сорауларга җавап бирергә тәкъдим итәбез: *Вакыйга кайда бара? Рәссам, картинаны язганда, нинди төсләрне кулланган? Алгы планда кемнәрне күрәсез? Муса Җәлилнең торышыннан, күз карашыннан нәрсәләр аңлашыла? Ә фашистларның кыяфәте турында нәрсә әйтә аласыз? Аларның көчсезлеген нәрсә күрсәтә? Арткы планда нәрсәләр күзгә ташлана? Сез ничек уйлыйсыз, стенадагы картина ни өчен яртылаш кына ясалган?* Хикәяне төзегәндә укучылар түбәндәге моментларны билгелиләр. Картинада төрмә бүлмәсе сурәтләнгән. Рәсемдә караңгы төсләр кулланылган. Без алгы планда Муса Җәлилне күрәбез. Ул горур басып тора. Аның үз-үзен тотышыннан, бернәрсәдән дә курыкмавы күренеп тора. Муса Җәлил фашистларга нәфрәт белән карый. Өстәл артында утырган фашист аннан бераз шүрли дә сыман. Муса Җәлилнең тоткынлыкта иҗат иткән шигырьләренә салынган мәгънә картинадагы геройның эчке халәтен бик ачык чагылдыра. Фашист хәтта торып басырга да курка. Әсир алардан курыкмыйча, фашистларның йөзенә карап тора. Арткы планда Гитлерның яртылаш портреты сурәтләнгән. Портретның яртылаш кына булуы дошманның тиздән җиңеләчәгенә ишарә кебек.

**V. Өй эше бирү.**

Дәрестә төзегән хикәяне язма рәвештә формалаштырып килергә.

**VI. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Эшең калсын мең яшәрлек имән булып (Муса Җәлилнең «Имән» шигыре).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — яхшылык, игелек эшләүнең әһәмиятен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, матур әдәбиятта сурәтләнгән ситуацияләрне анализлап, әсәрне өйрәнгәндә һәм тормышта очраган ситуацияләрне хәл итү өчен, проблемаларны ачыклау; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү, фикерләрне кабул итү һәм тәгъбирләү.

*Предмет нәтиҗәләр* — М. Җәлилнең «Имән» шигыренең эчтәлеген белү, идея-эстетик үзенчәлеген аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 5 нче сыйныф : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 143—145.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Алдагы дәрестә өйрәнелгәннәрне искә төшерү, өй эшен тикшерү рәвешендә үткәрелә ала.

*Игелек җирдә ятмый* мәкале белән эшләп, дәрестә өйрәнелә торган темага алып керәбез.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Уку мәсьәләсен кую.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Шигырь сәнгатьле итеп укылганнан соң, укучылардан шигырьдән алган беренче тәэсирләре турында сораштырабыз. Әсәрне анализлаганда, түбәндәге фикерләргә игътибар

иттерәбез: Имән ялгыз гына үсеп утыра. Ләкин ул үзен ялгыз хис итми. Аның әйләнә-тирәсе яшел үлән белән капланган, аның янынннан кеше өзелми. Бу Имәнне кем утыртканын да белмиләр.

Имәнне утырткан кеше кем генә булса да — игенчеме, бакчачымы, тормышны сөйгән гади кешеме — автор аңа: Син бәхетле кеше, — дип эндәшә. Аның хезмәтенә баш июен әйтә. Монда үзе үлгәннән соң да әйләнә-тирәгә, кешеләргә яхшылык, изгелек кыла торган кеше турында сүз бара. Автор ул кешенең хезмәтен имән аша ача. Имән исә кеше хезмәтенә һәйкәл булып тора.

Имән юлчыларга җырлый, аларны җил-яңгырдан саклый, күләгәсендә кешеләр ял итәләр, яшьләр имән төбендә очрашалар. Адашканнарга юл күрсәтә, кырларга татлы дымын эчерә. Үзенә тормыш биргән билгесез кешегә ул бик рәхмәтле. Рәхмәтле булуы — аның төп сыйфаты. Рәхмәтле булганга күрә Имән башкаларга да игелек кыла.

Ул ялгыз булса да, аның янәшәсендә яшел чирәм үсә, кошлар матур җыр суза. Имән ялгызлыктан интекми, чөнки ул тормышта да яхшы булган, берәүгә дә яманлык эшләмәгән. Ул тормышка гашыйк, ул бәхетле, чөнки кешеләргә шатлык өләшүе белән бәхетле.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

М. Җәлилнең «Имән» шигырен шагыйрьнең характер сыйфатларына нигезләнеп, язмышы белән чагыштырып нәтиҗә чыгару.

Шигырьдә кеше нинди булырга тиешлеге язылган. Имән үсентесен кайчандыр бер кеше утырткан. Димәк, аңа кеше тормыш биргән, шуңа күрә Имән кешене гомер буе бүләкли. Һәрвакыт яхшылык эшләп яшәргә кирәк, синең тормышың яхшылыклардан гына торырга тиеш, чөнки начарлык эшләсәң, ул сиңа кайчан да булса кире кайтачак. Шигырьнең дә төп фикере — кешеләргә карата булган игелегең — синең үзең өчен яхшылык.

«Имән» шигырен язган шагыйрь берничек тә игелексез була алмый. М. Җәлилнең кешеләргә карата эшләгән

яхшылыклары турында без укып беләбез. Шуңа күрә аның дуслары да күп булган. Кемгәдер эшләгән яхшылык синең үзеңә дә яхшылык булып кайтачагын ул бик яхшы аңлаган. Дусларына карата күрсәткән мөгалләмәсе аның тоткынлыкта булганда ачык чагыла. Җәлил сүзе, җыры, киңәше, мөнәсәбәте белән яхшылык эшләргә, аларга ярдәм итәргә тырышкан дигән нәтиҗә ясала.

**VI. Өй эше бирү.**

Шигырьне сәнгатьле итеп укырга.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Дөнья кайчан матур? (Мөдәррис Әгъләмов. «Матурлык минем белән», Гамил Афзал «Матурлык эзлим»).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — сәнгатьнең, шул исәптән өйрәнелә торган әдәби әсәрләрнең эмоциональ тәэсирен аңлау; матурлыкны күрә белү, аның кеше тормышында әһәмиятен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, матур әдәбиятта сурәтләнгән ситуацияләрне анализлап, әсәрне өйрәнгәндә һәм тормышта очраган ситуацияләрне хәл итү өчен, проблемаларны ачыклау; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү, үз фикерләреңне әңгәмәдә катнашучыларның фикерләре белән чагыштыру.

*Предмет нәтиҗәләр* — М. Әгъләмовның «Матурлык минем белән», Г. Афзалның «Матурлык эзлим» шигырьләренең эчтәлеген белү, идея-эстетик үзенчәлекләрен аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 5 нче сыйныф : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 145—149.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Алдагы дәрестә өйрәнелгәннәрне искә төшерү, өй эшен тикшерү рәвешендә үткәрелә ала.

*Бар кеше дә матурлыкны күрергә сәләтлеме?* дигән сорау куеп, укучыларны сөйләшүгә алып чыгабыз.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алдагы этапта эшләнгәннәргә нигезләнеп, укучылар дәрестә матурлык турында сүз барачагын билгелиләр.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Әлеге дәрес татар шигъриятендә матурлык темасы бирелешен өйрәнүгә юнәлдерелгән. М. Әгъләмовның «Матурлык минем белән» һәм Г. Афзалның «Матурлык эзлим» шигырьләре нигезендә укучылар лирик әсәрнең темасын, идеясен билгелиләр, лирик әсәрдә хис-кичерешләр сурәтләнеше үзенчәлекләре турында күзаллау булдыралар. Шул рәвешле, алар шигырьләрне тирәнтен аңлауга киләләр, бу белемнәр нигезендә мөстәкыйль рәвештә шушы темага язылган башка шигырьләргә анализ ясый алачаклар. Шигырьләрнең эчтәлеге, эш барышында сәнгать әсәрләренә мөрәҗәгать итү аларның эстетик зәвыкларын үстерәчәк, иҗади эш башкарганда ярдәм итәчәк.

М. Әгъләмовның «Матурлык минем белән» шигыре белән танышканда видеодәрес материалыннан файдаланып була. Алга таба сораулар ярдәмендә шигырьнең эчтәлеген ачыклыйбыз, хис-кичерешләр, аларның сәбәпләрен билгелибез: *«Матурлык минем белән» шигырендә нинди образларның матурлыгына дан җырлана? Шигырьдә нәрсә турында сүз бара? Мөдәррис Әгъләмов шигырендә нинди хисләр тасвирлана? Шигырьнең темасын ничек билгеләрсез? Әсәрдә шәһәр, табигать, туган ил образларын нәрсә берләштерә? Алар арасында нинди бәйләнеш бар? «Матурлык минем белән» шигыре ни өчен нәкъ менә шушы исем белән атал-*

*ган? Шигырьнең идеясе әсәрнең исеме белән нинди бәйләнештә?*

Лирик герой соклану, горурлану, шатлану, күңелгә канәгатьлелек алу хисләре кичерә. Һәр кешегә туган җире бик якын, шуңа күрә аның һәр почмагы да матур тоела. Шагыйрь, образлар турында фикерләп, бу җиһанда һәр нәрсә матур, матурлыкны күрә белергә генә кирәк дигән фикерен белдерә. Ул әсәренең исемендә төп идеяне җиткерә: матурлыкны күрә белү өчен, кешенең күңеле матур булырга тиеш. Ягъни күңеле якты, гүзәл кеше генә һәр мизгелдән ямь таба белә. Андый кешеләр гади генә әйбердә, гадәти күренешләрдә дә матурлык күрә. Илен, җирен яраткан, аның кадерен белгән, халкы, милләте тарихын белгән кеше алар белән горурлана. Мондый кеше патриот була, иле тагын да матуррак, көчлерәк булсын дип тырыша. Тарихын белмәгән, кешеләрне хөрмәт итмәгән кеше илен дә яратмый, аның белән горурланмый.

Татар мәктәпләрендә бу дәрестә Гамил Афзалның «Матурлык эзлим» шигыре дә өйрәнелә. Шигырнең эчтәлеген, идея-эстетик үзенчәлеген түбәндәге сораулар ачыкларга ярдәм итәр: *Шигырь герое өчен байлык мөһимме? Аңа алтын-көмеш кадерлеме? Шигырь героена гөлләрнең ниндие кирәк? Ул нинди дуслар турында хыяллана? Шигырь герое йөрәгенә салып ятлап йөргән төшенчәне ата. Ул гомере буе нәрсә эзләп йөри?* (Әсәрнең герое тышкы һәм эчке матурлыкка ия күренешләрне эзли.) *Ул эчке матурлыкны ниләрдә күрә? Кайсы образларның тышкы матурлыгына соклана?*

*Әлеге шигырендә шагыйрь матди һәм рухи кыйммәтләр турында сүз йөртә. Ул рухи кыйммәтләрне нәрсәдә күрә? Нинди матди кыйммәтләргә соклана? Гамил Афзалның «Матурлык эзлим» шигырендә нинди хис үзәктә тора? Бу шигырьдә холкы, күңел дөньясы нинди кеше исеменнән сүз барырга мөмкин?* дигән сораулар әсәрнең идея-проблематикасын тирәнрәк аңлау мөмкинлеген бирәчәк.

Лирик герой байлыкка битараф, ул буе матурлык эзләп йөри, кешеләрнең якты уйларын йөрәгенә салып ятлап йөри, матурлыкны табигатьтә, дуслыкта, балачак гамьсезлегендә күрә. Матди кыйммәтләргә илнең матурлыгын, табигать

гүзәллеген, рухи кыйммәтләргә якты уйлар, эчкерсез дуслык, балаларча шатлана белүне кертә алабыз. Бу шигырьдә матурлыкка соклану хисе үзәктә тора. Ул матурлыкны күрә белүче, һәр мизгелдән ямь табучы кеше исеменнән сөйләнә. Матурлык һәр җирдә — табигатьтә, кешеләрнең үзара мөнәсәбәтендә, җан тынычлыгында. Шуларны күреп соклана белгән кешенең дә күңеле матур була.

Әлеге дәрестә тема төшенчәсен үзләштерү дә каралган. Укучыларга *Әсәр нәрсә турында?* дигән сорауга җавап биргәндә, без әдәби әсәрнең темасын билгелибез. Димәк, тема — әсәрнең нәрсә турында булуын белдергән төп төшенчә ул.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Татар мәктәпләрендә М. Әгъләмовның «Матурлык минем белән» һәм Г. Афзалның «Матурлык эзлим» шигырьләрен чагыштырып эшләргә мөмкин. Әлеге ике шигырь үзара охшаш. Аларга хас уртак сыйфатларны билгеләргә куша алабыз.

Дәрестә үзләштерелгән теоретик материалны кабатлау максаты белән, *Әсәрнең темасын белү өчен, нинди сорауга җавап табарга кирәк? Мөдәррис Әгъләмовның «Матурлык минем белән» һәм Гамил Афзалның «Матурлык эзлим» шигырьләре нинди темага иҗат ителгән?* дигән сораулар биреп укучыларның белемнәрен ныгытабыз.

Шулай ук бу этапта *Нәрсә ул матурлык? Аны күрә белү ни өчен мөһим?* кебек сорауларны куеп укучыларны сөйләшүгә алып чыга алабыз.

Матурлыкны күрә белү кешенең холкыннан, күңел матурлыгыннан тора. Зарланучан, караңгы чырайлы, ачулы яки пессимист кешеләр дөньяның матурлыгын күреп бетермиләр. Ә инде шат күңелле, тормыштан ямь табып яши торган, һәр мизгелнең кадерен белә торган кешеләргә бөтен нәрсә матур тоела. Андый кешеләр белән аралашуы да күңелле, алар башкаларның да күңелен күтәрә, дигән нәтиҗәгә киленә.

**VI. Өй эше бирү.**

Шигырьләрне сәнгатьле итеп укырга өйрәнергә. М. Әгъләмовның «Матурлык минем белән» шигырен яттан өйрәнер-

гә, шигырьнең үзенә ошаган дүртьюллыгына иллюстрация ясарга.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Балачак хыялы (Роберт Миңнуллин. «Әни, мин көчек күрдем», «Олы булсам...»).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — мәрхәмәтлелек хисенә төшенү, кече дусларыбызны яратырга, аларны якларга кирәклекне аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, матур әдәбиятта сурәтләнгән ситуацияләрне анализлап, әсәрне өйрәнгәндә һәм тормышта очраган ситуацияләрне хәл итү өчен, проблемаларны ачыклау; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү, фикерләрне кабул итү һәм тәгъбирләү.

*Предмет нәтиҗәләр* — Р. Миңнуллинның «Әни, мин көчек күрдем», «Олы булсам...» шигырьләренең эчтәлеген белү, идея-проблематикасын аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 5 нче сыйныф : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 149—152.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

1. Өй эшен тикшерү. Алдагы дәрестә өйрәнелгәннәрне искә төшерү.

2. Укучыларга кызганыч күренгән эт баласы рәсемен күрсәтеп, рәсем буенча аның белән нәрсә буласын фаразлатып була. Укучыларның әлеге хәлгә мөнәсәбәтләрен ачыклыйбыз.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алдагы этапта әйткәннәргә нигезләнеп, дәреснең максатларын фаразлатабыз.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Алдагы өч дәрес татар балалар шигъриятенең күренекле вәкилләре — Роберт Миңнуллин һәм Шәүкәт Галиев шигырьләрен өйрәнүгә багышлана. Текстлар буларак, Роберт Миңнуллинның «Әни, мин көчек күрдем», «Олы булсам...», Шәүкәт Галиевнең «Һәркем әйтә дөресен», «Тагын бер «рәхмәт»» шигырьләре бирелә. Аларның эчтәлеге нигезендә укучылар лирик әсәрнең темасын, идеясен билгеләпиләр, текстта юмор һәм сатира алымнарын аерып чыгаралар. Шул рәвешле, укучылар шигырьләрне тирәнтен аңлауга киләләр, бу белемнәр нигезендә мөстәкыйль рәвештә юмор һәм сатирага билгеләмә бирә алачаклар. Шулай ук алар шигырьләр эчтәлеге нигезендә предметара бәйләнешле сорауларга да җавап табачаклар, димәк, аларның дөньяны күзаллавы үстереләчәк.

Р. Миңнуллинның «Әни, мин көчек күрдем» шигырен өйрәнгәндә видеодәрес материалыннан файдаланырга мөмкин. Эчтәлеген ачыклаганда *Бала ни өчен өйгә соңга калып кайткан? Ул күргән көчекнең хәле ничек булган? Көчек ни өчен шундый хәлгә төшкән? Бала көчекне өенә алып кайтканмы? Ни өчен әнисенә бу турыда сөйли? Бала әнисенә «көчек елый иде» дип кабат-кабат әйтә. Ничек уйлыйсыз, көчекләр чынлап та кешеләр кебек елый аламы? Бала көчекнең «елаганын» ничек аңлый?* сорауларыннан файдаланып эшлибез.

Шигырьнең эчтәлегенә нигезләнеп, бала күңелендә кызгану хисе тууын, балага кайсы холык сыйфатлары туры килүен билгеләгәндә, укучылар аның нечкә күңелле, кайгыртучан, мәрхәмәтле, шәфкатьле булуын күрсәтергә тиешләр. Хайваннар кешеләр кебек елый, зарларын аңлата алмый, ләкин

үзләрен рәнҗетсәләр аларга бик авыр. Шигырьдәге көчек тә үзен урамда адаштырып калдыруларыннан газаплана. Бала аның хәлен күңеле белән тоя һәм кызгана. Шуңа күрә аңа көчек елаган кебек тоела.

Татар мәктәпләрендә бу дәрестә Р. Миңнуллинның тагын бер әсәрен — «Олы булсам» шигырен өйрәнәләр. Шигырь сәнгатьле итеп укылганнан соң, эчтәлеге буенча сораулар бирәбез.

*Шигырь ни өчен «Олы булсам» дип атала? Олы булса, ул үзенең улына нинди йорт хайваны бүләк итәр иде? Ул аны кайларга алып барыр иде? Улына туган көненә нинди бүләкләр тапшырыр иде? Аны тыңлаучылар ни өчен көләләр?* сорауларыннан файдаланып эшлибез.

Р. Миңнуллинның «Олы булсам» шигыре балачак хыяллары турында. Шигырь герое — хыялый бала. Ул диңгездә коеныргa, кино карарга, машинада, велосипедта йөрергә, бинокльдән карарга, фотога төшерергә ярата. Димәк, ул алар турында үзе дә хыяллана. Соңгы строфада ул «үзенә дә кирәк икән диеп уйлый күрмәгез!» ди. Димәк, ул үзенең хыялларын сөйли, әмма башкаларга шуны сиздерәсе килми.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

*Роберт Миңнуллинның «Әни, мин көчек күрдем» шигырендәге баланың кайсы сыйфатлары сезгә ошады? Көчекне ташлаган кешене ничек күз алдына китерәсез? Авыр хәлгә төшкән җан иясенең хәлен нинди кешеләр аңлый ала?* кебек сораулар укучыларны үзара фикерләшүгә тартып, белемнәрне ныгытуга хезмәт итә.

Татар мәктәбендә бу этапта Р. Миңнуллинның «Әни, мин көчек күрдем!» һәм «Олы булсам» шигырьләрен чагыштырырга мөмкин. *Аларның кайсы җитди? Кайсы көлкеле вакыйганы сурәтли?* дигәндә түбәндәге җавапны алабыз: «Әни, мин көчек күрдем!» шигыре — җитди әсәр, чөнки анда кызганыч хәлдәге көчек сурәтләнә. Бу шигырьдә кызык, көлдерә торган вакыйга юк. «Олы булсам...» шигырендәге малайның хыяллары елмаю уята. Ул, кешегә сиздермәскә тырышып, үзенең хыялларын сөйләп бирә.

**VI. Өйгә эше бирү.**

«Әни, мин көчек күрдем!» шигырен яттан өйрәнергә. Шулай ук «Әни, мин көчек күрдем!» шигырен дәвам итеп фикерләреңне шигырь (1—2 строфа) яки хикәя формасында (4—5 җөмлә) язып килергә тәкъдим итеп була.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Дөреслек без күрә алганнан зуррак була аламы? (Шәүкәт Галиев. «Һәркем әйтә дөресен»).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — дөреслекнең әһәмиятен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, матур әдәбият үрнәкләрен анализлау барышында үзеңне башка кеше урынына куя белү; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре ачыклау, үз позицияңне, фикереңне дәлилләү; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү, үз фикерләреңне әңгәмәдә катнашучыларның фикерләре белән чагыштыру.

*Предмет нәтиҗәләр* — Ш. Галиевнең «Һәркем әйтә дөресен» шигыренең эчтәлеген белү, идея-эстетик үзенчәлеген аңлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 5 нче сыйныф : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 153—154.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Алдагы дәрестә өйрәнелгәннәрне искә төшерү, өй эшен тикшерү рәвешендә үткәрелә ала.

*Сез, укучылар, һәрвакыт дөресен генә сөйлисезме? Дөреслекне генә әйтү никадәр әһәмиятле икән, ничек уйлыйсыз?* дигән сораулар биреп, укучыларның җавапларын, бу турыда фикерләрен беләбез.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алдагы этапта әйтелгәннәргә нигезләнеп, бу дәрестә сүз нәрсә турында барачагын билгеләтәбез.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Әсәрне өйрәнү аны сәнгатьле итеп укудан башлана. Сорауларга җавап бирү барышында шигырьнең эчтәлеген ачыклыйбыз.

*Шигырьдә малайларны автор төрле итеп сурәтли. Хәлимнең кояш чыгуын иң беренче булып күрүе, ә баюын күрмәве аның нинди характер сыйфаты турында сөйли?* (Эшчәнлеге, елгырлыгы турында.) Мөсәлимнең кояш чыгуын — иң соңгы, ә баюын иң беренче булып күрүен аның әкрен кыймылдавы, пошынмас булуы белән бәйли алабыз.

Шигырьдә, кояш чыгуын тырыш, өлгер кешеләр беренче булып күрәләр, дигән фикер чыгарыла.

Алга таба юмор төшенчәсен үзләштерү өчен, түбәндәге сораулар нигезендә эшлибез. *Шәүкәт Галиевнең «Һәркем сөйли дөресен» шигырендә нинди вакыйга көлке тудыра? Автор үз геройларынннан ничек көлә?* Укучылар «малайларның, көне буе утырып, мәчегә җитәрлек кенә балык тотулары көлке тудыра, автор алардан яратып, үз итеп көлә» дип билгеләргә тиеш булалар.

Алга таба түбәндәге төшенчәләрне ачыклыйбыз.

*Юмор* — көлкенең бер төре, җитди нигезле яратып көлү.

*Сатира* — көлкенең бер төре, тискәре мөнәсәбәт белдереп көлү.

*Ничек уйлыйсыз, Шәүкәт Галиевнең «Һәркем әйтә дөресен» шигырендә көлкенең кайсы төре урын ала?* дигән сорауны биреп, аның юмор булуын билгеләтәбез.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

«Һәркем әйтә дөресен» шигырендә шагыйрь Хәлим, Сәлим һәм Мөсәлимнең кояш чыгышын һәм баешын төрлечә күрүләре турында әйтә. *Чынлыкта шулай була аламы? Автор ни өчен алай дигән икән?* сорауларына җавап эзләгәндә, Җир шарының төрле почмакларында яшәүчеләр өчен кояш төрле вакытта чыга һәм байый, дип фикер йөртәбез. Әмма шигырьдәге малайлар барысы да бер җирдә яши. Шагыйрь аларның холыклары төрле булудан елмаеп, үз итеп көлеп кенә шулай әйткәнлеген ачыклыйбыз.

*Бу малайларның кайсына охшарга теләр идегез?* соравы ярдәмендә сөйләшүгә, фикер алышуга алып чыгабыз.

Укучылар Хәлимнең эшчән, өлгер, җитез булуын билгеләрләр. Андый кешеләр күп эшкә өлгерә. Хәлимгә охшасам дәресләремне әзерләргә дә, уйнарга да, әти-әниемә булышырга да өлгерер идем, дип җавап бирәчәкләр.

Соңгы дәрестә *Лириканың хис-кичерешләргә байлыгы, эмоциональ яңгырашы аның формасына ничек тәэсир итә?* соравын биреп, укучыларны уйландырабыз, нәтиҗә ясатабыз. Бу вакытта дәреслектә урнаштырылган материал ярдәмгә килер.

**VI. Өй эше бирү.**

Шигырьне сәнгатьле итеп укырга өйрәнергә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Рәхмәтне саныйлармы? (Шәүкәт Галиевнең «Тагын бер «рәхмәт» шигыре). Үткән теманы кабатлау.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — «рәхмәт» сүзенең әһәмиятен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү, фикерләрне кабул итү һәм тәгъбирләү.

*Предмет нәтиҗәләр* — Ш. Галиевнең «Тагын бер «рәхмәт» шигыренең эчтәлеген белү, идея-эстетик үзенчәлеген билгеләү. Үткән теманы кабатлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 5 нче сыйныф : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 154—156.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Алдагы дәрестә өйрәнелгәннәрне искә төшерү, өй эшен тикшерү рәвешендә үткәрелә ала.

*Яхшылык итсәң — яшер, яхшылык күрсәң — белдер* мәкале белән эшләү, шуның нигезендә укучыларны сөйләшүгә алып чыгу.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең тема, максатлары билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Шигырьне сәнгатьле итеп укыганнан соң, анализны түбәндәге сораулар ярдәмендә оештырабыз.

*Шигырьдә кем турында сүз бара? Сәлим яхшылык эшләргә яратамы? Ни өчен? Сәлим нинди яхшылыклар эшләгән? Ул барлыгы ничә «рәхмәт» ишеткән?*

Сәлим, яхшылык эшләргә яратса да, алар белән мактанырга да ярата. Шуңа күрә ул «рәхмәт»ләрне санап бара. Күбрәк яхшылык эшләсәң, рәхмәте дә күбрәк булачак, дигән нәтиҗә ясала. Шигырьнең эчтәлегенә нигезләнеп, аның кылган яхшылыгың хакында мактанып йөрмәскә кирәклеге турында булуын билгелибез.

Сәлим, эшләгән яхшылыклары белән мактана, алар өчен әйтелгән «рәхмәт»ләрне санап бара. *Сәлимгә хас төп сыйфатны кайсы дуртьюллык күрсәтә? Аның холкындагы нин-*

*ди сыйфат көлке тудыра?* дип, алдагы дәрестә үткән юмор төшенчәсен бу әсәр белән бәйләп ныгытабыз.

4 нче сорауга җавап биргәндә ике шигырьнең дә көлкеле булуын ачыкларга тиешбез.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Шигырь эчтәлегенә туры килгән мәкальләрне искә төшерәбез, аларның мәгънәләрен аңлатып, эшне оештырабыз.

*Яхшылык ит, каршысына яхшылык көтмә.*
*Яхшылык ит тә мәңгегә оныт.*
*Яхшылык эшләгәнеңне үзең әйтеп белдермә.*
*Яхшылык ит тә, суга сал.*

**VI. Өй эше бирү.**

Шигырьне сәнгатьле итеп укырга өйрәнергә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Син әкият яратасыңмы? (Драма әсәрләре. Туфан Миңнуллин. «Гафият турында әкият»);

Нәрсә яхшы, нәрсә начар? (Туфан Миңнуллинның «Гафият турында әкият»е);

Әкият хакыйкатькә якынайта (Туфан Миңнуллинның «Гафият турында әкият»е).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — әдәби әсәрләрдә персонажларның үз-үзен тотышын һәм гамәлләрен бәяләп, әхлакый сайлау ситуацияләрендә әхлакый кыйммәтләр һәм нормаларга таянырга юнәлеш бирү; әкиятнең кеше тормышында ролен аңлау, яхшылыкны яманлыктан аера белү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; объектларның һәм күренешләрнең төп билгеләрен ачыклау һәм бәяләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре ачыклау, үз позициямне, фикереңне дәлилләү; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү, үз фикерләреңне әңгәмәдә катнашучыларның фикерләре белән чагыштыру.

*Предмет нәтиҗәләр* — Т. Миңнуллинның «Гафият турында әкият»енең эчтәлеген белү, идея-проблематикасын билгеләү. Драма төре турында төшенчә алу.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 5 нче сыйныф : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 157—172.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Алдагы дәрестә өйрәнелгәннәрне искә төшерү, өй эшен тикшерү рәвешендә үткәрелә ала.

Укучыларның игътибарына төрле әкият геройлары рәсемнәрен тәкъдим итеп була. Алар арасында рус һәм татар әкиятләренең геройлары булырга тиеш, әйтик, Шүрәле, Былтыр, Камыр батыр, Убырлы карчык, Балда, Карабас-Барабас, Буратино, Юха елан һ.б.

*Бу геройлар кайсы әкиятләрдән? Ничек уйлыйсыз, алар бер әкият геройлары була аламы? Шундый әкият укыйсыгыз киләме?* дип, укучыларда теманы өйрәнүгә кызыксыну уятабыз.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең темасы һәм максатлары билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Программада драма төрен өйрәнүгә каралган сәгатьләр (2 дәрес татар мәктәбендә, 3 дәрес рус мәктәбендә) Т. Миңнуллинның «Гафият турында әкият» пьесасын өйрәнүгә багышланган. Дәреслектә әсәр кыскартып бирелә. Укучыларга әсәрнең эчтәлеге буенча сорауларга җавап табарга, персонажларны характерларга, аларның эш-гамәлләренә бәя бирергә, әсәрнең темасын һәм идеясен табарга тәкъдим ителә. Шулай ук әдәби-теоретик белем бирү кысаларында төп герой, ярдәм-

че герой төшенчәләрен аңлап эш итү күздә тотыла. Әкиятләрнең төрләрен барлап әкият-пьесага билгеләмә бирү аның үзенчәлекләрен аңлап эш итү мөмкинлеген тудырачак. Бу алга таба укучыларга иҗади эшне башкаруда (мизансцена төзү, аны сәхнәләштерүдә) ярдәм итәчәк.

Т. Миңнуллинның «Гафият турында әкият»е тормышта әкиятләрнең кирәклеге турында. Әсәр өлешләп укыла (татар мәктәбендә ике өлешкә, рус мәктәбендә өч өлешкә бүлеп өйрәнелә). Алда бирелгән сорауларны да шул өлешләргә бәйле рәвештә тәкъдим итәбез. Бу әсәрне өйрәнгәндә, видеодәрес материалыннан да файдаланырга мөмкин.

*Әкиятне кем сөйли? Кем ул Әкиятче?*

*Әкиятче янына кем килә? Ул үзен ничек тота? Бу малай нәрсә яратмый? Әкият турында Гафият нәрсә ди?*

*Сез Гафият белән килешәсезме? Ул нәрсәдә ялгыша? Әкият нәрсәгә өйрәтә?*

*Гафият турында Әкиятче нәрсә чыгарырга уйлый? Ни өчен? Гафият кем белән таныша? Ул аның каршысына кем сурәтендә чыга?* (Аларның танышу диалогын рольләргә бүлеп укытып була.)

*Кем ул Юха елан? Ул әкиятләр яратамы?* (Бирердә Юха еланның кешене юк итү өчен, төрле сурәтләргә керә, мәсәлән матур кызга, батыр егеткә әйләнә ала, дигән аңлатма бирү кирәк.)

*Гафият Юха еланга ышанамы? Юха елан Гафиятне нәрсәләргә өйрәтә? Үги кызны алар ничек үпкәләтәләр?*

*Юха еланның «Дөньяда рәхәтләнеп яшәргә кирәк. Ничек телисең, шулай. Менә мин авылда теләсә нишлим. Куяннарны тотып кыйныйм, тиеннәрнең борынына чиртәм» дигән сүзләре белән син килешәсезме? Ни өчен?*

*Алар бергәләп нинди начарлыклар эшлиләр?*

*Юха елан үзе куркакмы? Бу турыда кайсы сүзләреннән белә алабыз? Шушы урынны тексттан табып укыгыз.*

*Шүрәле кемнән ярдәм сорый? Ни өчен? Убырлы карчык Гафият эшләгән начарлыкларны ошатамы?*

*Гафият ни өчен явыз көч булырга ризалашмый? Гафияткә ярдәмгә кемнәр килә? Гафият әкият турында нәрсәне аңлый?*

Туфан Миңнуллинның «Гафият турында әкият»ендәге вакыйгаларны дөрес урнаштырырга тәкъдим итү әсәрнең сюжетын төгәл күзалларга ярдәм итәчәк.

Гафиятне характерлаганда, аның кире, үзсүзле малай булуын күрсәтәбез. Ул башкаларның фикерләренә колак салмый, әкиятнең кирәклеген аңламый. Явыз көчләрнең тәэсиренә бирелеп, начарлыклар эшли, башкаларны рәнҗетә, үпкәләтә. Гафият әкиятне юләрләр уйлап тапкан дип саный. Гафият белән килешеп булмый, чөнки әкиятне юләрләр уйлап чыгарса, аны ничәмә-ничә йөз еллар буе ничәмә-ничә мең кешеләр сөйләмәс иде. Ул илдән-илгә йөрмәс, телдән-телгә күчмәс иде. Әкият кешеләрне хыяллана белергә, зирәклеккә, батырлыкка өйрәтә. Менә шуларны кире кагуда ялгыша Гафият дигән нәтиҗә чыгарыла.

Юха елан — яше мең елга җиткән аждаһа. Кешенең дошманы. Ул үзе дә гел начарлык эшли, башкаларны да начарлык эшләргә өнди.

Т. Миңнуллин әкиятендә Убырлы карчык башка әкиятләрдәге Убырлылардан аермалы буларак, тыныч, акыллы, яхшы күңелле итеп сурәтләнә. Ул кешеләргә начарлык эшләми, киресенчә, Юха еланны начарлык эшләүдән тыярга тырыша. Яхшылыкны явызлыктан аера белә. Гафиятне дә фикерен үзгәртергә, хаталарын танырга аны дөрес юлга бастыруга өлеш кертә.

Бу әкияттә Шүрәле дә акыллы, төпле фикерле, яхшы күңелле итеп бирелә, ягъни яхшы якка үзгәргән. Гафиятнең дә әкиятләр турындагы фикерен үзгәртергә тырыша. Былтырдан да тирән хөрмәт белән ярдәм сорый.

Беренче дәрестә үк драма төренә билгеләмә бирү сорала. Моның өчен әкиятнең Беренче пәрдәсе I күренешен укыганнан соң *«Туфан Миңнуллинның «Гафият турында әкият»е син укыган башка әкиятләрдән кайсы ягы белән аерыла? Ул нинди формада язылган?* сорауларын биреп, әсәрнең хикәяләнеп бирелмәвен, диалоглар формасында язылганын билгелибез. Монда аерым персонажларның сүзләре аларның исемнәре астында язылган, урыннары белән автор аңлатма биреп бара, дип ачыклыйбыз.

Алга таба укучыларга аңлатма бирәбез: Т. Миңнуллинның әсәре әкият-пьеса. Димәк, ул — драма әсәре. Сәхнәгә куелу өчен язылган. Моның өчен автор аны тиешле формага керткән. Герой репликалары, автор аңлатмалары аерым бирелә. Әкият-пьеса — диалог рәвешен алган, драма төре кануннары буенча язылган әкият. Ул сәхнәдә спектакль итеп куела.

Шулай ук беренче дәрестә төп герой һәм ярдәмче геройлар турында аңлатма бирелә. Дәреслектә бу теоретик материал урын алган.

Әсәрнең темасын билгеләгәндә әкиятләрең кеше тормышындагы урыны, аларның файдасы, кешеләрне яхшылыкка омтылырга, зирәк һәм батыр булырга өндәве турында булуын ачыклыйбыз. «Гафият турында әкият»ендә язучы акыллылык һәм наданлык, яхшы күңеллелек һәм явызлык, батырлык һәм куркаклыкны капма-каршы куя.

Әкият илдән—илгә йөреп, телдән—телгә күчеп зирәклеккә, батырлыкка, хыяллана белергә өйрәтә, тормышны аңларга булыша. Әкиятләрне яратырга, аларны укырга, сөйләргә кирәк. Алар аша без явызлыкны яхшылыктан аерырга өйрәнә алабыз, дип әйтергә тели язучы.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

*Т. Миңнуллинның «Гафият турында әкият» әсәрен ни өчен әдәби әкият дип атыйлар? Әсәрдәге фольклор башлангыч нәрсәдә чагылыш таба?* сорауларын биреп, фольклор жанры булган әкият билгеләрен бу әсәрдә табып билгеләргә кушып була.

Укучылар әлеге әкиятнең авторын күрсәтәләр. Ул — Туфан Миңнуллин. Балалар өчен язылган, әкиятендә ул героеның маҗаралары турында сөйли, укучылар «Фольклор башлангыч әдәби әкиятләрдә дә уңай һәм тискәре геройлар булуында, яхшылыкның явызлыкны җиңеп чыгуында чагылыш таба», дип җавап бирергә тиеш булалар.

Драма әсәре рольләргә бүлеп уку өчен уңайлы. Анда геройларның сүзләре аерып әйтелгән. Соңгы дәрестә инде геройларның характерын, аларның үзләрен ничек тотуы, сөйләшүе, башкаларга карата мөнәсәбәтләре белән таныш

булганга, пьесаның үзләренә ошаган өлешен аерып алып, төркемдә рольләргә бүлеп укытырга мөмкин.

Шулай ук бу этапта (әсәр тулаем укылып беткәннән соң) *Төп геройның әкиятләрне яратмавы аның нинди холык сыйфатына бәйле? Бу фикерен үзгәртергә аңа кемнәр һәм ничек булыша? Юлында Юха елан кебек явыз көчләр генә очрап торса, Гафият белән нәрсәләр булыр иде дип уйлыйсың?* дип, укучыларны фаразлата алабыз.

Әлеге этапта тагын бер кызыклы алым кулланып эшләргә мөмкин. Ул мизансцена төзү алымы. Төркемнәргә бүленеп, Т. Миңнуллинның «Гафият турында әкият» пьесасының үзегезгә ошаган өзеген сайлап алып, шуңа мизансцена төзетәбез. (*Мизансцена* сәхнәдә урнашу дигәнне аңлата. Ул актерларның сәхнәдә спектакльнең теге яки бу моментында урнашу тәртибе, аларның хәрәкәт юнәлеше, образлар тормышының тышкы кыяфәтенең күрсәтелүе. Мизансцена төзү этаплары: мизансцена төзү өчен, күренешләрне сайлап алу; ни өчен сайлап алганнарына аңлатма бирү; мизан-сценаны төзү; әсәрдә сурәтләнгән билгеле бер мизгелдә геройларның урнашуы, төрле хәрәкәтләренең катып калган моментларын күрсәтү; бергәләп, күрсәтелгән мизансценаның уңышлы якларын һәм кимчелекләрен тикшерү, тәкъдимнәр кертү).

Алга таба Т. Миңнуллинның «Гафият турында әкият» пьесасыннан мизансцена өчен сайлап алынган өзекне сәхнәләштерергә куша алабыз. Аны укучылар сыйныфта яки мәктәп сәхнәсендә күрсәтә алалар.

Соңгы дәрестә *Драма әсәре иҗат итүдә кемнәр катнаша?* соравын биреп укучыларны уйландырабыз, нәтиҗә ясатабыз. Моның өчен дәреслектә урнаштырылган материал ярдәмгә килер.

**VI. Өй эше бирү.**

Әсәрне укырга, эчтәлеген сөйләргә өйрәнергә, сорауларга җавап бирергә.

**VII. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Үткән материалны кабатлау. Контроль эш. Нәтиҗәләр чыгару.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* — әдәбиятка мәхәббәт хисе туу, аны алга таба өйрәнү теләге туу.

*Метапредмет нәтиҗәләр* — уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, гомумиләштерә һәм нәтиҗә ясый белү, мәгълүматны нәтиҗәле истә калдыру һәм системалаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп әйтә белү, фикерләрне кабул итү һәм тәгъбирләү.

*Предмет нәтиҗәләр* — үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау.

**Материал:** Туган телдәге әдәбият. 5 нче сыйныф : төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек / Мөхәрләмова Г. Н., Абдуллина Д. М. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2024. — Б. 3—172.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру, дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерү рәвешендә үткәрелә ала.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Укучылар әлеге дәреснең уку елы дәвамында өйрәнелгәннәрне кабатлау, үткәннәрне искә төшерү дәресе икәнлеген билгели алалар.

**IV. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Кабатлауны төрлечә оештырырга мөмкин. Анда һәр укучы катнашырга (димәк, сорауларның авырлары да һәм җиңелрәкләре дә булсын), дәрес формасы да кызыклы оештырылган булырга тиеш. Мәсәлән, алдан карточкалар әзерләп, аларга бу уку елында үтелгән әсәрләрнең исемнәрен һәм авторларын язып куярга мөмкин. Һәр партада утырган

(төркемдә булган) укучылар бер карточканы алып, бу әсәр турында белгәннәрен әйтәләр (башка төркемнәр дә өсти ала). Бу — укылган әсәрләрне тиз генә искә төшерергә ярдәм итә. Шул ук алым белән аерым әсәрнең темасын, төп фикерен искә төшерергә, бирелгән өзекнең кайсы әсәрдән икәнлеген ачыкларга һ.б. биремнәрне үтәргә тәкъдим ителә.

Дәреслектәге рәсемнәрне экранга чыгарып, аның кайсы авторның нинди әсәре булуын ачыклатырга, яки укучыларга алдан ук төрле әсәрләргә рәсем ясарга кушып, күргәзмә оештырырга һәм алар буенча сөйләшү үткәрергә мөмкин.

Укучыларның аерым сүзләрнең мәгънәсен хәтердә калдыруларын ачыклау өчен, сорауларны да төрлечә әзерләргә кирәк.

Биремнәрнең бик төрле булуы ихтимал, әмма кабатлау үтелгән материалның иң әһәмиятле өлешләрен укучының хәтеренә сеңдеререргә булышырга тиеш.

Электрон дәреслектә бирелгән тестлар үткәннәрне кабатлауда ярдәмгә килер.

Шулай ук бу дәрестә контроль эш тә үткәрергә кирәк.

**V. Рефлексия.**

1. Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
2. Бәяләү, үзбәя бирелә.

## ЭЛЕКТРОН РЕСУРСЛАР ИСЕМЛЕГЕ

www.antat.ru/ru/iyli/publishing/book/uchebniki — Дәреслекләрнең электрон формалары.

www.antat.ru/ru/tatzet — Татар теле: зур электрон туплама.

https://magrifat.antat.ru — Укытучылар, әти-әниләр һәм балалар өчен мәгълүмати ресурс.

https://photo.miras.info/№ — «Татарское визуальное наследие» сайты

www.belem.ru — Татар мәгарифе порталы.

www.balarf.ru — Интерактив мультимедия китапханәсе.

http://tatarile.tatar — «Татар иле» укучылар өчен электрон энциклопедиясе.

www.ganiev.org — Русча-татарча тавышландырылган онлайн сүзлек.

www.tatarhistory.ru — Татарстан тарихы буенча электрон атлас.

www.tatarcartoon.ru — «Татармультфильм» берләшмәсе эшләгән анимацион фильмнар җыентыгы.

Учебное издание

**Мухарлямова** Гульназ Нурфатовна
**Абдуллина** Дилария Маратовна

РОДНАЯ (ТАТАРСКАЯ) ЛИТЕРАТУРА

**5 класс**

Методическое пособие
для преподавателей образовательных организаций
основного общего образования, работающих с обучающимися,
владеющими родным (татарким) языком

*На татарском языке*

Уку-укыту басмасы

**Мөхәрләмова** Гөлназ Нурфат кызы
**Абдуллина** Диләрия Марат кызы

ТУГАН ТЕЛДӘГЕ ӘДӘБИЯТ

**5 нчы сыйныф**

Методик әсбап
Төп гомуми белем бирү оешмаларында
(туган (татар) телендә сөйләшүче укучылар белән)
эшләүче укытучылар өчен

Мөхәррире *А. А. Дәүләтова*
Рәссамы *Д. Л. Нәүрузова*
Техник мөхәррире һәм компьютерда
биткә салучысы *Л. И. Матвеева*

Подписано в печать с оригинал-макета 21.08.2024
Формат 60×84 1/16.